Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

05

май 2020

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Татар кызларының, татар әбиләренең йөзләрендә иман нуры бар

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

05
(317)
май 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Ризаэддин Фәхреддин

ТАТАР ГАМЕ

4 *Ильяс хәзрәт Җиһаншин:* «Мирасыбызны киләчәк буынга җиткерик!»
10 Татарның шәфкатьле улы. *А.Хәбибуллин*
18 Игелекле татар байлары. *Т.Биктимирова*

ТАРИХИ МИРАС

24 Кичә, бүген һәм иртәгә. *И.Таһиров*
32 «Ислам динен олылагыз!» *М.Әбделганиева, М.Сәхапова*
35 Саумы, ураза! *Х.Вәлиев*
38 Үтәмеш зиратының кабер ташлары. *Р.Исхакова*
43 Гөләйза кыйссасы. *Г.Хисамиев*
49 I Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда хатын-кызлар мәсьәләсе. *А.Шәрәфиева*
55 Галәветдин хәзрәт Җамалетдиновка ни өчен яла ягылган? *Р.Сәлиев*
60 «Иттифакъ» газетасы. *Л.Гобәйдуллин*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битка салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәширият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, А.Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

64 Борһан Шаһиди (1894-1989) – Кытайның күренекле дәүләт эшлеклесе, галим һәм язучы

ДИНИ МИРАС

71 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

76 «Сагындыра туып-үскән җир» (Исфәндияр Ишгай). *Х.Миңнегулов*
83 Тальян моңы. *С.Шәйхи*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

86 Мәрҗани хәзрәтнең вафаты (1818-1889)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 Мәрҗанинең кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
91 Батырлар табыла вакыт белән... *И.Габдрахманов*
95 Олуг Мөхәммәдкә – һәйкәл. *Г.Шәмсетдинов*

98 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

100 «Туплар шартласа да, җырлар тынмый!» *А.Хәкимова*
106 Фасилнең моң чишмәсе. *Ә.Фәйзрахманов*
110 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

112 Тукай ул – безнең татар халкының дәүләте. *Т.Миңнуллин*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Май*

Заказ №А-891. Тираж – 1839 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 28.04.2020. Чыгу көне: 06.05.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Бу сан «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә Р.Мөхәммәтҗанов фотосы. 2000 нче еллар. *(Разил Вәлиевнең гаилә архивыннан).*

Төзәтмә. Журналның 4 нче санында «Истә, һаман да истә!» дигән материалда, техник сәбәпләр аркасында, Гомәр Толымбай белән Әбрар Сәгыйди фотоларының урыннары алышынган. Укучыларыбыздан әлеге хата өчен гафу үтенәбез.

Бәхет — гаиләсе эчендә рәхәт гомер итүдән гыйбарәт булып, гаилә эчендә рәхәт күрмәгән бер кеше гаилә тышында рәхәт күрә белмәс.

Ризаэддин Фәхреддин

Ризаэддин Фәхреддин гаиләсе белән.
Сулдан уңга: Габдерәшит, Ризаэддин, Габдрахман, Зәйнәп, Габделәхәт, Нурҗамал.
Уфа, 1900 ел

Ризаэддин Фәхреддин

(12.01.1858-14.04.1936)

Бизмәннең бер генә башы басып тормый.

***

Ачу килү изгелекләрне оныттыра.

***

Өмете беткән кешенең өмете – үлем генә.

***

Төшүе авыр булырлык югары урынга менәргә кызыкма.

***

Дошман белән чуалу вә булышу – аны кыздырудыр.

***

Күп наданга ияргүгә караганда, аз галимгә ияргү яхшырак.

***

Кулыңнан килсә, форсат тисә, галим бул, бу эш насыйп булмаса, шәкерт вә гыйлем эстәүче бул, бу да булмаса, гыйлемне дус күр.

***

Дөньяда яхшы тереклек күркәм холыклы хатыннан башка булмас.

***

Әдип вә галимнәре булмаган кавем бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык көчсез, әдәбияты булмаган милләт рухсыз.

***

Бәгъзе бер кешеләр тешләре белән чәйниләр, бәгъзе берәүләр телләре белән чәйниләр.

***

Дошманны җиңү өчен иң көчле корал – аңа изгелек итү.

***

Тугрылык — максатка бара торган юлларның һәм кыскасы, һәм яхшысы.

***

Балаларга калдыра торган мирасларның иң кыйммәтлесе — дин өйрәтеп калдыру.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Ильяс хәзрәт Җиһаншин:
«Мирасыбызны киләчәк буынга җиткерик!»

«Яңа Татар бистәсе зиратына мемориал статус бирәсе иде»

Беркөнне минем янга Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдсафа улы Галикәевнең оныгы Динә ханым Сакаева килде. Мин аны Яңа Татар бистәсе зиратына, бабасы кабере янына алып бардым. Мөхәммәдсадыйк Галикәев Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте, 1 нче гильдия сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, Казан Шәһәр Думасы гласные була, тире һәм йон складлары, кибетләр тота. Замандашлары аны «мануфактура короле» дип тә атыйлар. Ул шушы мәчетне* яңадан төзетә, «Мөхәммәдия»нең яңа бинасы төзелешенә акча күчерә. Аның бертуган энесе Габдрахман Галикәев тә 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре,

Йосыф Әҗемев, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Динә Сакаева һәм Наил Таиров. Яңа Татар бистәсе зираты. 2020 ел

*Элекке Ал мәчет, хәзерге «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе бинасы.

Йосыф Әҗемев безгә күренекле татар зыялылары Галимҗан Баруди, Салихҗан Галиев, Габделхәмид Казаков һәм Габдулла Апанаевлар бергә төшкән фотоның төп нөсхәсен бүләк итте.

сабын кайнату заводының хуҗасы була. «Солтания» мәчете, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе төзелешләренә үзеннән зур өлеш кертә. Галикәевнең оныгы белән Әҗемевләрнең нәсел дәвамчысы, профессор Йосыф Ибраһим улы Әҗемев тә килгән иде. Әҗемевләр дә Яңа Татар бистәсендәге зиратта җирләнгән.

Бер гасыр чамасы вакыт үтсә дә, әлеге бөек шәхесләребезгә бәйле кешеләрне Аллаһы Тәгалә үзе безгә китерә. Галикәев, Әҗемевләр кебек затлы, көчле нәсел югалмаган. Алар дөньялыкта да үз урыннарын тапканнар, ахирәтне дә онытмаганнар.

Киләчәктә Яңа Татар бистәсендәге зиратка мемориал статус бирәсе иде. Анда җитди төзекләндерү, төрле яктан капкалар булдыру, кабер ташларын саклау эшләрен дә башкарырга кирәк. Атаклы муллаларның кабер ташларына QR кодлар куярга планлаштырабыз.

Хәзер татар зиратына мәрхүмнәр җирләнми диярлек. Әмма бу каберстан һич кенә дә ябык оешма булырга тиеш түгел. Биредә туристик мәйдан булырга, монда килгән һәр кеше татарның күренекле шәхесләре, аларның нәсел-нәсәбе турында бай мәгълүмат алырга, ахирәт тормышы турында искә төшерергә тиеш. Аерым язучылар, сәнгать әһелләре, галимнәр, эшкуар байларыбыз турында үзгә экскурсия маршрутлары эшләп, гамәлгә ашырып булыр иде.

Бүген зыялы дип саналган кайбер хәзрәтләребез дә: «Шиһабетдин Мәрҗани шунда күмелгәнмени?» – дип сорап, безне гаҗәпләндерә. Яңа Татар бистәсе зираты мәгариф үзәге дә була ала. Монда җирләнгән бөек шәхесләребезнең

кабергә кадәрге тормышлары, иҗаты, кылган игелекләре турында гыйбрәт һәм үрнәк өчен бик күп нәрсәләр сөйләргә мөмкин.

Яңа Татар бистәсе зиратына җирләнгән мулла һәм эшкуарларның нәсел-нәсәбен табып, алар белән элемтә урнаштыруны мәдрәсәбезнең бер максаты итеп куйдык.

«Яңа Татар бистәсе – үзенчәлекле урын»

Шәкертләребезне борынгы зыялылар, бабаларыбыз рухында тәрбиялибез. Мөгаллимнәребез хәзерге вакытта «Остазларның эзеннән барсак, югалмабыз» дигән китап әзерли. Инкыйлабка кадәр биредә «Якубия» мәдрәсәсе эшләгән. Галимҗан Барудиның бертуган энесе Салихҗан Галиев имам булган, мәдрәсә җитәкләгән. Бирегә Түбән Новгород, Ульяновск, Оренбург, Вятка тарафларыннан да килеп белем алганнар. Хәсәнҗан хәзрәт Әхмәрев, хәзерге Ульяновск өлкәсендәге Малыклы районыннан килеп, биредә җиде ел укый. Аны Иске Кармәткә мулла итеп җибәрәләр. Ул шунда булачак шагыйрь Хәсән Туфанны да укыта, аңа хисап, астрономия фәннәреннән гыйлем бирә. Бу турыда шагыйрьнең матур гына истәлекләре дә бар. Заманында Гаяз Исхакый да монда килеп чыгыш ясый, Әхмәдһади Максуди да дәресләр бирә, Габдулла Тукай Шәһретдин Шәрәф белән килеп шәкертләр белән аралаша.

Яңа Татар бистәсе – үзенчәлекле урын. Бистәдә – өч мәчет, димәк, өч мәхәллә эшләгән, гыйлем, мәгарифкә игътибар зур булган. Мәдрәсәнең диварларына игътибар итсәгез, анда мәшһүрләребезнең сүзләре язылган. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗанинең: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Болар – милли тел, милли кием һәм милли гореф», – дигән сүзләре. Болар – бер көн, бер гасыр өчен генә түгел, адәм баласының мәңгелеге өчен әйтелгән сүзләр! Алар бүгенге көн өчен дә актуальлеген югалтмаган! Үзебезнең эшчәнлегебезне шушы бөекләребезнең хезмәтен истә тотып алып барырга тырышабыз.

«Эдуард хаҗи Ганиев үз нәсел-нәсәбен яхшы белә иде»

Галимҗан Баруди 1905 елгы хөтбәсендә: *«Әй, байлар! Дәүләтегезгә алданмагыз! Дәүләтегезнең өлешен чыгарыгыз. Малыгызны диндә иҗтиһад кылу белән бәйләгез. Малны гыйлемгә һәм мәдрәсәләргә сарыф итегез. Шул вакытта гына сез ике дөнья бәхетенә ирешерсез»*, – ди. Аллаһка шөкер, хәзерге вакытта байларыбыз күпмедер дәрәҗәдә дингә тартыла. Безнең арадан киткән Эдуард Әнвәр улы Ганиев үз малын дин ислам үсешенә бирде. Аның белән якыннан аралашканлыктан: «Эдуард абый, бу эшләрне китаби мәсьәлә белән бәйләп алып барырга кирәк», – дип әйтә идем. Аллаһка шөкер, ул безне тыңлады. Егерме мәртәбә Кулаткы укулары үткәрелгән икән, ул барыбер үз эзен калдырды.

Без инкыйлабка кадәр булган татар байларының исемнәрен беләбез, әмма хәзер аларның бик азы гына искә алына. Әхмәд бай Хөсәенев үзе тары ярмасы белән генә тукланган, ә нинди дәрәҗәле байларның берсе саналган! Ул, Россия күләмендә генә түгел, чит илләрдә дә сәүдә фирмалары тоткан. Әхмәд бай үзеннән соң малын шәкертләр һәм мәдрәсәләргә тотарга дип васыять итеп калдыра. Аның бер фикере бигрәк тә ошый миңа. «Ел башында без мәдрәсәгә йөзләгән шәкерт алабыз. Шуларның берничәсе генә имам булып китә», – дигән ул. Татар байлары, дин белән бергә, дөньяви юнәлешне дә кайгырткан. Ә инде шәкерт дөньяви фәннәрне дә үзләштерә икән, аның сәүдә яки башка юнәлештә дә эшләргә

«Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм шәкертләре атаклы иганәчеләрнең оныклары Динә Сакаева һәм Йосыф Әҗемев белән. 2020 ел

мөмкинлеге булган. Байларыбыз мулла хәзерләдем дә, ул мәчеткә урнашып дога кылыр һәм шуның белән эш бетәр дип уйламаган. Алар киң масштабта фикер йөртә торган шәхесләр тәрбияләргә тырышкан.

Шөкер, соңгы елларда да байларыбыз намазга баса башлады, хаҗга баручылар, зәкят бирүчеләр артканнан-арта бара. Эдуард абый да бер урында гына таптана торган кеше түгел иде. Ул, каядыр барып, кемнеңдер хәлен белә икән, кешеләрне теге яки бу милләткә аермый иде. Кешенең мохтаҗлыгын күзеннән күрсә, аңа мөмкин булганча ярдәм итте. Саратов һәм Ульяновск өлкәләрендәге, Татарстандагы дини уку йортларына, мәчетләргә һәрдаим ярдәм итеп торды. Татарлар тарихта эзле булган, дибез. Эдуард хаҗи авыл, төбәк тарихы буенча китап чыгаручыларга да даими ярдәм күрсәтеп килде. Үз тарихын, нәсел-нәсәбен яхшы белгән, зыялы кеше иде ул.

«Шәкертнең «кыса»сы булырга тиеш»

Милли гореф-гадәт тә – безнең корал. 1998 елны шәкертләр бирегә күчкәч, иң беренче итеп, махсус кием булдыру таләбен куйдым. Кешенең тышкы кыяфәте дә туры, дөрес булырга тиеш. Менә бу портретны гына ал: әгәр дә аның кысасы булмаса, ул ямьсез күренә. Кыса эчендә ул матур, камил. Шуның өчен дә шәкертнең «кыса»сы булырга тиеш! Әгәр дә шәкерт урамда формада, кәләпүштән йөри яки автобуста бара икән, олы кеше белән, һичшиксез, исәнләшәчәк, аңа урын бирәчәк. Гади генә киемнән булса, ул урын бирмәскә дә мөмкин. Андый кеше урамда барганда да төкеренми, тәмәке тартмый. Мине, булачак хәзрәтне, кеше карап тора дип уйлый. Мин – шәкерт, минем киемем, кәләпүшем бар, начар гадәтләр миңа килешмәс, ди. Әгәр дә ул, махсус киемсез һәм кәләпүшсез булса, Аллаһ сакласын, кайбер ярамаган эшләрне дә эшләргә мөмкин.

Шәкертләребез генә түгел, мөгаллимнәребез дә инкыйлабка хәтле булган

мәдрәсә формасына охшатып тегелгән кием кия. Без аны, шәкерт укырга килү белән, бушка, амәнәт итеп бирәбез. Аны чиста, пөхтә итеп саклау – һәр шәкертнең изге бурычы. Махсус киеме, кәләпүше юк икән, ул дәрескә кертелми. Берәү әйтә:

– Питрәч районында бер мәчеткә кердем. Анда Сезнең элекке шәкертегез басып тора. *«Хәзер бит намаз вакыты түгел, нигә бу форманы киден?» – дип сорагач: «Әй, бәлки, Ильяс хәзрәт килеп керер!» – дигән җавап бирде»*, – ди.

Ул, бәлки, миннән куркуы турында шаяртып кына әйткәндер, әмма бу гадәт холкына гомерлеккә сеңеп кала. Без тәрбияләгән имамнар, мәҗлесләргә баргач та, урыс телендә түгел, ә туган телендә матур итеп сөйләячәк. Шулай итеп, мәдрәсә бусагасын атлап керү белән, кием шәкертне билгеле бер тәртипкә салырга тиеш. Татарның үз киеме бар. Без матур кием белән дә беренчеләрдән булган халык.

«Мәрҗани бернинди бәхәскә дә урын калдырмаган!»

Мәрҗани шигарендә өченчесе – гореф-гадәт. Ш.Мәрҗани хәзрәтләре беркайчан да исламга файда китерә торган гореф-гадәткә каршы килмәгән. Ул ата-бабаларыбыздан килгән, әмма динне саклауга сәбәпче булган бер генә нәрсәне дә инкяр итми. Бервакыт кабер ташы куярга һәм зиратка барып дога кылырга ярыймы-ярамыймы дигән бәхәсләр китте. Кайбер хәзрәтләребез, аеруча 1990 нчы елларда, ярамый, дип вәгазьләр дә сөйләделәр. Әгәр дә сине газиз әти-әниең үстергән, сиңа гомерен фида кылган, сине тәрбияләгән икән, син аның каберен зиярәт кылырга чирканырга тиешме? Син анда барудан оялырга тиешмени?! Хәтта әти-әниләр балаларына: «Мине матур итеп озатыгыз, миңа догачы булып калыгыз», – дип васыять әйтеп калдырырга тиеш.

Ш.Мәрҗани хаҗ сәфәре турындагы китабында, Гарәбстанга барып җиткәч: «Йәнбәгътә төрле җирләрдән килгән байтак мосафирлар илә күрешеп таныштык. Казаннан китеп Йәнбәгътә вафат булган хәйриячеләрдән хаҗи Хөсәен бине Йосыфның каберен сорашып, барып күрдек. Коръән укып багышладык. Аллаһы Тәгалә кабул итеп, рухын шат кылсын», – дип яза. Бу зат, Казанда Мәрҗани мәхәлләсенең тырыш байларыннан булып, үз акчасы илә ике кешене хаҗга алып барган һәм әлеге сәфәреннән кайтышлый 1864 елда вафат булган икән. Ошбу шәхеснең Мәрҗанинең үзенә дә ярдәм иткәнлеге «Мөстәфадел-әхбар»да язылган.

Икенчедән, Ш.Мәрҗани вафат булыр алдыннан үзенең шәкерте – мулла Гобәйдуллага: «Үлсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше генә күтәреп китәрлек булмасын. Һәм рус сүзе, рус елы куелмасын», – дип васыять әйтеп калдыра. Мәрҗани – әтисенә, әнисенә һәм күп кенә туганнарына кабер ташын үзе ясатып куйган кеше. Ул бу турыда китапларында язып калдыра. Мәрҗанинең әлеге ике дәлиле безгә дәрес түгелмени?! Гарәп илләрендә мәшһүр булган галим әлеге мәсьәләгә нокта куйган, бернинди бәхәскә дә урын калдырмаган!

«Татарлар бөтен төрки дөньяны Коръән укырга өйрәткән»

1990 нчы елларда шәкертләрне чит илгә җибәреп тә ялгыштык. Әти-әниләр дә 10-15 яшьлек балаларын чит илгә җибәрергә теләде. Балалар, анда барып җиткәч, кая килгәннәрен аңламадылар. Күбесе кире кайтырга мәҗбүр булды. Икенчедән, чит илдән килгән галимнәр, төрле фондлар, фиркаләр, мәдрәсәләр оештырды. Күп мөдәррисләр дә, тере гарәпне күргәч, аларны укытырга алырга ашыкты. Ул нинди фәннән, нинди максат белән укыта? Нинди мәзһәпкә таяна? Болар турында әллә

ни уйлап тормадылар. Бу хәл Россия буенча җәелде. 1997 елларда ата-ана – бала, өлкәннәр – яшьләр, җәмәгатьчелек – дәүләт арасында каршылыклар башланды. Ә бит, элеккегә әйләнеп карасак, үз вакытында Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Сөнгатулла Бикбулат, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәдһади Максудиларның бай дини мирасы булган икән! Алар төзеп калдырган уку программалары бибәһа бит! Әхмәдһади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл», «Мөгаллиме сани», «Гыйбадәте исламия» китапларын алыштырырлык хезмәтләр бүгенге көндә дә юк. Сөнгатулла Бикбулатның кыйраәт китабын Кавказда, Дагстанда укыганнар, андагы мөселманнар гарәп телен шушы дәреслектән өйрәнгәннәр. Әхмәдһади Максудиның китаплары миллионнарча тираж белән басылып, аның белән бөтен татар дөньясы, Урта Азия халыклары белем алган. Габдрахман Карабашның тәҗвиде бөтен төрки дөньяны Коръән укырга өйрәткән. Бу галимнәрнең барысы да – татарлар. Аларның китаплары үзебезнең җирлектә язылган! Хәтта бу хезмәтләр белән чит илләрдә дә белем бирелгән, аларның авторлары дөньякүләм мәшһүр, алыштыргысыз галимнәр саналган.

«Нәсел-нәсәбе белән горурланган кеше беркайчан да читкә тайпылмаячак»

Шундый бай мирасыбыз була торып, 1990 нчы елларда без яктылыкны читтән эзләгәнбез. Югыйсә, үзебездә китабы да, галимнәре дә җитәрлек булган. Тарикать әһелләре генә нинди мәртәбәгә ия! Мөхәммәдзакир Чистави-Камалов меңләгән шәкертләрне үз артыннан иярткән. Алар сәүдәсен дә алып барган, гыйлем дә биргән. Ә шәкертләре, хәзерге Татарстан җирендә генә калмыйча, хәтта Урта Азиягә, чит илләргә кадәр барып җиткән. Зәйнулла ишан Рәсүлев – нинди көчле шәхесләрнең берсе! Хәбибулла ишан Хансөярев Кулаткы, Зимничә төбәгендә күпме шәкертләр тәрбияләп калдырган.

Хәзер алда искә алынган галимнәребезнең мирасын барлау, тәҗрибәсен өйрәнү, каберләрен зиярәт кылу заманы килеп җитте. Ни өчен каберләрен дә барлау, дибез? Әгәр дә үз бөекләренең кабергә кадәрге хезмәтен танымаса, каберен белмәсә, аның рухына дога кылмаса, ул халыкның киләчәге юк.

Без шәкертләрне иң әүвәл әби-бабаңны, аларны дөньяга китергән затларны белергә өндибез. Араларында хәтта әбиләренең дә исемен белмәүчеләр очраштыргалый. «Әби – дәү әни инде ул», – ди. Үз шәҗәрәсен, нәсел-нәсәбен җиде буынга кадәр белгән, аның белән горурланган кеше беркайчан да читкә тайпылмаячак. Үзебезнең традицияләрне һәм тарихны өйрәнергә, шуларны онытмаска кирәк! Бездәге кебек иркенлек башка бер генә дәүләттә дә юктыр. Теләсәң, мәчеткә, мәдрәсәгә бар... Гыйлем алу өчен барлык мөмкинлекләр дә ачык. Үз остазыңны таба аласың... Әлбәттә, билгеле бер чикләрдән чыгып китәргә ярамый. Әбү-Хәнифә мәзһәбе бабаларыбыздан амәнәт булып килгән икән, без аны сакларга һәм киләчәк буынга тапшырырга тиеш! Хәнәфи мәзһәбе – башка дин һәм милләт кешеләре белән каршылыкка керми, алар белән дус-тату яшәргә өнди торган юнәлеш ул. Без күрше милләтләр белән дус яшәргә тиеш, әмма туганлашырга тиеш түгел! Катнаш никах булган очракта дин, милләт, балага исем кушу, сөннәткә утырту мәсьәләсе кискенләшә һәм боларның берсе дә татар халкы файдасына хәл ителми.

Динебезне, милләтебезне һәм, әлбәттә, ата-бабаларыбыздан килгән бай мирасыбызны саклыйк, аны киләчәк буынга җиткерик!

*Язманы журналга **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Татарның шәфкатьле улы

(Эдуард хаҗи Ганиевнең якты истәлегенә)

Али Хәбибуллин*

Һәрбер чорның үз мәшһүрләре дөньяга килә. XVIII гасырда – Батырша хәзрәт Галиев, XIX гасырда – Шиһабетдин Мәрҗани һәм Ризаэддин Фәхреддин, атаклы иганәчеләр Әхмәд, Гани һәм Мәхмүт бай Хөсәеновлар, Закир һәм Шакир Рәмиевләр, XX гасырда мәшһүр дин әһелләре Әббәс белән Мөкаддәс Бибарсовлар һәм башкалар туып, милләтебезгә игелекле хезмәт итте. Безнең чорның атаклы иганәчеләре арасында галим, электротехника фәннәр докторы, Россия электротехника академиясенең академигы, РФнең атказанган машина төзүчесе Эдуард Әнвәр улы Ганиевнең (1952-2019) дә исеме аерым урын алып тора.

Һәр шәхеснең тарихи әһәмияте үз халкының матди, рухи-әхлакый, мәдәни нигезен ныгытуга һәм үстерүгә керткән өлеше белән бәяләнә. Эдуард Ганиевнең мирасыбызны баетуга керткән хезмәте бәяләп бетергесез. Аның хәйриячелек өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйләгәндә, бу шәхеснең бетмәс рухи куәте, күңел байлыгы һәм киңкырлы фикерләве хакында уйланмый булдыра алмыйбыз.

Эдуард Әнвәр улы 1952 елның 15 гыйнварында Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткы районының Иске Мостяк авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Балачагы Муса, Иске Атлаш, Иске Мостяк авылларында үтә.

Эдуард Әнвәр улы балачактан ук җәмгыятькә файдалы кеше булырга дигән максат куя. Бу һич кенә дә очраклы түгел, чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) дә: *«Кешеләрнең иң яхшылары – кешеләргә файдалы булучылар»*, – дигән. Нәни Әнвәр, бабасы Исхак Хәбибулла улы һәм әбисе Бәхерниса Габдрахман кызыннан ишетеп, догалар ятлый, халкының гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын күңеленә сеңдерә.

1906 елда Иске Мостяк авылында, Сөләйман Сүнчәләев тырышлыгы һәм иганәсе белән, мөселман китапханәсе ачыла. 1930 нчы елларның ахырында монда тирә-яктагы татар авыллары өчен беренче урта совет мәктәбе оештырыла. Мәсум Ризван улы Ногаев (1919-1993), Хәйрулла Шәмсетдин улы Юсупов (1884-1952) кебек мәртәбәле мөгаллимнәрнең тырышлыгы белән, дистәләгән яңа буын укытучылары җитешә. Мәктәп үз укучыларында туган илгә, тарихка мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияли. Шуңа күрә дә бу уку йортын тәмамлаган шәхесләр арасында тарих фәннәре докторы, профессор Фрид Әйни улы Рәшитов, филология фәннәре кандидаты Мәвия Фатих улы Зәйнетдиновларның булуы очраклы

*Али хәзрәт Хәбибуллин – «Шәех Сәид» мәдрәсәсе директорының урынбасары, тарих фәннәре кандидаты.

түгел. Мостяк мәктәбендә Эдуард Ганиевнең әтисе – Әнвәр Исхак улы (1926-2012) да белем ала. Ул, Ульяновск педагогия институтын тәмамлап, 1955-1973 елларда Иске Атлаш мәктәбе директоры һәм тарих укытучысы, аннары Муса авылы мәктәбе директоры булып эшли. Әнвәр Исхак улының хатыны – Сафия Хәсән кызы да шул мәктәпләрдә башлангыч сыйныф балаларын укыта, китапханәдә хезмәт итә. Ганиевләр гаиләсендә дүрт бала дөньяга килә. Алар, барысы да, югары педагогик белем алып, халык арасында дәрәҗәле кешеләр булып үсәләр. Әнвәр Исхак улы балалары өчен дә, укучылары өчен дә бар яктан да үрнәк булып тора. Ул директор булган чорда Атлаш мәктәбендә югары квалификацияле педагогик коллектив туплана. 1967 елда урта мәктәп ачыла. Эдуард Әнвәр улы әлеге мәктәпне беренче чыгарылыш укучылары сафында көмеш медаль белән тәмамлый. 1968-1973 елларда ул, әтисенең һөнәрен сайлап, Ульяновск педагогия институтының физика-математика факультетында белем ала. 1973-1980 елларда Яңа Кулаткы авылының урта мәктәбендә директор һәм физика укытучысы булып эшли. Район хакимияте вәкилләре, кешеләр белән уртак тел табып, оештыра белү сәләтен күреп, аны Кулаткы район башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе итеп билгели. Эдуард Ганиев эшләгән вакытта районның мәдәни тормышы яңа көч ала: күп авылларда мәдәният йортларының яңа биналары төзелә, даими рәвештә үзешчән сәнгать коллективлары бәйгеләре һәм фестивальләре үткәрелә. Кулаткы районына Казан һәм Ульяновск калаларыннан атаклы артистлар, язучылар, шагыйрьләр, милли иҗат коллективлары еш килә башлый.

Эдуард хаҗи Ганиев

1983 елдан Э.Ганиевнең тормышында яңа этап башлана. Ул, Саратов шәһәренә күчеп китү белән, «Автоматика һәм телемеханика» заводында техник укыту һәм кадрлар бүлегенең җитәкчесе булып эшли башлый. 1984 елда заводның директор урынбасары итеп билгеләнә. 1993 елда федераль һәм өлкә хакимиятенең каршы фикеренә карамастан, коллектив тарафыннан заводның директоры итеп сайлана. Үзенә халык баглаган ышанычны Эдуард хаҗи тулысынча аклый. Шул елдан алып, хәйрияче Э.Ганиевнең алдагы юлы тәгаенләнә. Россиядәге эре сәнәгать оешмасы җитәкчесенең уңышлы эшчәнлеге кешеләргә файдалы булырга, мохтаҗларга ярдәм итәргә дигән рухи максатны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Илебезнең күп завод-фабрикалары таркалган вакытта Э.Ганиев, дөрес һәм урынлы ысуллар кулланып, җитештерүне саклап кала. 2000 елны ул заводны

акционерлаштыра һәм аның генераль директоры була. Заводның белгечләре әйтмешли, Эдуард Әнвәр улы җитештерүне оештыру һәм сату мәсьәләләрендә югары компетентлык, төгәллек һәм җитезлек күрсәтә.

Оста җитәкчелек иткәне, заводның тотрыклы эшләвен тәэмин итүе һәм җитештерү программасын уңышлы үтәве өчен, Эдуард Әнвәр улы РФнең «Почет билгесе» һәм Саратов өлкәсе губернаторының «Хөрмәт билгесе» орденнары белән бүләкләнә. 1999 елда Э.Ганиев иң уңышлы дәүләт предприятиесе җитәкчесе дип танылып, «Петр Великий» дипломына лаек була, завод чыгарган эшләнмәләр Россиянең һәм чит илләрнең югары бүләкләрен ала, алар арасында «Алтын пальма» да бар.

Эдуард Ганиев 2005 елның декабрь аенда «ГЭКСАР» электротехника заводының генераль директоры итеп сайлана. 2008 елгы кризис заводның үсешен дәвам итү өчен яңа ысуллар, юллар табу бурычын куя. Эдуард Әнвәр улы инновацияле технологияләр кертә һәм яңа уңышларга ирешә.

Ул үз кул астында эшләүче хезмәткәрләр өчен намус, эшкә сәләтлелек, җаваплылык үрнәге булып торды. Эдуард Әнвәр улы алардан тапшырылган эшләрне башкарып чыгуны, ахыргы нәтиҗәгә төгәл ирешүне таләп итте. Бер үк вакытта эшчеләрнең хокукларын да тулысынча саклады һәм яклады. Финанс ягыннан катлаулы булган 1990 нчы елларда да аның җитәкчелегендә эшләүчеләр хезмәт хакын вакытында алып килде. Аның өчен беренче урында табыш түгел, ә кешенең көндәлек ихтыяҗы тора иде. Завод хезмәткәрләренә лаеклы эш хакы түләнде, транспорт чыгымнары капланды, ашханәдә арзанлы ашату оештырылды... Эдуард Ганиев аларның шәхси тормышы белән даими кызыксына, күбесен фатирлар белән тәэмин итә, укулары, дәваланулары өчен акчасын кызганмый иде. Завод ветераннары да аның кайгыртуын һәрдаим тоеп яшәде.

Эдуард Әнвәр улы Саратовта эшләгән вакытта ук Иске Кулаткы районының тормышы белән даими кызыксынып торды. «Мин эшләмәсәм, кем эшләр соң?» дигән принципка таянып, ул туган ягының мәктәпләренә, мәчет-мәдрәсәләренә ярдәм күрсәтте.

2013 елның гыйнвар аеннан башлап Эдуард Әнвәр улы Иске Кулаткы районы башлыгы һәм җирле депутатлар шурасы рәисе булып эшли башлый. Бер үк вакытта «ГЭКСАР» электротехника заводының генераль директоры вазыйфасын да башкара. Алты ел дәвамында ул Ульяновск һәм Саратов өлкәләрендәге ике җаваплы эшне параллель алып бара. «Кешеләр өчен яшәргә, аларга файда китерергә» дигән тормыш принцибы аңа бетмәс-төкәнмәс дәрт, рухи көч бирә.

Эдуард Әнвәр улының кешеләр белән аралашканда үзен һәрвакыт гади, түбәнчелекле итеп тотуы безне таң калдыра иде. Район башлыгы буларак кына да аңарга көненә дистәләгән кешене кабул итәргә, зарларын тыңларга, канәгатьләндерергә туры килде. Эдуард Ганиев бөтен мәсьәләләрне урында, иртәгә калдырмыйча хәл итәргә дигән тормыш принцибы белән эш итте.

Ул Саратов шәһәренең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында да актив катнашты. 2008 елдан алып Эдуард Ганиев Саратов өлкәсенең Иҗтимагый палатасы әгъзасы, өлкә Диния нәзарәтенең Иҗтимагый шурасы башлыгы булып торды. Диния нәзарәтенең күп кенә мәдәни-агарту, мәгариф проектлары аның финанс ярдәме белән гамәлгә ашырылды, мөселман балалары өчен җәйге лагерьлар оештырылды. «Шәех Сәид» мәдрәсәсе хәзерге көндә дә уңышлы эшләвен дәвам итә.

Эдуард Әнвәр улы 2000 нче еллар башында Саратов Ислам комплексын төзүгә

Э.Ганиевнең әтисе Әнвәр һәм әнисе Сафия

үзеннән саллы өлеш кертте һәм бинаны тотуда гомере азагына кадәр даими рәвештә булышып торды. 2005 елда ул Дергач районы үзәгендә җәмигъ мәчетен торгызуда булыша, Вольск шәһәрендәге борынгы мәдрәсә бинасын сатып алып, аны мәчет карамагына кайтара.

2000 нче еллар уртасыннан алып, аның ярдәме белән, Иске Кулаткы районында мәчетләр торгызу һәм искеләрен төзекләндерү проектлары гамәлгә ашырыла, мәдрәсә һәм дини мәктәпләр төзелә. Районда аның кулы тимәгән бер генә мәчет тә калмый. Иске Кулаткыдагы «Гани» (2006) һәм «Әнвәр» (2014) мәчетләре, мәдрәсә бинасы (2015), Иске Мостяк мәчете һәм мәдрәсәсе (2008) тулысынча Эдуард хаҗинең хәләл акчасына салынды. Э.Ганиевнең башка дин һәм милләт кешеләренә дә мәрхәмәте, кылган игелеге чиксез иде. Иске Кулаткы районының бердәнбер чуаш авылында 2007 елда, иганәченең матди ярдәме белән, чиркәү торгызыла. 2010 елда район үзәгендә ташландык хәлдәге тулай торак бинасы төзекләндерелә һәм 2018 елда Ульяновск өлкәсе Диния нәзарәте карамагына тапшырыла. Хәзерге вакытта монда имамнар өчен укулар үтә, мәҗлесләр, балалар өчен җәйге лагерьлар оештырыла.

Эдуард Әнвәр улы ике дистә ел дәвамында Иске Кулаткы районының барлык

мәчетләрен дә даими кайгыртып тора. Ул мәчетләргә китаплар, уку әсбаплары сатып алуны, имамнар өчен җыеннар уздыруны, Болгар җыенына 600ләп якташын алып баруны, хаҗ сәфәренә ел саен 20-30 кеше җибәрүне, имамнарга хезмәт хакын түләүне, хәттә шәхси машиналар алып бирүне дә үзенең бурычы, изге вазыйфасы дип санады.

Элекке мөгаллим буларак, Э.Ганиев яшь буынны укыту һәм тәрбияләүнең, милли компонентлы мәктәпләрне саклап калуның әһәмиятен аңлап гамәл кылды. Саратов милли гимназиясе, Саратовның «Чишмә» татар балалар бакчасы, Иске Кулаткы мәктәпләре аның ярдәмен һәрдаим тоеп яшәде. 2005 елда Э.Ганиевнең акчасына Саратов милли гимназиясенең 3 нче катында капиталь төзекләндерү эшләре башкарылды, сыйныфлар җиһазландырылды. Саратов татар милли гимназиясендә ел саен «Идел буе халыклары: тарих, мәгариф, мәдәният» дип аталган өлкә укучылар конференциясе оештырылып килде.

Иске Кулаткы районының барча мәктәпләрендә 2006 елдан башлап үткәрелгән ремонт эшләренең чыгымнарын Э.Ганиев үзе күтәрде. 2014 елда Иске Атлаш урта мәктәбенә озак еллар көтеп алган газ кертелде.

Эдуард Ганиев Яңа Кулаткы мәктәбенең директоры булып эшләгән вакытта ук тарихи хәтерне саклау, укучыларында ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүгә зур игътибар бирә. 2000 нче еллар башыннан алып, аның матди ярдәме белән, төбәк тарихы өйрәнелә башлый, Иске Мостяк, Муса, Иске Атлаш, Усть Кулаткы һәм башка авыллар турында ике дистәдән артык китап басыла. 2005 елны Иске Кулаткы үзәгендә Җиңүнең 70 еллыгына багышланган мемориаль комплекс төзелә, һәйкәлләр булдырыла, хезмәт ветераннары хөрмәтенә «Дан аллеясы» ачыла. Шулай ук үзәк мәйданда хәрби очучы, Сириядә һәлак булган Россия Герое Рәфәгать Мәхмүт улы Хәбибуллинга багышлап мемориаль такта, ә җирле музейда почмак булдырыла. Э.Ганиев, район башлыгы булуга ук, төбәк тарихын өйрәнүчеләрне җыеп, алар алдында тарихи-мәдәни мирасыбызны саклау һәм пропагандалау бурычын куйды. Аның ярдәме белән музей өчен яңа экспонатлар алынды, барлык экспозицияләр тәртипкә китерелде һәм техник җиһазлар булдырылды.

Хәйриячеңең татар милли мәдәниятен үстерүгә һәм саклауга керткән ярдәме бәяләп бетергесез. Аның матди булышлыгы белән Саратов шәһәрендә һәм Ульяновск өлкәсендә, ел саен диярлек, Сабан туе бәйрәме уздырылды. 2016 елны Иске Кулаткы авылында Федераль Сабан туе үтте. 2008 елдан алып ел саен, Эдуард Ганиевнең ярдәме белән, «Түгәрәк уен» дип аталган Бөтенроссия фольклор фестивале оештырылып килде. Татар мәдәниятенең үсеше өчен районда бөтен шартлар да тудырылды: мәдәният йортлары җиһазландырылды, үзешчән коллективлар милли киемнәр белән тәэмин ителде, авылларда Татарстан артистларының концертлары үткәрелеп килде.

Эдуард Әнвәр улы якташларының сәламәтлеген дә кайгыртып яшәде. Иске Кулаткы районына кергән авылларда яңа медицина пунктлары төзелде, аларга газ кертелде. Район үзәге хастаханәсенең терапия бүлегенә капиталь ремонт ясалды, лифт куйдырылды, заманча җиһазлар алынды. Бу оешмалар ел саен кирәкле дарулар белән тәэмин ителеп килде. Әнвәр хаҗиның күп чирлеләргә үз игътибарын биргәне, аларны, кадерле вакытын сарыф итеп, хастаханәләргә йөрткәне, хәл-әхвәлләрен белергә шәхсән үзенең барганлыгы да сер түгел!

Ул, ихлас ышанып: «Мин кешеләргә күпме ярдәм итәм, Аллаһ миңа үзенең нигъмәтләрен шулхәтле күбәйтеп бирә», – дип кабатларга ярата иде. Бу сүзләр изге Коръәндәге: *«Аллаһ юлында биргән малның мисалы бер бөртек орлык кебек,*

Ульяновск өлкәсе губернаторы С.И.Морозов, РФ Дәүләт Думасы депутаты В.А.Третьяк, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатқы районы хакимият башлыгы Э.Ә.Ганиев һәм Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Р.З.Закиров Иске Кулаткыдагы татар балалар бакчасында. 2016 ел

ул орлыктан җиде башак үсәргә, һәр башакта йөзәр орлык булырга мөмкин. Аллаһ – үзе теләгән бәндәсенә җиде йөздән дә арттырып бирер. Аллаһ – киңлек иясе һәм барча нәрсәне белүче», – дигән юлларга туры килә (2:261).

Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин хәйрияче Эдуард Ганиевне, Россия ислам өммәтенең ихтыяҗларына игътибарлы, кешеләргә ярдәмчел булуына югары бәя биреп, «Әл-Фәхер» ордены белән бүләкләде. Ульяновск өлкәсе губернаторы да аңа «За веру и добродетель» дип аталган күкрәк билгесе тапшырды.

Ул үз туганнары белән гомере буе күркәм мөгамәләдә яшәде, аларга даими рәвештә барып, хәлләрен белеп, ярдәм күрсәтеп торды. Әти кеше буларак, гаиләсенең дә ныклы терәге иде ул. Эдуард хаҗиның балалары, бүген аталарының лаеклы дәвамчылары булып, аның эшен уңышлы дәвам итәләр.

Бик тыйнак кеше булганга, Эдуард Әнвәр улы эшләгән игелекләрне күрсәтергә тырышмады, бу аның эшләреннән күренде! Безнең бурыч – милләтебезнең әлеге тырыш улы һәм аның эшләре хакында бар белгәнебезне халыкка җиткерү. Аның кешеләргә, халкыбызның гореф-гадәтләренә һәм йолаларына, диненә, тарихына, теленә булган мөнәсәбәте, юмартлыгы, ярдәмчеллеге хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен олы бер үрнәк, гыйбрәт булып тора.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә: *«Бер кеше Аллаһ күрсәткән урыннарга садакалар бирсә, Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан сакланса һәм Аллаһының берлеген, исламның хаклыгын вә Коръәннең һәм пәйгамбәрнең хаклыгын тәсъдыйк кылса, аңа җиңеллек вә рәхәтлек урыны булган җәннәткә алып керүче гамәлләрне мийәссәр кылырбыз»,* – ди (92:5-7). Эдуард Әнвәр улын догаларыбыздан калдырмыйк. Милләттәшебезнең кылган игелекле гамәлләрен ешрак искә алсак иде! ■

Ринат Закиров

Җәлил хәзрәт Фазлыев

«Россиядә иганәчелек феномены: үткәне, буыннан-буынга күчеше, киләчәге» халыкара конференциясе

(Саратов, 8 февраль, 2020 ел)

Тәэминә Биктимирова, Фәния Хуҗахмәтова, Рәшит Минһаҗ

Ләбиб Лерон

Дамир Исхаков (сулда)

Татарстаннан килгән делегатлар

Рәфис Нуруллин фотолары

Безнең мирас №5 май 2020

ИГЕЛЕКЛЕ татар байлары

Тәэминә Биктимирова

Ятимнәргә, өлкән яшьтәгеләргә, фәкыйрьләргә һәм, болар өстенә, милләтебез файдасына үз малыннан өлеш чыгарып ярдәм итә белү – кеше күңеленең иң матур, иң җылы хиседер, мөгаен. Моңа кушып, шәфкатьле кешенең мәдәнияте югары дәрәҗәдә булуын да әйтергә кирәк. Мәдәниятсез кеше мәрхәмәтле була алмыйдыр.

Тарихыбызга күз салсак, халкыбызның борынгыдан килгән үзара ярдәмләшүенең, игелек кылуының матур үрнәкләрен күрергә була. Туй төшерү, өй салганда бураны күмәкләп – өмә ясап күтәрү кебек зур чыгымнар сорый торган эшләрдә туганнар, дуслар, авылдашлар ярдәмләшкән очраклар бар иде, диясе килә… Екатерина патшабикә мондый эшләргә рәсми төс бирүне дә кирәк тапкан. Аның 1775 елның 17 ноябрендә чыккан Указы нигезендә, Русиянең барлык губерналарында «Приказы общественного презрения» яисә «Авыруларга, ятимнәргә һәм ярлыларга ярдәм итүче оешма» төзү бурычы куела.

Казанда мондый оешма 1782 елда төзелә. Тиздән балалар өчен өч приют та ачыла. Алар, кем акчасына ачылган булуга карап, Николаев, Юнысовлар һәм Александров приютлары дип йөртеләләр.

БЕРТУГАН ЮНЫСОВЛАР

1844 елда эре фабрикант һәм сәүдәгәр, коммерция советниклары Ибраһим һәм Исхак Гобәйдулла улы Юнысовлар Печән базарында урнашкан һәм елына 14 мең сум табыш бирә торган кибетләрен мөселман балалары йорты чыгымнары өчен биргәннәр. Алар ачкан приют Казанда иң яхшы балалар йорты исәпләнгән. Татар байлары һәр балага, Николаев һәм Александров приютларына караганда, ике мәртәбә артыграк акча тапканнар. Биредә балалар, ашау-эчү, киенүдән тыш, бушлай белем дә алган. Приютның янында гына хастаханәсе булган. Атаклы медицина докторы А.Н.Казембек балаларның сәламәтлеге белән даими кызыксынып торган. Приют каршында мәктәп тә ачылып, замана өчен кирәкле дини һәм дөньяви белем дә бирелгән. Балалар арифметика, татар, рус, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнгән. Дәресләрне шул заманның атаклы педагоглары Сәгдетдин Үтәшев (имам), Хәсәнгата Габәши һәм Мөхетдин Корбангалиевләр алып барган.

Балалар йорты эшчәнлеген яхшы оештырулары өчен, Юнысовлар орден һәм медальләр белән бүләкләнгән. Моңа җавап итеп, алар һәр ел саен приютка 52 бала кабул итәргә йөкләмә алганнар.

Юнысовларның балалар йорты биналарының берсе әлегә кадәр сакланган (Тукай урамы, 89 йорт). Игелекле җан Ибраһим Юнысовның мәчет-мәдрәсәләр ачуы өстенә, 1838 елны халык өстенә төшкән ваба (чума) афәте вакытында үз хисабына хастаханә ачып, авыру мөселманнарны дәвалавын да искә алып, рәхмәтле булып, рухына дога кылыйк.

* * *

Шунысы мөһим: Юнысовлар кебек затлы, шәфкатьле шәхесләр аз булмаган татарда. Сәүдәгәр Госмановларны искә төшерик. 1891 елгы ачлыкта алар, йортларында ашханә ачып, 800дән алып 1000гә чаклы кешене көн саен бушка ашатканнар. (Йортлары исән, хәзерге К.Насыйри урамында).

Пләтән урамында эре сәүдәгәрләр Галиев, Апаков, Сәйдәшев һәм Үтәмешевләр ачкан ашханәнең берсендә – көн саен 300 кеше, икенчесендә тагын 1000 кеше тукланып, ач үлемнән котылган. Мондый мисаллар тагын бар әле... Ачлыкны Ходай күрсәтмәсен, әмма бүген шул хәл була калса, хәзерге байлар да шундый мәрхәмәтлелек күрсәтерләр дип кем генә ышана алыр икән?!

1898 елда, ниһаять, татарларга махсус «Мөселман хәйрия җәмгыятьләре» төзергә мөмкинлек ачыла (бергә булганда, татар акчасы кем файдасына тотылачагы билгеле инде).

Татарлар яшәгән барлык шәһәрләрдә һәм хәтта зуррак авылларда да төзелгән хәйрия җәмгыятьләрен, гадәттәгечә, татарның затлы, зыялы байлары җитәкли. Аларның тырышлыклары белән күпме мәчет һәм мәдрәсәләр корыла. Ул вакытта мәдрәсә төзетәсе килгән кешегә мәчет салдыру да мәҗбүри булган. Ни өчен мәдрәсәләргә игътибар зур булган соң татарда? Бердән, татар мәгарифе өчен патша хөкүмәте бер тиен дә акча бирмәгән, икенчедән, шәригатебез буенча наданлык зур хурлык саналган.

БЕРТУГАН ХӨСӘЕНОВЛАР

Оренбург хәйрия җәмгыятен оештыручы атаклы сәүдәгәр Хөсәеновларга татар мәгарифенә ярдәм оештыру эшендә дөньяда тиңнәр булырмы икән?! Төрле төбәкләрдә 40тан артык мәчет-мәдрәсә салдырып, 200ләп мәктәп-мәдрәсәне уку әсбаплары белән тәэмин итү, 40лап яңа ысул белән укытучы мөгаллимгә эш хакы түләү, Петербург, Мәскәү, Сарытау, Томск, Каһирә, Бәйрут, Истамбул һәм Европа шәһәрләренең уку йортларына ел саен 20дән артык татар яшьләрен җибәреп, аларның укуы өчен матди шартлар тудыру – болар атаклы иганәчеләр эшләгән изге эшләрнең бик азы гына.

Әхмәт байның Казандагы йорты хәзер дә исән, Мәрҗани урамында, бүгенге байлар барып карый ала. Өстәп шуны әйтеп үтик: чит ил университетларында укып кайткан егетләр «Хөсәения» мәдрәсәсендә дүрт ел буе дәрес бирергә тиеш булганнар.

Шунысы сокландыра: Хөсәеновлар егетләрдән төрле фәннәрне өйрәтү белән бергә, дәүләт төзелеше һәм җәмәгать эшләре буенча да белем алуны таләп иткәннәр. Мөгаен, бу аларның мөстәкыйль дәүләт төзергә өметләнеп, шуңа белгечләр әзерләүләре булгандыр!

Мондый белгечләрнең исемнәрен санасам, язмам бик зурга китәр иде. Кызыксынучылар булса, олуг галимәбез Мәдинә Рәхимкулованың 1997 елда Оренбургта чыккан «Медресе «Хусаиния» в Оренбурге» дигән китабын укый ала. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә университет дәрәҗәсендә белем бирелүен совет хөкүмәте дә танырга мәҗбүр була.

Мәдрәсәдә төрле фәннәр өчен аерым кабинетлар, яхшы җиһазландырылган лабораторияләр, рус, татар һәм гарәп телләреннән тыш, инглиз, француз, немец телләрендәге әдәбият, газета-журналлар тупланган бай китапханә була. Болар барысы да Хөсәеновлар акчасына оештырыла.

Казанда яшәгән Әхмәт бай Хөсәенов, туганы Мәхмүт белән, Казан губернасында

Мәрхүм Мәхмүт бай Хөсәенов (10 август 1910 сәнәдә вафат)

10 ел эчендә 20 мәчет һәм мәдрәсә салдыра һәм бу биналарның барлык чыгымнарын үз өсләренә ала. Казан губернасыннан тыш, алар мәктәпләрне Мәкәрҗә, Эрбет, Түбән Новгород ярминкәләрендә һәм Сәмәрканд, Коканд, Мәккә шәһәрләрендә дә ача. 1901-1902 уку елында Гани бай Оренбургта кыз балалар өчен җәдитчә мәктәп оештыра. Әлеге мәктәпне мөгаллимә Фатыйма Әдһәмова җитәкли, ә кызлары Хәдичә белән Зәйнәп рус теле һәм география фәннәрен укыта.

Мондый изге эшкә тотынганда бертуган Әхмәт, Мәхмүт һәм Габделгани Хөсәеновларның максатлары, әлбәттә, халыкка хезмәт итү булган. Аларның сәүдәгәр буларак та бик матур нәтиҗәләргә ирешкәннәрен, сәүдәләрендә хәтта бүгенге кебек карточка системасын да гамәлгә кертә алганнарын беләбез.

БЕРТУГАН ЯУШЕВЛАР

Троицкида яшәүче Яушевлар (чыгышлары белән Әтнә районының Иске Мәңгәр авылыннан) төзегән ширкәтнең офислары Мәскәү, Варшава, Троицк, Чиләбе, Оренбург, Кустанай, Ташкент, Әүлия-Ата, Токмак кебек шәһәрләрдә ачылган. Болар өстенә, аларның ерак дала ягында оештырылган җиде ярминкәдә һәм Кытайның Голҗа шәһәрендә дә даими сәүдә үзәкләре булган. 1898 елда иң элек алар Троицк шәһәрендә «Җәмгыяте хәйрия»гә нигез салалар. Габделвәли Яушев – җәмгыятьнең рәисе, аның бертуган энесе Муллагали әлеге җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы, ятим балалар өчен ачылган приютлар эше комиссиясе җитәкчесе, Кустанай шәһәрендә хәйрия җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм Троицк өязе төрмәләренең попечителе була. I Бөтендөнья сугышы башлангач, Троицк шәһәрендә яралы сугышчылар өчен Яушевлар акчасына лазарет төзелә һәм алар акчасына тотыла.

Яушевлар мәдрәсәләрне Урал тауларының түбәнге өлешендә урнашкан барлык шәһәрләрдә дә диярлек салалар. 1900 елда бертуганнарның Төркестанда атаклы төрки шагыйрь Әхмәд Ясәвинең (11 йөзнең ахыры-1166) төрбәсен төзекләндерүгә 82 мең сум акча бирүләре, Муллагали ярдәме белән казакъ телендә беренче әдәби журнал чыга башлавы, 1893 елда Габделвәли акчасына 1000 данәдә «Хәдисләр җыентыгы» да басылып чыгуы – аларның игелекләренә дәлил. Иганәчеләр ярдәме белән Троицк, Верхнеуральск, Кустанай шәһәрләрендә һәм өязләрендә яңача укыта торган мәктәпләр ачыла. 1915 елда Муллагали Яушев акчасына татар ир балалары өчен педагогик училище – дарелмөгаллимин, мәрхүм энеләре Мөхәммәтшәрифнең хатыны Гайния Баһаветдин кызы акчасына кыз балалар өчен шундый училище – дарелмөгаллимат ачылган.

Алгарак китеп әйтим, Гайния ханым Октябрь революциясеннән соң Харбинга китеп урнаша. Яңа төзелгән Татарстан автономияле республикасында 1920-1921 елларда коточкыч ачлык башлангач, ул, Ризаэддин Фәхреддингә хат язып, мөгаллимнәрнең адресларын сорый. Адресларын алгач, 15 мөгаллимгә икешәр потлы посылкалар җибәрә. Бу хәл ничә тапкыр кабатлангандыр – төгәл билгеле түгел, әмма, архивлардагы документларга караганда, бер генә тапкыр булмагандыр дияргә нигез бар. Урыны җәннәттә булсын!

Яушевларда милли хис-тойгыларның көчле булуын аларның 1905, 1917 еллардагы Мөселманнар съездында катнашулары да күрсәтеп тора. Алай гына да түгел, Муллагали Яушевның олы улы Октябрь революциясе башлану белән Германиягә китә. Анда ул немец кызына өйләнә, зур байлык туплый, Бөек Ватан сугышы чорында Муса Җәлил төзегән оешмага ярдәм итеп тора. Соңыннан туганнары, бу турыда ишетеп, хәйран кала.

ФАТИХА АИТОВА

Хәйриячелек, бигрәк тә татар мәгарифенә ярдәм итү эшеннән хатын-кызлар да читтә калмаган. Менә әле күптән түгел генә Казанның 12 нче кызлар гимназиясендә Яушевлар гаиләсендә туып үскән мәгърифәтче Фатиха Габделвәли кызы Яушева-Аитовага багышланган музей ачылды.

Заманында француз гувернанткаларында тәрбияләнеп, яхшы белем алган Фатиха 18 яшендә Казан бае Сөләйман Аитовка кияүгә чыга. Сөләйманга да иганәчелек эше чит түгел. Аның Казан мәчет-мәдрәсәләренә, ятимнәргә даими ярдәм итүе, шәһәрдә холера авыруы башлангач, тиз генә хастаханә төзетеп, бөтен чыгымнарын

үз өстенә алуы һәм башка игелекле эшләре тарихта билгеле.

Фатиха ире Сөләйман белән Сукно бистәсендә 1897 елгы ачлыкта ятимә һәм ярлы кыз балалар өчен һөнәр мәктәбе ача. Кызлар бу икееллык мәктәптә тегү, чигү, бәйләү, мех теркәү һәм кәвеш, чүәкләр эшләп чыгарырга өйрәнәләр. Күбесе, ул эшләнмәләрне сатып, ач үлемнән котыла. Мәктәпнең бинасын да үзләре төзетә, материалларына, өйрәтүчеләргә дә акчаны Аитовлар түли.

Фатиха Аитова энесе Муллагали Яушев белән. 1914 ел

1909 елда Екатеринская (хәзерге Тукай) урамында 4 еллык мәктәп ачыла һәм соңрак ул 9 еллыкка әйләнә. Мәктәпнең бинасын төзетүдән алып, башка бөтен чыгымнарын Фатиха Аитова үз өстенә ала. Мәктәптә рус гимназияләренә хас программа белән укыталар. Дини һәм дөньяви фәннәрдән тыш, биредә аш-су, йорт эшләре осталары да әзерләнә. Фатиха һәм Сөләйман Аитовлар, өч ел рәттән Берлин, Вена, Прага шәһәрләренә барып, андагы уку йортларына кереп, уку әсбаплары алып кайталар. Әлеге хәл Фатиха апаның татар кызлары өчен Европа дәрәҗәсендәге уку йорты, ягъни гимназия ачу теләге барлыгын күрсәтеп тора бит! (Телевизордан бер тапшыру тыңлаган идем. Анда Башкортстанда татар мәктәпләре өчен дәреслекләр җитешми, дип зарландылар. Ходаем, шул ярдәмне оештырырлык та байларыбыз юкмы безнең?!)

1916 елның 29 октябрендә татар мәгарифе тарихында беренче тапкыр ачылган кызлар гимназиясе бинасын да үз акчасына салдыра бу игелекле җан. Кызларга махсус формалар, калфакларны үзе тектерә. Ярлырак балаларга уку бушлай була. Иң яхшы белемле укытучылар чакырыла аларга. Хәтта җәй айлары өчен дә яхшы хезмәт хакы түләнә, театрларга, экскурсияләргә бергәләп барулар оештырыла. Күренекле язучы Фатих Әмирхан белән очрашу кичәсе дә кызлар хәтерендә матур бер истәлек булып кала. Татарның җырчы сандугачлары Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова, Мәрьям Рахманкуловалар – Фатиха Аитова мәктәбе укучылары.

СУФИЯ ҖАНТУРИНА

Кызлар өчен мәктәпләр салуда Фатиха Аитова ялгыз түгел. Бу уңайдан әле күпләребезгә билгеле булмаган, әмма милләтебез файдасына кылган гүзәл эшләре белән сокландырган Суфия бикә Җантуринаны да искә алу урынлы булыр.

Чыгышы белән атаклы Тәфкилевләргә барып тоташа ул. Күп кенә морза гаиләләрендә урнашкан гадәт буенча, Суфия рус мохитенә якынрак шартларда тәрбия-

ләнә. Әмма әнисе Хәдичә бикә кызларына мөмкин кадәр ислам дине, милли тәрбия бирергә тырышкан.

Балигъ булгач, Суфия милләте буенча казакъ, әмма гомере буе Уфада торып татарча тәрбия алган, Петербург университетын тәмамлаган юрист Сәлимгәрәй Җантуринга кияүгә чыга. Алар бәхетле пар булалар. Икесе дә рус телен камил белгән, әмма гаиләдә гел татарча гына сөйләшкәннәр.

Үз утарлары урнашкан Килем авылында белем бирүнең бик түбән дәрәҗәдә булуына борчыла Суфия. Борчылып кына калмаган, Иж-Буби мәдрәсәсенә барып, уку тәртипләрен өйрәнә, андагы өметле берничә шәкертне мөгаллим итеп чакыра. Шулай итеп, ир балалар өчен яңача белем бирә торган мәктәп ачыла. Мөгаллимнәргә хезмәт хакын, мәктәпнең бөтен чыгымнарын Суфия үзе күтәрә.

Ул кыз балаларны да онытмый. Алар өчен дә үз акчасына мәктәп оештыра. Алай гына да түгел, кыз балалар өчен туку остаханәсен дә ача әле. Петербургка барып, өч ай буе туку станокларында эшләү серләрен өйрәнә һәм 24 станок алып кайта. Шул рәвешле, кызларны һөнәрле итеп калдыра.

Уфаның атаклы «Галия» мәдрәсәсен төзетүдә дә Җантуриннарның өлеше зур. Безгә билгеле булган мәгълүматларга караганда, Суфияның мәчет төзелешенә биргән акчасы 50 мең сумга җиткән. Мәдрәсә идарәсен Сәлимгәрәй җитәкләгән һәм шәкертләргә бушлай белем алырга мөмкинлек тудыруга ирешкән. Россиядә әледән-әле кабатланып торган ачлык елларында да мескеннәргә ярдәме зур була Суфияның.

Истамбулга киткәндә, үзен озатыр өчен Уфа вокзалына төшкән олы улына үзәк өзгеч сүзләрен әйтә ул: «Балам, син яшьсең әле, – ди, – мин сине бүтән күрә алмам инде. Минем сиңа актык сүзем, изге киңәшем: син татар углы бул, татарыңны сөй, татарыңны онытма!»

Суфия үз куллары белән язган васыятьнамәсендә «Галия» мәдрәсәсенә – 10 мең сум, аның китапханәсенә – 500 сум, Килем авылы мәдрәсәләренә – 5 мең сум акча һәм 200 дисәтинә җирен калдыруын әйтә. Бу акчаның хәзерге миллионнарга бәрабәр икәнен беләсездер инде.

Ни кызганыч, Суфия Җантурина 1911 елның 28 декабрендә нибары 37 яшендә Истамбул шәһәрендәге йортында вафат була.

* * *

Милләтебезнең киләчәге хакында уйласак, әле искә алган гүзәл шәхесләребезгә мохтаҗлыгыбыз аңлашыла кебек. Мин хәзерге байларыбызны: «Алардан үрнәк алыгыз!» – дип өндәүдән тыелып торам. Шулай да халкыбызның «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигән мәкале барлыгын искә төшерик әле. Милләтебезгә хәзерге көндә дә мәгариф, медицина өлкәсендә ярдәм артык булмас иде. Тик аның өчен, әйткәнемчә, шәфкатьле-миһербанлы булу кирәк!

Сүземне замандашыбыз, күренекле әдип Марсель Галиевнең шигъри юллары белән тәмамлыйм:

Ут хәтере гөлтләп сүнсә, су хәтере кала –
Су сүрәсен аңлап, сабак алырбызмы?
Ходай биргән милләт дигән таҗны җуеп,
Киләчәккә гидай булып барырбызмы?!
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?! ■

КИЧӘ, БҮГЕН ҺӘМ ИРТӘГӘ

Индус Таһиров

Сүз башында язмамның югалткан, табылган һәм табылырга мөмкин кыйммәтләребез турында икәнлеген искәртеп китү урынлы булыр. Чөнки безнең күргәннәребез дә, күрәчәкләребез дә бер-берсенә бәйле. Үткәнебез безне бүгенге көнебезгә китерде, ә бүгенге көн иртәгәбезне билгели.

Иң зур югалтуларыбызның беренчесе – 1552 елны Казаныбызның яулап алынуы, дәүләтебезне югалту. Югалту никадәр авыр булса да, кайтаруы аннан да авыррак. Шушы коллык чорында «күпме михнәт чиккән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән». Тукай бу сүзләрне үзе дә канлы күз яшьләре белән язган.

Кичә бөек булып, ничәмә-ничә шанлы дәүләт оештыра алган халыкның канына сеңгән шул дәүләтчелек. Ул һәрвакыт үзен сиздерә килгән. Татарларның башка халыкларга ярдәм кулы суза килүләре, алар арасында аң-белем таратулары да юкка гына түгел. Ул әнә шул дәүләти канның хәрәкәттә булуына бер дәлил. Бу кан буыннан-буынга бирелә килгән һәм үзе өчен бик зур авырлыклар туганда да,

А.Биктимиров фотосы

Мирсәет Солтангалиев. 14 декабрь, 1928 ел

үзен ныклап сиздерә-белдерә, аның татарлыгын уята торган көч булган.

Ул бигрәк тә тарихның кискен борылышлары вакытында хәрәкәткә килә, аның дәүләти тойгыларын уята.

Беренче рус революциясе, Тукаебыз язганча, уятты татарны бишенче елның бер таңында. Әйе, бу революция татарның милли аңын уятты, аның максатын ачыкларга мөмкинлекләр ачты.

1917 елдагы революцияләр дә, аларга бүгенге көндә тискәре караш булуына да карамастан, татарга, гомумән, Россиянең рус булмаган милләтләренә шактый файдалы булды. Беренчедән, Советларның III Бөтенрусия съезды кабул иткән «Изелгән һәм эксплуатацияләнгән халыклар декларациясе»ндә Россия ирекле халыкларның республикалары нигезендә төзелгән федерация дип игълан ителде. Бу документның соңгы пунктында шушы Федерациягә керү ирекле, республикалар анда катнашу принципларын үзләре билгеләргә тиеш икәнлеге ачыктан-ачык күрсәтелгән. Дөрес, бу федерация, илдә большевиклар диктатурасы урнашу сәбәпле, гамәлгә ашмады. Шушы документ нигезендә барлыкка килгән республикалар гадәти административ территориаль берәмлек кенә булып калдылар. Татарстан Республикасы да хокукый яктан Россиянең өлкә һәм крайларыннан аерылып тормады. Ул телсез дә, динсез дә, милексез дә иде.

Ләкин 1920 елда бу республиканың барлыкка килүе татар халкына дәүләтчелеген торгызу өчен тарихи мөмкинлек бирде. Шушы курчак республиканы суверен дәүләткә әверелдерүгә юл ачылды. Әгәр шул автономияле республика барлыкка килмәгән булса, 1990 елның 30 августында кабул ителгән суверенлык декларациясе дә булмас иде.

Шулай да татар халкының, автономияле республикага гына риза булмыйча, СССР барлыкка килгән 1922 елдан башлап ук үз республикасын союздаш итү өчен көрәш башлап җибәргәнлеген дә, әлеге көрәшнең башында торган Мирсәет Солтангалиев аның беренче корбаны икәнлеген дә онытырга ярамый. 1936 елгы Сталин Конституциясен кабул итү чорында да Татарстанны һәм Башкортстанны союздаш республикага әверелдерү өчен талпынулар булды. Тик ул вакытта татарларны сөйми торган Сталин: «Татарии и Башкирии статуса союзной республики не видать как своих ушей», – дигән.

1977 елгы Брежнев Конституциясе кабул ителгән вакытта да Татарстанны союздаш республикага әверелдерү мәсьәләсе күтәрелгән иде, ләкин моңа да колак салучы булмады.

Әмма халыкта Татарстанны союздаш республикага әверелдерү дәрте сүнмәде. Илдә үзгәртеп кору процессы башлангач, бу дәрт өр-яңа дәрманга төренде. Беренче буларак, әлеге идеяне Казан дәүләт университеты доценты Марат Мөлеков төзегән Татар иҗтимагый үзәге күтәреп чыкты. Республика җитәкчелеге шулай ук бу идеяне хуплады. Татарстан Республикасының Югары Советы 1990 елның 30 августында

суверенлык декларациясен кабул итте. Бу документта Татарстанның Россия составында икәнлеге күрсәтелмәде. Чөнки Татарстан, аңа таянып, яңа Союз договорына мөстәкыйль рәвештә кул куюны максат итте. Шушы максат СССР тарихына «особая позиция Татарстана» дигән атама белән кереп калды.

Декларация кабул ителгән көннәрдә республика халкы, умарта иле кебек, гөрләп-гөжләп торды. Урамнарыбыз, мәйданнарыбыз халык белән тулы иде. Халык депутатлардан гаделлек декларациясен кабул итүне таләп итте. Милиция кордоннары куелган булуга да карамастан, халык Ирек мәйданыннан таралмады. Аның күпчелеге төннәрен дә шунда үткәрде. Казан татарлары аларга ризык ташып торды. Җир шарының төрле почмакларындагы татарлар, төннәрен йокламастан, Казан белән аралашып, андагы хәлләр белән кызыксынып, милләттәшләренә дәрт һәм дәрман бирео торды. Бу көннәрдә бөтен татар дөньясы бер йодрыкка тупланды.

Югары Совет рәисе М.Ш.Шәймиев Башкортстан Югары Советы рәисе М.Г.Рәхимов белән аралашып торды. Ул бервакыт башкорт коллегасына Ирек мәйданы тулы халык икәнлеген, анда ачлык тотучылар да булуын хәбәр иткәч, Рәхимов: «Их, менә бездә дә шулай булса иде», – дип уфтанган. Һәм, өстәп, Шәймиевкә: «Бу синең файдага», – дигән. Әйе, ул көннәрдә халык һәм хакимият бер фикердә иде. Нәкъ менә шушы бердәмлек тиешле эчтәлектәге декларация кабул итүгә төп сәбәп булды да инде. Мондый егетлекне тик дәүләти халык кына булдыра ала.

Чыннан да, әгәр дә Уфа мәйданнарын да халык каплап алган булса, анда да, тиешле эчтәлектәге декларация кабул итүне таләп итеп, ачлык игълан итүчеләр булса, бәлки, Башкортстанда да безнекенә охшаш декларация барлыкка килер иде.

Ә бит мондый мөмкинлек бар иде. Бу очракта Казанга Башкортстанның Россия составында икәнлеге күрсәтелмәгән, тулы суверенлык декларациясенең проекты килеп ирешкәнлеген әйтеп китү урынлы булыр. Аның эчтәлеге хәтта безнең проекттан да тулырак иде.

Үзебезнең декларациябез кабул ителгәч, М.Ш.Шәймиев шул вакыттагы Татарстан өлкә комитетының идеология буенча сәркатибе Р.Р.Идиатуллинны һәм мине Уфага җибәрде. «Татарстанга көрәштәшләр кирәк», – диде ул. Һәм без, Уфага барып, анда Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары Мансур Әюпов, КПССның Башкортстан өлкә комитетының идеология буенча сәркатибе Роберт Янбарисов белән очраштык. Башкортларның шундый декларациягә хаклы икәнлекләре турында фикер алыштык. Чыннан да, бу эш барып чыкса, ул тик гаделлекне торгызу гына булыр иде. Эш менә нәрсәдән гыйбарәт.

Билгеле ки, Башкортстан Республикасы 1917 елның декаберендә үк игълан ителә. 1919 елның мартында Совет хөкүмәте, шушы республиканың хөкүмәте белән, башкорт гаскәрен Колчак ягыннан кызыллар ягына күчерү бәрабәренә, республиканы тану турындагы килешү төзергә мәҗбүр була. Аның нигезендә Башкортстанның үз гаскәре, башка илләр белән аралашу ведомствосы булуы һәм аның яшәешнең бик күп өлкәләрендәге мөстәкыйльлеге танылa. Тик күп тә үтмәстән, Совет хөкүмәте шушы документны берьяклы рәвештә юкка чыгара.

Менә ни өчен башкортлар өчен тулы канлы декларация кабул итү үткәндәге гаделлекне торгызу гына булыр иде. Ләкин, ни кызганыч, бу эш барып чыкмады. Башкортстан Татарстанныкы кебек декларация кабул итә алмады, чөнки бу эштә халык катнашмады: мәйданнар кайнамады, Югары Совет исеменә бәйсезлекне таләп иткән мөрәҗәгатьләр һәм хатлар яумады, ачлык тотучылар да булмады.

Ә без ялгыз калдык. Бервакытны Минтимер Шәрипович, уфтанып:

– Их, союзникларсыз калдык бит, – диде.

Ш.Кармышаков фотосы

Азатлыкка таба...

Мин аңа:

– Минтимер Шәрипович, башкортлар моның белән берни дә югалтмадылар, – дидем.

Ул:

– Ничек югалтмасыннар? – диде.

Мин Башкортстанның һәм башка республикаларның Россия составына ирекле рәвештә керүләренең 400 еллыгын тантаналы рәвештә үткәргәнлекләрен аның исенә төшердем. Алар шул көннәрне орден-медальләр һәм тагын әллә нинди өстенлекләр алдылар, дидем.

– Ә без? – диде ул.

– Безнекеләр, ягъни татарлар, беркайчан да Россиягә ирекле рәвештә керүләрен танымадылар. Әгәр дә без Татарстанның Россия составында икәнлеген күрсәткән декларация кабул иткән булсак, бу беренче шундый документ булачак иде. Юк, Сез бәхетле кеше, Минтимер Шәрипович. Сез имзалаган документ – чын-чынлап халык теләгән документ.

Бу Россия җитәкчелеген зур борчуга салды. Декларация кабул ителеп бер ел үткәч, Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм Россия Президенты Борис Николаевич Ельцин, Союз килешүенә Татарстанның ни рәвештә кул куярга тиешлеген билгеләү өчен ике делегация төзеп, аларны 1991 елның 12 августында Мәскәүнең Ак йортында сөйләшүләр өстәле артына утырттылар. Россия делегациясенең җитәкчесе Г.Э.Бурбулис булып, Татарстан делегациясенең башлыгы итеп В.Н.Лихачев билгеләнде. Аның урынбасары вазыйфалары шушы юлларның авторына йөкләнгән иде.

Сөйләшүләр 15 август көнне уңышлы тәмамланып, аның нәтиҗәсендә уртак кабул ителде. Анда моннан соң Россия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрнең тик ике яклы килешүгә генә корылган булырга тиешлеге күрсәтелгән. Менә шушы документ Россиянең конституцион-килешүле федерациягә әверелә башлавына юл ачты. Татарстанның яңа Союз

килешүен имзалау мәсьәләсенә актык ноктаны Ельцин белән Шәймиев куярга тиеш иде. Ләкин... Әйе, мин кабат шушы сүзне кулланырга мәҗбүрмен һәм менә ни өчен: ике Президентның очрашуы 19 август көнне кичке сәгать дүрткә билгеләнгән иде. Тик аларга бу көнне очрашу насыйп булмады. Шәймиев Ак йортка сөйләшкән вакытта килгән булса да, анда Ельцинны очрата алмый. Геннадий Бурбулис, Ельцинның дачасыннан шалтыратып, аның очрашуга килә алмавын хәбәр итә. Сәбәбе – ГКЧП фетнәсе башлану.

Тиздән КПСС юкка чыга, СССР таркала. Шулай итеп, Татарстанга союздаш республикага әверелү өчен өч көн җитми кала. Аяныч ки, без өйләнгәч кенә төн кыскарды, дигәндәй, тиешле гамәлебезне кылып бетермәстән, СССРның кояшы сүнде, Россиянең исә, таңы атты. Әгәр без Союз килешүенә кул куеп өлгергән булсак, СССР таркалса да ярый иде. Без, башка союздаш республикалар кебек, бәйсез дәүләт була идек. Тик менә бөек халыкның язмышы авыр була шул. Безгә бәйсезлек юлыбызны авыр һәм сикәлтәле юллар кичеп дәвам итәргә туры килде.

1992 елның 21 мартында үткәрелгән референдум үзе генә дә ни тора! Ул көннәрдә Татарстанга янаулар, телевидение, радио, газеталар аша таратылган коткылар... Россия Югары Советының махсус машиналары Татарстан шәһәрләренә төрле рәвештәге куркыту-янау белән сугарылган листовка һәм прокламацияләр таратып йөрделәр. Кешеләрнең почта тартмалары шулар белән шыплап тула иде. Россиянең Конституция суды Татарстанда референдум үткәрүгә каршы карар чыгарды. РСФСР Югары Советының махсус сессиясе шушы мәсьәләгә багышланды. Анда Конституция судының рәисе Валерий Зорькин: «Әгәр дә референдум нәтиҗәсендә куелган сорауга «әйе» дигән җавап алына икән, бу Татарстанның бәйсезлеген игълан итү өчен нигез булачак», – дип куркытты. Тагын, өстәп, болай диде: «Так будет считать любой юрист и будет прав». Бу инде Татарстан Россияне тарката, шунлыктан, аның кыла торган гамәлләрен туктатыгыз дигән кисәтү иде. Россиянең беренче җитәкчеләре үзләре татарлар белән урыслар арасына чөй кагу эшенә керештеләр. Хәтта «Мин Горбачев ясаган хаталарны ясамам», «Берите суверенитета столько, сколько сможете проглотить» дигән Ельцин да телевидение аша Татарстандагы русларны: «Әгәр дә референдум уңай нәтиҗә бирсә, иртәгәсен икенче сортлы гражданнарга әвереләчәксез», – дип куркытты. Россия прокуратурасы Татарстандагы прокурорларга сайлау участокларын ачтырмаска дигән боерык бирде. Россия Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатов, Татарстан чигендәге Волжск шәһәренә килеп, референдум нәтиҗәләрен көтеп торды. Әгәр дә Татарстан сайлаучылары куелган сорауга «юк» дип җавап биргән булсалар, Хасбулатов Шәймиевне, үзе әйтмешли, тимер читлеккә утыртып, Мәскәүгә алып китәргә тиеш булган. Тик менә бернигә дә карамастан, сайлаучыларның 61,4 проценты Татарстанның суверенлык статусын яклап чыкты.

Референдум Декларацияне халык фикере белән ныгытты, аңа яшәү көче өрде. Димәк, В.Зорькинның сүзләренә таянып әйткәндә, Татарстан законлы рәвештә үзенең тулы бәйсезлеген игълан итү хокукын яулаган булып чыга.

Әлбәттә, Татарстан өчен бүгеннән тулы бәйсезлек игълан итү мөмкин булмас иде. Чечня мисалы моны яхшы раслый. Ә бит Самарада Татарстанга гаскәр кертү планы әзер булган. Анда танклар озатуындагы гаскәр Казанның кайсы урамнарыннан үтеп, нинди бина һәм учреждениеләрне алырга тиешлеге тәфсилләп күрсәтелгән. Әгәр дә Татарстанда нинди дә булса милләтара ыгы-зыгы чыга калса, бу план, һичшиксез, хәрәкәткә килгән булыр иде. Ләкин Татарстан җитәкчеләренең, аның Президенты Минтимер Шәймиевнең зур зирәклек һәм батырлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә, бу

план тормышка ашмады. Республикада тынычлык һәм милләтара татулык хөкем сөрде. Нәтиҗәдә, Мәскәү белән сөйләшүләрне дәвам итүгә юл ачылды.

Референдумнан соң нәкъ ун көн үтүгә, 31 март көнне делегацияләр яңадан өстәл артына утырдылар. Бу көнне Мәскәүдә Федератив килешүгә кул кую тантаналары да булып үтте. Мәгьлүм ки, Татарстан аңа катнашудан баш тарткан иде. Безгә Федератив килешү түгел, махсус статусыбызны билгеләп торган ике яклы килешү генә кирәк иде. Дөресен әйткәндә, безгә ияреп, Башкортстан һәм Саха-Якутия Республикаларының да аны имзалаудан баш тартуларына өметләнгән идек. Чөнки бу республикаларның җитәкчеләре шул рәвештәге белдерүләр дә ясаган иде. Тик алай булып чыкмады, Мәскәү, бу республикаларга кайбер өстенлекләр вәгъдә итеп, аларны Федератив килешүне имзаларга күндерде.

Тик без моның шулай икәнлеген көннең икенче яртысында гына аңладык. Шулай да бездә ниндидер шик-шөбһә бар иде. Сөйләшүләр бер ун минутка соңга калып башланды, чөнки Г.Э.Бурбулис юк иде. Без, делегациябез җитәкчесе В.Н.Лихачев белән икәү, коридорга чыгып, Бурбулис кабинеты янына килсәк, ишек төбендә Башкортстан җитәкчеләре басып торганын күрдек. Сүз катмадык, алар безне, без аларны күрмәмешкә салыштык. Ә көннең икенче яртысында Федераль хөкүмәтнең Башкортстан җитәкчелеге белән махсус килешү төзегәнлеге мәгълүм булды. Башкортстанга биргән вәгъдә шул булып чыкты. Россия җитәкчелеге шушы ике республиканың һәм башкаларның Татарстан артыннан баруыннан бик нык курыккан. Моның шулай икәнлеге Бурбулистан күренә иде. Гадәттә, үз-үзен кулда нык тота торган бу кеше шактый дулкынланган иде. Моны исәнләшкән вакытта куллары салкын тирдә булуыннан да чамалап була иде. Аның, Татарстанның абруе зур икәнлегенә басым ясап: «Татарстан задает некий нравственный вектор, за которым следуют другие», – дигән сүзләре моның чыннан да шулай икәнлеген раслады. Ул хәтта Федератив килешүне имзалау тантанасының бик күркәм үтәчәгенә дә, аннан соң мул банкет буласына да, зур бүләкләр биреләчәгенә дә ишарә ясады. «Теләсәгез, сез дә катнаша аласыз!» – диде Бурбулис.

Очрашу әллә ни уңышлы үтте, дип әйтә алмас идем. Чөнки Конституция судының карары Россия җитәкчелегенең кул-аягына богау салган иде. Шулай да, кыска гына беркетмә кабул иттек. Анда Татарстанның махсус статуста булырга тиешлеге билгеләнгән иде. Документның проектын тикшергәндә, бер эпизод булып алды. Анда шушы статусның Россия Федерациясендә икәнлеген күрсәткән «В составе Российской Федерации» дигән сүзләр бар иде. Бу сүзләр безнең Декларациябезгә, референдум нәтиҗәләренә каршы килгәнлектән, мин аларны алып ташлау тәкъдимен керттем. Россия ягы килеште һәм, алай булгач, «субъект международных отношений» сүзләрен дә алып ташлыйк, диделәр. Мин ризалаштым һәм документ шушы рәвештә кабул ителде. Лихачев, соңыннан минем янга килеп: «Вот, Индус Ризакович, из-за Вас мы лишились международной правосубъектности», – диде. Ә Татарстан хөкүмәте башлыгы Мөхәммәт Галләмович Сабиров, яныма килеп, «рәхмәт», дип, кулымны кысты. Ул, әлбәттә, Россия составында итеп күрсәтелмәү принцибының үз эченә әнә шул «субъект международного права»ны да ала икәнлеген яхшы аңлый иде.

Моның белән Лихачевка нинди дә булса күләгә төшерәсем килми, ул, делегация җитәкчесе буларак, үзен лаеклы тотты, үзенең яхшы юрист һәм дипломат икәнлеген исбат итте.

Безгә Россия делегациясе белән тагын күп мәртәбә очрашырга туры килде. Төрле рәвештәге сөйләшүләр алып бардык. Тик бу язманың максаты моны тәфсилләп сөйләүдә түгел. Бу очракта безнең өчен иң әһәмиятлесе – аларның нәтиҗәсен

билгеләргә тырышу. Төп нәтиҗә – 1994 елның 15 февралендә имзаланган ике яклы Шартнамә.

Бу елны инде мин кемнеңдер (соңрак «кемнеңдер»нең В.А.Тишков икәнлеге ачыкланды) таләбе нигезендә сөйләшүләрдән читләштерелгән идем. Шунлыктан, аның соңгы проектын күргәч, зур ризасызлык белдердем. Чөнки бу сөйләшүләр нәтиҗәсеннән шактый чигенү иде. Җитәкчеләребезнең иртәгә Мәскәүгә аны имзаларга китәчәген белгәч, мин Кремльгә Президентыбызны күрергә дип килдем. Тик аны туры китерә алмадым. Шуннан соң Югары Совет рәисе Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшинга барып, аңа үземнең шигемне белдердем. Ул бу турыда ачыктан-ачык әйтмәсә дә, минем белән килешкән булса кирәк. Чөнки Минтимер Шәрипович соңрак: «Син аны шулкадәр кыздыргансың ки, без самолетта юл буе бәхәсләшеп бардык!» – диде.

Ләкин имзаланган ике яклы Шартнамәнең хикмәте, беренчедән, аның дәүләтара булуында, икенчедән, унитар идарә итү системасын селкетеп, гомумән, Россияне демократик рельсларга күчерүче документ икәнлегендә. Татарстан үзенең шушы гамәле белән Россиягә чын федерациягә әверелү юлын ачты. Әлбәттә, Шартнамәдә Татарстанның хокуклары күбрәк күрсәтелсә, бигрәк тә яхшы буласы иде. Тик менә моңарчы бөтен вәкаләтләрне үзендә туплаган унитар дәүләтнең мөстәкыйльлек дәгъва иткән Татарстан белән вәкаләтләр бүлешүе ул республикабызның суверенлыгын өлешле рәвештә тануга бәрабәр иде.

Татарстанга ияреп, башка республика һәм өлкәләр дә Федераль үзәктән Татарстанныкына охшаган шартнамәләр булдыруны таләп итә башлады. Нәтиҗәдә, Федераль үзәкнең төбәкләр белән төзегән кырыкка якын шартнамәсе барлыкка килде. Чыннан да, Бурбулисның: *«Татарстан задает некий нравственный вектор, за которым следуют другие»*, – дигән сүзләре дөрес булып чыкты. Татарстан Россия төбәкләренең лидерына әйләнде. Ә Россия үзе тиз рәвештә чын федерациягә әверелә башлады.

Ләкин рус менталитеты моңа протест белдерде. Чөнки ничәмә йөз еллар буе формалашкан империячел яшәеш һәм аңа хас булган империячел холык, аның сыйфатлары берничә ел эчендә генә үзгәрә алмый. Ул менталитетның нигезе хакында Казан университеты профессоры **Н.Фирсов** 1869 елда ук болай дип язган: *«...известная вещь, что у нас относительно украин* (бу очракта бу сүз ил кырыен, рус булмаган милләтләр яшәгән җирләрне аңлата. – ***И.Т.***)*, пользовавшихся особыми правами, всегда существовали две партии, из которых одна стояла за решительные меры к слитию этих украин с Великороссийскими областями посредством подведения их под одинаковые законы, управление и суд, а другие надеялись возбудить в этих, вошедших в состав Русского государства, украинцах чувство приязни и расположения к Русской власти и Русскому государству посредством охранения их особенных прав и льгот»*.

Галимнең: *«Центральная власть в России не любит, как известно, таких подданных, которые жили не по ее законам и указаниям»*, – дигән сүзләре бүген бигрәк тә актуаль яңгырый. Чөнки хәзерге вазгыять бу сүзләрнең дөреслеген раслый.

Шунлыктан, империячел сыйфатлар һәм холык демократик процессларны туктатуны, һич булмаса, акрынайтуны таләп итә. Шовинистлар кемнәрнеңдер башка кануннарга таянып яшәүләрен кабул итә алмыйлар, катгый рәвештә Россия җитәкчелегенә каты кул килүне таләп итәләр.

Менә ни өчен В.В.Путин хакимияткә килгәч, республикаларның суверенлыгына, Үзәк хакимиятнең федерация субъектлары белән төзегән шартнамәләренә һөҗүм башланды. Алар юкка чыкты, әмма без, зур авырлыклар белән булса да, Үзәк белән шартнамәле мөнәсәбәтләребезне саклап кала алдык. Мироновлар һәм

Ирек мәйданында ирек даулаганда...

Жириновскийларның каршы килүләренә дә карамастан, 2007 елның июнендә яңа Шартнамә барлыкка килде.

Дөрес, ул республикабыз өчен ниндидер икътисади өстенлекләр бирә торган документ түгел иде. Безнең өчен аның җисеме түгел, исеме әһәмиятле. Ул Татарстанның шартнамәле махсус статустагы республика икәнлеген билгеләгән документ иде.

Бүген Россия килешүләр принцибына нокта куйды. Шуның белән аның өчен үз Конституциясенең дә канун түгел икәнлеге мәгълүм булды. Милли телләргә богау салуы нәкъ менә шул турыда сөйли. Республикаларны бетерүгә булган омтылышлар да күзгә күренеп тора. Кайбер шовинистларның бу эшне Татарстаннан башларга кирәк дигән өндәүләре юкка гына түгел.

Путин: «Республикаларга тимибез, алар исән калачак», – ди. Ләкин бу сүзләргә ышанып яшәү зур хата булыр иде. Бүгенге көндә республикабызны саклау, аның суверенлыгын аныклау һәм яклау эшләрен без үзебез генә башкарып чыга алабыз. Беренчедән, бездән халыкара нормаларга таянып эш итү таләп ителә. Берләшкән Милләтләр Оешмасының «Кешенең икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклары» Пактының беренче маддәсендә болай дип язылган: *«Все народы имеют право на самоопределение. В силу этого права они свободно устанавливают свой политический статус и свободно обеспечивают свое экономическое, социальное и культурное развитие...», «государства, участвующие в ней должны в соответствии с положениями Устава, уважать это право на самоопределение»*. Россия – шушы Пактны имзалаган дәүләт. Моны һич кенә дә онытырга һәм оныттырырга ярамый.

Инде әйтеп үтелгәнчә, Татарстан, Декларация кабул итү һәм референдум үткәрү нәтиҗәсендә, үзбилгеләнү хокукын гамәлләштергән дәүләткә әверелде. Соңгы 2007 елгы Шартнамәнең кереш өлешендә Россия тарафыннан Татарстанда үткәрелгән референдумның танылуы акка кара белән язылган. Шартнамә үзе юкка чыккан булса да, референдумның танылуы хак. Аны берничек тә юк итеп булмый. Ә ул республикага, Зорькин сүзләре белән әйткәндә, Татарстанга тулы бәйсезлек игълан итү мөмкинлеген бирә.

Тик беркем дә курыкмасын, Татарстанның беркайчан да Россиядән чыгу максатын куйганы юк. Чөнки Россиянең бөтенлеге милләтебезнең бөтенлегенә тәңгәл.

Күренә ки, республикабызны саклау һәм яклау өчен безнең бөтен мөмкинлекләребез бар. Аларны хәрәкәткә китерү безнең үзебездән генә тора. Бергә булсак,

«Ислам динен олылагыз!»

Мәдинә Әбделганиева, Мөхтәрәмә Сәхапова

Газиз әтиебез Хәниф Мөхәммәтвәли улы 1903 елда Чирмешән районының Югары Чагадай авылында туган. Әнисе – Иске Үтәмеш авылыннан Ишмөхәммәт углы Хәсәншаның кызы Миңнегаян 1919 елда 36 яшендә вафат була. Хәтерләүчеләр аны күркәм холыклы, ак, матур йөзле, юмарт һәм кече күңелле иде, дип искә алалар иде. Әтиебез Хәниф 1910-1921 нче елларда мәдрәсәдә белем ала. 1924 елда ул Югары Чагадай кызы Мөнәвәрә белән гаилә кора.

1925 елда гаскәри хезмәткә алынып, Армавир һәм Новороссийск шәһәрләрендә 22 нче Краснодар дивизиясенең 64 нче укчы полкындагы беренче ротада хезмәт итә. Армиядән кайткач, 1931 елга кадәр игенчелек белән шөгыльләнә. 1931 елдан Чирмешәндәге «Заготконтора»да авыл хуҗалыгы азыкларын әзерләү, кабул итү һөнәрен үзләштереп, аларны киң күләмдә җитештереп, завод-фабрикаларга һәм хәрби оешмаларга озатуда үзенең зур тырышлыгын, оештыру сәләтен күрсәтә.

38 яшьлек Хәниф Вәлиев

Хәниф Вәлиев гаиләсе. Югары Чагадай, 1952 ел

«Заготконтора»ның хисапчы-бухгалтеры вазыйфасын башкара. 1959 елга кадәр шул оешмада эшли.

Әтиебез чын мәгънәсендә камил кеше иде. Гадел, алдынгы карашлы, һәр өлкәдән хәбәрдар, пөхтә, иманлы, уңган ир, яхшы ата, әткәсенә тәрбияле ул, ярдәмчел... Безгә калса, бөтен уңай сыйфатлар әтигә туры килә. Балаларына һәрвакыт файдалы гыйлем алырга, тормыш итәрлек китап укырга киңәш итә иде ул. Әти – Чирмешәндә радио алган беренче кеше. «Новое время» журналына кадәр яздырта иде ул. Шкафы дөньяви һәм дини китаплар белән тулы иде аның.

Әти бик пөхтә, чиста кеше иде. Безгә дә: «Киемнәрегезне чиста тотыгыз, аяк киемнәрегезне юыгыз. Сез пөхтә йөрсәгез, мин ике адым артык атламам», – дип, безне чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтә иде.

Югары Чагадай авылындагы бу йортта совет чорында җомга намазлары укыла иде. Йорттан Таһирә абыстай Фәхруллина чыгып килә

«Хәниф Вәлиев – совет чорында ислам мирасын саклауда һәм аны яшь буынга тапшыруда зур роль уйнаган мәгърифәтче һәм елъязмачы. Шундый шәхесләр булганга, ислам дине совет чорында сакланып калган да инде. Беренче чиратта, гаиләдә, туганнар һәм авылдашлар арасында… Хәниф Вәлиев мисалында әйтсәк, Вәлиевләр гаиләсендә, Мөхәммәдәмин нәселендә һәм Чирмешән районының Югары Чагадай кешеләре арасында.

Хәниф Вәлиев, Утыз Имәни, Ризаэддин Фәхреддин, Галимҗан Баруди, Габдрахман Рәсүлиләрнең һәм башкаларның дини мәгърифәтчелек эшен район дәрәҗәсендә алып барган шәхес. Ул совет атеизмы чорында, үзен куркыныч астына куеп, дини китаплар әзерли, элекке кульязмаларны яндырмыйча саклый, милли тарихны барлап, шәҗәрәләр әзерләп калдыра».

Александр Далматов-Долгов

Әтиебез иртәнге дүртләрдә азан әйтеп, намаз укып, эшкә чыгып китә иде. Без дә, аңа ияреп, намаз укый идек. Сугыштан соң әти авылның шәҗәрәсен төзи башлады. Аның өчен, әллә кайлардан гыйлемле картларны алып кайтып, айлар буе бездә яшәтә, алар сөйләгәнне язып бара иде. Өстәле тулы кәгазь өелеп торганы аеруча истә калган.

Әтиебезнең язма мирасын туганнарыбызга, якташларыбызга җиткерүне 1990 елда ук башладык. «Югары Чагадай авылының төп тарихы. Шәҗәрәләр» дип аталган кульязмасын иске имлядан күчереп, китап итеп бастырып, авылыбыз халкына тараткан идек. 30 ел вакыт үтеп тә китте, ә шәҗәрәләр белән кызыксыну арта гына бара. Хәтта башка төбәкләр һәм чит илләрдән дә нәсел очларын, җепләрен табучылар бар. Дистәләгән хатлар алдык. Рәхмәт сүзләре әле дә килеп тора. Шәҗәрәләр китабын сорыйлар, үтенеп сорыйлар. Димәк, ихтыяҗ бар!

Әтиебез Хәниф гомере буе ислам гыйлемен өйрәнде. Дин тыелган 1945-1957 елларда гакыйдә – иман, фикһ – ислам хокукы һәм сира – пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) тормыш юлына багышланган китаплар, вәгазьләр әзерләде. Алар барысы да шәригать кануннарын тирәнтен өйрәнү нигезендә, ышанычлы чыганаклардан файдаланып язылган. 2015 елда, шәҗәрәләр белән бергә, аларны да гарәп имлясыннан күчереп, «Югары Чагадай мирасы» исемле саллы динитарихи китап чыгару бәхетенә ирештек.

Ул, дин белән бергә, дөньяви фәннәрне дә өйрәнде, бигрәк тә бакчачылык темасын ярата иде. Бакча белән шөгыльләнгәндә, Мичурин томнарын ныклап өйрәнде. Татарстанда үсүче барлык төр җиләк-җимеш агачлары да безнең бакчада бар иде. Алмагачларның саны гына да 182гә җитте. «Бар көчемне бакчага салдым», – дия иде ул. Әти, пенсиягә чыккач, бакчабызда хозурланып яшәргә хыяллана иде, ләкин насыйп булмады.

Әти белән әнинең мөнәсәбәтләре шулкадәр мәхәббәтле, матур, әнигә киңәшләрне шундый зирәк итеп бирә иде ки, без шакката идек. Берсендә әни ямьсез савытка гөл утырткан, ә әти бөтен эштә матурлыкны ярата. Шунда әти әнигә: «И, Мөнәвәрә, астында бәрәңгесе, өстендә башагы юк. Аның гөл булгач, савыты да матур булырга тиеш», – дип куйды. Әни исә сабырлыгы белән аерылып тора иде. Әтинең сүзен шундук аңлап, гөлне матур савытка күчереп утыртты.

Әтиебез 1959 елның 29 октябрендә 56 яшендә вафат булды. Урыны оҗмахта булсын! ■

Саумы, ураза!

Хәниф Вәлиев

Игътибарыгызга Хәниф Вәлиев кулъязмаларыннан уразага багышланган бер бүлекне тәкъдим итәбез. Кем белә, Чирмешән районының Югары Чагадай һәм күрше-тирә авыллар халкы, дин катгый тыелган елларда, нәкъ менә әлеге язмаларга нигезләнеп, ислам дине йолаларын башкарганнардыр һәм аның иң мөһим баганаларыннан берсе булган уразаны калдырмый тотканнардыр! Хәзерге заман укучысы өчен әлеге мәкаләдә әллә ни яңалык та булмаска мөмкин, әмма ул совет чорында дин исламны яшерен генә булса да саклау һәм пропагандалауда, һичшиксез, мөһим роль уйнаган.

Редакция

Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан алып кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – акылы булган һәрбер мөэмин бәндәгә фарыздыр.

Хәниф Вәлиевнең кулъязма мирасы

Уразаның фарыз булуы турында Коръәни-кәримнең «Бәкарә» сүрәсендә (183 нче аять) Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Әй, иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды, уразаларыгызны тотыгыз, шаять, котылучылардан булырсыз»*.

Хәдис шәриф:

«Һәрнәрсәнең зәкяте, ягъни пакьләүчесе бардыр. Тәннең зәкяте – ураза».

Уразаның фарызлары өчәү:

1 нчесе – ният кылу;

2 нчесе – ашау-эчүдән тыелу;

3 нчесе – якынлык кылудан тыелу.

Ураза өчен сәхәр ашаганнан соң, таң атканчы ният кылу – мөстәхәбтер. Өйлә вакытына бер сәгать чамасы калганчы ният кылынса да, дөрес булыр. Өйлә вакытына бер сәгать чамасы гына калгач, ният кылу ярамас.

Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу җитәдер. Тел белән һичбер сүз әйтмәсә дә, күңеленнән иртәгә ураза тотачакмын дип уйласа, ураза дөрестер. Әмма гарәпчә ошбу сүзләрне әйтеп, тел белән ният кылу мөстәхәбтер:

«Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләәһи Тәгалә».

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән, таң вакытыннан башлап кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым»*.

Кояш баткач, көнлек уразаны тәмамлаганда ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу сөннәт санала. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу — мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачкач) ошбу дога укыла:

«Аллааһуммә ләкә сумтү үә бикә әәмәңтү үә гәләйкә тәүәккәлтү үә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффаару мә каддәмтү үә мәә әххәртү».

Мәгънәсе: *«Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Һәм Синең ризалыгың белән авыз ачам. И, гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, инде минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка»*.

Ураза тоткан кешегә мондый эшләр сөннәт булып санала:

1 нчесе – таң атканчы, төнлә торып сәхәр ашау;

2 нчесе – ураза тотып, нәфесне гөнаһлы эшләрдән тыюны ният кылу;

3 нчесе – кәсептән бушаган вакытларда дини китаплар уку;

4 нчесе – кояш баегач, ахшам намазын укыганчы авыз ачу.

Ураза вакытында көндезен ошбу 10 төрле эшне кылу мәкруһ санала:

1 нчесе – файдасыз сүзләр сөйләү;

2 нчесе – әдәпсез сүзләр сөйләү;

3 нчесе – мунчага кереп, озак утыру;

4 нчесе – суга чумып коену;

5 нчесе – ризык һәм сагыз чәйнәү;

6 нчысы – берәр азыкка телне тидереп татып карау;

7 нчесе – иреннән үбү;

8 нчесе – ифтар кылмыйча, ике көн рәттән ураза тоту;

9 нчысы – ни булса да бер гөнаһлы гамәл кылу;

10 нчысы – авыруның артачагын белә торып ураза тоту.

Ураза тоткан кешегә ошбу 10 төрле эшне башкару дөрес санала:

1 нчесе – сатып алыначак малны татып карау;
2 нчесе – балага ризык чәйнәп бирү;
3 нчесе – күзгә сөрмә тарту;
4 нчесе – мыек һәм иренне майлау;
5 нчесе – тешләрне пакьләү;
6 нчысы – кан алдыру;
7 нчесе – сөлек салдыру;
8 нчесе – комган белән госел коену;
9 нчысы – мунчага кереп, аягүрә тирләп чыгу;
10 нчысы – сабын белән юыну.

Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:
1 нчесе – борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару кабу;
2 нчесе – бер тамчы кадәр генә булса да, су йоту:
3 нчесе – якынлык кылу.

«Һәрвакыт Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән ислам дине эчендә булып, Раббыбызның барлык кушкан әмерләрен үтәп, тыйганнарыннан тыелырга васыять әйтәм.

Шулай ук ислам дине гыйлемен һәм дөньяви гыйлемне өйрәнегез. Һәрвакытта ислам динен хөрмәтләгез, олылагыз.

Миннән калган дини китапларны һич таратмыйча саклагыз. Аларны укырга өйрәнеп, шәригать юлларына төшенегез.

Хак юлда ихласлыгыгызны ныгытыгыз».

Хәниф Вәлиевнең балаларына васыятеннән

Рамазан уразасын үз ихтыяры белән бозган кешегә һәр көн урынына бер көн каза кылу һәм бозган өчен кәффарәт кылу фарыз була.

Ураза кәффарәте өчен бер колны азат итү тиешле. Әгәр кол табылмаса яки аны сатып алырга байлыгы җитмәсә, 60 көн бер тоташтан ураза тоту тиешле була. Әгәр дә зәгыйфьлек сәбәпле 60 көн ураза тотарга куәте җитмәсә, 60 фәкыйрьне тукланырлык итеп ашату тиешле була.

Ураза тоткан кеше хаталык белән бераз аш йә су йотса яки бугазына кар һәм яңгыр тамчылары керсә, яисә ихтыяры белән авызын тутырып косса, таң аткан булса да, таң атмагандыр дип белеп сәхәр ашаса, кояш батмаган булса да, кояш баткандыр дип белеп, авыз ачса яки якынлыктан госелсез булса, уразасы бозыла. Андый кешегә Рамазан ае үткәннән соң уразасын каза кылу тиешле була, ә кәффарәт тиеш түгел.

Бер кеше, ураза икәнен онытып, ашаса яки эчсә, уразасы бозылмый.

Бер кешенең бугазына тузан, туфрак, йон йә төтен керсә яки бер кеше төкреген йә какрыгын яки теш арасында калган ризык кисәген йотса, уразасы бозылмый.

Ураза тотарга көче җитмәгән бик зәгыйфь, карт кеше ураза тотмаса, һәр көннең уразасы урынына бер фәкыйрьне тукланырлык итеп аш ашатырга яки ризык алырга җитәрлек акча бирергә тиеш.

Әгәр Рамазан аеннан соң шул карт сәламәтләнсә, калган уразасын каза кылырга тиеш.

Йөкле яки бала имезә торган хатыннар ураза тоткан вакытта үзләренә йә балаларына зарар килүдән һәм, шулай ук, хаста кешеләр үзләренең авырулары көчәюдән курыксалар, ураза тотмасалар да дөрес була. Аларның һәркайсы калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиеш. ■

Безнең мирас №5 май 2020

Үтәмеш зиратының КАБЕР ТАШЛАРЫ

Резеда Исхакова

2018 елны Татарстан Республикасының Тәтеш районындагы Үтәмеш авылында яшәүче якташларыбыз, зираттагы борынгы ташларны өйрәнүне сорап, төбәкне өйрәнүче Нияз Фәтхелислам улы Исхаковка мөрәҗәгать итте. Илдус һәм Алсу Халиковлар, сакланып калган дүрт ташны фотога төшереп, Санкт-Петербургка җибәрде. Шулай итеп, Үтәмештәге эпиграфик ядкәрләр белән кызыксыну башланып китте.

* * *

Үтәмеш авылында моннан 200 ел чамасы элек үк мәрхүмнәрне җирләү өчен инештән иң ерак булган урында җир бүлеп бирелә. Зиратка беренче мәрхүм кайчан күмелгәнлеге турында төгәл әйтүе кыен, әмма 1833 елда мәчет мулласы Минуш Мостай углының, метрика кенәгәләре язып, анда бакый дөньяга күчкәннәрне аерым биткә махсус теркәп барганлыгы билгеле. 1898 елга Үтәмеш авылы инде шактый зураеп, анда меңнән артык кеше яшәгән. Бу елларда авылның зираты да зур булган дип чамаларга була. Мәрхүмнәрне җирләгәч, Үтәмешкә кабер ташларын ерактан ук алып кайтканнар. Мондый ташларны үз туганнарының кабере өстенә куйдырту бөтен кешенең дә хәленнән килмәгән. Мөгаен, күпләр өчен кабергә мәрхүмнең һәм аның әтисенең исемен, вафат булган датасын язып, кадап куела торган такта яки бүрәнә кисәге бердәнбер һәм озак сакланмаган «һәйкәл» булгандыр.

Бөек Ватан сугышы тәмамланганда Нияз Исхаковка ун яшь була. Гаилә авыл



Сембер губернасының топографик картасында Үтәмеш авылы һәм аның тирә-ягы. А.И.Менде атласыннан. 1861 ел

читендәге йортта яши. Аларның бәрәңге утырта торган җирләре зират белән чиктәш. Шулайук колхоз фермасы белән ат абзары да зират читендә генә урнашкан. Кич белән, көтү кайткан саен, маллар зират янынннан уза торган була. Зират киртә белән уратып алынмаган булу сәбәпле, хайваннар шунда кереп, кабер ташларына ышкынган, мөгезләрен шомарткан, сирень куакларын сындырган. Күп еллар үткәннән соң, Нияз Фәтхелислам улы, балалык еллары турында: «Боларның барысын да искә төшереп йөрәк кысылып куйды, әмма ул вакытта бу хәлләргә каршы тора алырлык чаралар күрү мөмкинлеге юк иде», – дип әйтә.

Сугыш һәм аннан соңгы еллар халык тормышында гаять авыр чор булган. Зиратка ачлыктан һәм төрле авырулардан һәлак булган мәрхүмнәр күпләп җирләнгән. Соңрак, маллар кереп таптый торгач, зират урынында атлар утлап йөри торган ялан кыр барлыкка килә. Ерактан караганда, маллар чирәм өстендә генә утлап йөргән кебек тоелса да, чынлыкта алар каберләр өстен таптый иде. Нәкъ шул вакытта Үтәмеш зиратындагы борынгы кабер ташлары да юкка чыкты – җимерелеп, тапталып бетте. Шулай итеп, җирле халык сөйләменә «кабер өсте», ягъни гүрстан, зират өстендә урнашкан урынны белдерә торган атама килеп керә.

Дөрес, соңгы елларда зиратның барлык территориясе дә киртә белән әйләндереп алынды, халыкның матди хәле, тарихи, мәдәни мираска, ата-бабаларыбызның якты рухына мөнәсәбәте үзгәрде.

Безгә XIX гасыр һәм 20 нче йөз башында куелган кабер ташларын укырга Казан ислам университетының дини фәннәр кафедрасындагы өлкән укытучы Нурислам хәзрәт Әбсәләмов ярдәм итте.

Габделгафур Габделнәсыр углына куелган таш

Үтәмеш зиратында сакланып калган иң борынгы кабер ташы чагыштырмача кечкенә, ул уалучан известьташтан эшләнгән һәм начар сакланган. Ташның өске өлеше түгәрәк һәм анда турыпочмак рәвешендә уенты-чокыр ясалган. Бу, яңгыр сулары җыелып, матур сайрый торган кошлар шунда килеп су эчсен һәм тирә-як җәннәт бакчасын хәтерләтсен өчен махсус шулай эшләнгән. Кабер ташының алгы ягына тупас кына итеп *«1889 нчы (елда) мартның 8ендә мәрхүм Габделгафур Габделнәсыр»*; ә арткы ягына *«углы. Гафу ителсен»* дип язылган.

Метрика кенәгәсендә бу кешенең 65 яшендә бакый дөньяга күчүе хакында мәгълүмат бар. Димәк, ул 1824 елда дөньяга килгән. Әгәр аның хәзерге көндә нәсел дәвамчылары булса, мөгаен, аларны Гафуров яки Насыйров фамилияле гаиләләрдән эзләргә кирәктер. Мәгълүм ки, совет хакимиятенең беренче унъеллыгында гаилә хәле актларын теркәү вакытында шәҗәрәгә тирән төшеп тормаганнар, еш кына фамилия итеп кешенең әтисе исемен генә язып куйганнар.

Гөлихан бинтү Сәбиткә куелган кабер ташы

2 нче кабер ташы да тәбәнәк, өсте ярымтүгәрәк, читләре тигез, өсте яхшы шомартылган. Таштагы затлы, зәвыклы язу безгә билгесез останың шактый тәҗрибәле ташчы һәм хаттат булганлыгы хакында сөйли. Ташның иң өстенә күпертмә хәрефләр белән Коръәннән *«Күллү нәфсин зәикатү әлмәүт»*, ягъни *«Барча кеше үлем ачысын татыр»* дигән аять язып куелган. Шунда ук ислам символы – ярымай һәм борынгы болгар кабер ташлары өчен традицион орнамент – чәчәк рәсеме ясалган. Алга таба, ташның алгы ягына гарәби хәрефләр белән, уеп: *«Тарих вафат 1895 (ел) гыйнвар 4ендә»*, – дип, мәрхүмнең бакый дөньяга китү датасы; арткы ягына да, уеп: *«Гөлихан бинтү Сәбит (Сәбит кызы Гөлихан) дәру-л-фәнән дәру-л-бәкая (бетү йортыннан калу йортына) рихләт әйләде (күчеп китте) 40 яшендә»*, – дип язылган.

Әлеге зиннәтле кабер ташын кем заказ биреп эшләткән? Бәлки, ул яраткан хатынын югалткан ир булгандыр? Яки кызның әтиседер? Бу сорауга төгәл җавап юк, әмма метрика кенәгәләре мәрхүмәнең тормыш юлына кайбер ачыклыклар кертә. 1871 елда 18 яшьлек Гөлихан Сәбит кызы Әхмәтша Таҗетдин улына кияүгә чыга. Бер елдан соң аларның Рәхилә исемле кызлары туа. Кызга ун ай тулган мәлдә ире талак әйтә һәм, озак та үтми, башка чибәркәй белән никах укыта. Бала әтисе белән кала, әмма озак яшәми – ике яшендә вафат була. Аерылышканнан соң, Гөлихан ата-анасы йортына кайта. Ярты елдан аны яңадан кияүгә – Гыймадетдин Садыйк улына бирәләр. Аларның беренче балалары алты елдан соң гына туа, ә икенче сабыйлары дөньяга 8 елдан соң аваз сала. Ә бер елдан соң озак көттереп туган бу балаларның икесе дә үлеп китә. 1889 елда Гөлихан белән Гыймадетдиннең уллары Кәмаретдин, 1894 елның гыйнварында кызлары Бәдрихан дөньяга килә. 1894 елның декабрендә 40 яшьлек Гөлихан, сабыйларын ятим калдырып, бакый дөньяга күчә. Аңлашыла ки, бу кабер ташында үлем датасы метрикадагы язмалардан бераз аерыла, әмма мәрхүмәнең яше дөрес күрсәтелгән.

* * *

Ул елларда кулга хәзерге кебек туу яки вафат булу турындагы таныклык бирелмәгән. Гаилә хәле актлары метрикага теркәлгәнгә кадәр дә, теркәлгәннән соң да башкаларга телдән генә җиткерелгән. Төрле сәбәпләр аркасында махсус, яшерен яки үзара килешеп, бу даталарны башка көнгә күчерү очраклары да күзәтелгән. Авылның бер гаиләсендә шундый вакыйга булган. Сабый үз вакытыннан шактый алда, зәгыйфь булып дөньяга килә. Әти-әнисе исән калырмы, юкмы икәнен төгәл белмиләр һәм, өметсез килеш, аны мич янындагы тартмага салалар. Бала үлми. Ике ай дәвамында, табигый туу вакыты җитәрәк, ул ныгый һәм шул вакытта гына аны рәсми документка теркәп куялар.

Исмәгыйль Рәхмәтулла углына һәм Бибизөһрә Мөхәммәддияр кызына куелган кабер ташы

Зират читендә үсеп утырган сирень куаклары арасында тагын бер кабер ташы сакланып калган. Кайчандыр ул яссы плитәдән гыйбарәт булып, ярымтүгәрәк өсле һәм ике ягы да язулы биек һәйкәлне тәшкил иткән. Вакыт узу белән, таш, икегә сынып, бер кисәге җиргә авып, туфракка батып кергән. Шулай да аның икенче өлешен чыгарып, чистартып, асты белән тоташтырганнан соң, тулы текстын уку мөмкин булды. Таш ир белән хатын җирләнгән каберләр өстенә куелган. Аның алгы ягына, уеп: *«Би-хукми-лләһи (Аллаһ хөкеме белән). Бу кабер сахибе (иясе) Исмәгыйль Рәхмәтулла углы. Гомерегез язлары 68 улды. Кабере җәннәт ягы улсун. Сәнә (ел) 1319 һиҗрия рәҗәбнең 5ләрендә, сәнә 1901 миладия октябрь 15ендә»*, – дип язылган. Икенче ягына: *«Бу тарафда Исмәгыйль Рәхмәтулла углының зәүҗәсе (хатыны) Бибизөһрә Мөхәммәддияр кызы алтмыш яшендә мәдфүнә (күмелгән) улды. Мәрхәмәтү Аллаһ вәсигә (Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте киң). Сәнә 1913 миладиядә май 8ендә»*, – дип уелган.

Шуны да искәртик: кабер ташында күрсәтелгән яшь метрика кенәгәләрендә язылган мәгълүматтан сизелерлек аерыла. Архив документларына караганда,

Нияз Исхаков һәм Мәхмүтгәрәй Шәмсетдинов

Исмәгыйль Рәхмәтулла углы 1824 елда туган, ә Бибизөһрә Мөхәммәддияр кызы 1834 елда дөньяга аваз салган. Кабер ташында вафат булу елы турындагы мәгълүматка караганда, ир кеше – 77 яшендә, ә хатыны 12 елдан соң гына, 79 яшендә бакый дөньяга күчкән булып чыга. Кем тарафыннан куелуы билгесез булган бу таш бер гаилә – ир белән хатынның бакый дөньяда да бергәлеген, аларның мәңге аерылмаганлыгын символлаштырып тора.

Насыйбулла Йосыф углына куелган кабер ташы

1921 ел белән билгеләнгән бу таш авылдан 40 чакрым ераклыктагы Буа шәһәрендә яшәүче ташчы һәм каллиграф Гарифҗан Буави (1879-1946) тарафыннан эшләнгән дип уйларга мөмкин. Һәрхәлдә, ташның формасы һәм язу стиле шуңа ишарәли.

Ташның алгы ягына: *«Әл-хукму лилләһ (Бар хөкем Аллаһта). Тарих вафат 1921 нче сәнә (ел) миладия июль 9ында Насыйбулла Йосыф углы дәру-л-фәнәдән (бетү йортыннан) дәру-л-бәкая (калу йортына) рихләт әйләде. Аллаһ урынын җәннәт кылсын»*, – дип уелган. Икенче ягына: *«Һуәл-хәййу (Ул тере) лә йамүт (үлми торган). Бу кабердә Насыйбулла Йосыф углы. 57 яшендә вафат улды. Рухына дога Аллаһу Гафур әр-Рахим»*, – дип язылган. Метрика кенәгәсендә Насыйбулла бине Йосыф бине Хәбибулланың 1864 елда дөньяга килгәнлеге турындагы мәгълүмат бар. Бу очракта ике төр чыганактагы – кабер ташы һәм метрика кенәгәсендәге язмаларның туры килеп, бер-берсен тулыландырганын күрәбез.

Әлеге мәрхүмнең нәсел дәвамчылары хәзер Йосыпов фамилиясен йөртә. Балалары аңа чардуган корып, заманча итеп таштакта да беркетеп куйдылар. Алар үз бабаларын онытмый: ел саен каберен карап, рухына дога кылып тора.

* * *

Үтәмеш авылында элек-электән балаларга зиратта үз-үзеңне тоту әдәбен өйрәтәләр: кабер өстенә басып йөрмә, зиратта кычкырып сөйләшмә, кыр чәчәкләрен өзәргә, җир җиләген җыярга ярамый, зиратка тәһарәтле килеш кенә керергә рөхсәт... Каберстанда яман сүз сөйләү тыела, югыйсә, үлгәннәр икенче якка әйләнеп ятачак, мәрхүмнәр рәнҗи; бармагың белән күрсәтсәң, үлем чире йоктырырга мөмкинсең... Бу йола-ышанулар барысы да зиратка, вафат булганнар рухына хөрмәт тәрбияли, кеше җанының үлемсезлегенә, бакый дөньяның мәңгелегенә ишарәли. ■

Гөләйза кыйссасы

Галим Хисамиев

«Башыбызны киссәгез дә, христианлыкка күчмибез!»

Гөләйза бакый дөньяга күчкәннән соң, аның «эше» – мөселманлыкка кайткан керәшеннәрнең иман, ислам хакына көрәше, аларны эзәрлекләү, судтан судка йөртү дәвам итә. Гөләйзаның ире һәм балалары, мәрхүмәне җирләүдә катнашы булган дип саналган мулла белән мәзиннең язмышы ничек хәл ителгән? Хәзер шулар турында сөйләрбез.

Шулай итеп, Кыр Шонталасы авылы татарлары Фекла Тимофеева, Измаил Ефремов, Иван Денисов, хатыны Дарья һәм кызы Марфаны Казан рухани консисториясенә «миләрен чистартырга» җибәрәләр. Әмма чиркәү руханилары максатларына ирешә алмый: Кыр Шонталасының «чукындырылган татарлар»ы үз сүзләрендә нык торалар, янәдән чукынмыйлар. Аларның иманнарына тугрылыгы Казан губерна идарәсенең 1845 елгы 31 октябрьдәге Указында да чагылыш тапкан. Анда: *«Консистория әгъзалары һәм дөньяви депутатлар, татар теле укытучысы катнашында аларга үгет-нәсыйхәт биреледе, тик* ***алар мөселманлыкны калдырырга теләмәүләрен****, рус телен һәм христиан динен белмәүләрен аңлаттылар. Бернинди үгетләүләргә колак салмыйча,* ***христианлыкка кайтырга риза***

Кыр Шонталасы авылының картасыннан керәшен татарлары, мөселманлыкка кайткан керәшеннәр һәм мөселманнар зиратын күрергә мөмкин. XIX гасыр

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2020) санында.

***булмау сәбәпле, аларны үз сүзләрендә каты торучы** санап, Чистай өяз мәхкәмәсе аларның эшен Җинаять эшләре палатасына җибәрү турында уйларга, ә үгет-нәсыйхәт бирүне дәвам итәргә»*, – дип боерык биргән. Бу турыда Казан рухани консисториясенең губерна идарәсенә юллаган хатында да әйтелә. Протоиерей Мамаков имзалаган документта: *«**Татарлар ислам динен ташлап христианлыкка кайтырга теләмәүләрен**, рус телен һәм христиан дине догматларын белмәү сәбәпле, кайта алмаячакларын, үзләренең чукындырылганмы, юкмы икәнлеген белмәүләрен аңлаттылар. Консистория әгъзаларының, бигрәк тә семинариянең татар теле укытучысы Аполлон Александровның православие чиркәвенә кире кайту турындагы үгет-нәсыйхәтләренә колак салмыйча, **ислам динендә калырга теләүләрен тәкърарлыйлар, үз сүзләрендә нык торалар**. Шул сәбәпле, аларның эшен губерна идарәсенә юлларга, ә урындагы причтка православие диненә кайту хакында үгет-нәсыйхәт бирүне дәвам итәргә»*, – диелгән. Тагын бер документта Кыр Шонталасы чукындырылган татарларының: *«Без патша әмерен көтәбез. **Башыбызны киссәгез дә, христианлыкка күчмибез, мөселманлыкта калабыз!**»* – дип, ярсынып җавап бирүләрен язып китү дә урынлыдыр.

Гөләйза һәм аның улын кем җирләгән?

Шушы вакыйгалардан соң хәлләр тагын да катлаулана. 9 декабрьдә Чистай өяз мәхкәмәсе земство мәхкәмәсенә чираттагы Указын юллый. Анда: *«Фекла Тимофееваның кызлары Федосья һәм Марьяны эзләп табып, сорау алу өчен земство мәхкәмәсенә китерергә. Гөләйзаның үлеп китүе сәбәпле, аның уллары Габделвахитны, Габделҗаббар һәм Гайнетулланы, мөселманлык белән кызыксынудан арындыру өчен, Камаевтан аерып, христиан диненә ияләштерергә һәм аларны, чукындыру өчен берәр христианга тәрбиягә бирү максатында, округ идарәсенә җибәрергә. Мулла Әхмәревнең эшен земство мәхкәмәсенә тапшырырга»*, – диелгән.

Сорау алганда, кызларын һәм оныгын югалту кайгысыннан, төрле борчулардан йончыккан булса кирәк, олы яшьләрдәге Фекла Тимофеева: *«...Гөләйза 2 ел элек вафат булды. **Аны Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәрев мөселманча җирләде.** Төпчек кызым Миңҗамал 6 ел элек үлеп китте, аны Кызылъяр атакае (исемен белмим) христианча җирләде. Уртанчы кызым Шәрифҗамал авылда яши, кияүгә чыкмаган, ул да мөселман динен тота»*, – дип сөйли һәм «эш»не тагын да катлауландыра.

Фекла Тимофееваның кызы Федосья: *«Исемем – Шәрифҗамал, русча исемемне һәм әтиемнең кем булуын белмим, 19 яшемдә, язык әйтүдә (исповедь) һәм өлеш алуда (причастия) булганым юк, аларның нәрсә икәнен дә белмим, чукындырылуым турында әнием Гөлзадәдән (Фекла) дә, башка кешеләрдән дә ишеткәнем юк һәм белмим. Хәзер әнием белән Кыр Шонталасында үз йортыбызда яшибез, кечкенәдән әнием күзәтүе астында ислам динен тотам»*, – дип әйткән. Аның күрсәтмәләрен писарь Ильминский имзалаган. Бу нисбәттән: «Шушы писарь атаклы «мәгърифәтче» Николай Ильминский булмадымы? Ул, Чистай һәм Спас өязләрендәге 51 авылда мөселманлыкка кайтучы татарларның эшен тикшерүдә катнашып, кирәкле тәҗрибә туплап, шул вакытта ук «чыныгу» алмадымы икән?» – дигән фикер туа.

Хәким Камаев исә: *«Чыннан да православиедән безнең мөселман диненә кайткан хатыным Гөләйза ике ел элек, өченче улыбыз Гайнетулла быел җәен вафат булды, **Әхмәт Әхмәрев аларны мөселманча җирләде**. Улларым Габделвахит һәм Габделҗаббар минем белән яшиләр»*, – дип җавап биргән.

Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәрев сорау алганда стан приставы Шахтка: *«**Гөләйзаны мөселманча җирләдем**, аның чукындырылуын белмәдем, ә **аның улын – Гайнетулланы** мин өйдә булмаган чакта мәзин **Мөхәммәтша Мөхәммәтсәлимов җирләгән**. Гайнетдиннең туганлыгы метрика кенәгәсенә теркәлгәнгә, аның үлеме дә язылган, ә Гөләйзаныкы исә юк»*, – дип сөйләгән.

> **Казан казна палатасы карары буенча бер генә юл кала – үгет-нәсыйхәт. Моның өчен атлар белән кучереп йөртелә торган тәгәрмәчле чиркәүләр куллану киңәш ителә. Бу үгетләүләргә, дөресрәге, кысу-изүгә түзә алмыйча, Кыр Шонталасыннан нибары бер гаилә – Илья Федоровлар гына 1855 елда кабат христиан диненә кайта.**

Чирүле Шонталасының мәзине: *«Исемем – Мөхәммәтсәлим улы Мөхәммәтша, 37 яшемдә, хөкемгә тартылганым юк, татарча укый-яза беләм, Спас өязендәге Түбән Тигәнәле авылының дәүләт крестьяны, 8 нче ревизиядә шулай язылганмын. Чирүле Шонталасында азанчы булып торам, указым әлегә юк, әмма тиешле кәгазьләр җибәрелгән. 1845 елның җәендә Хәким Камаевның үлгән улы **Гайнетулланы мулла авылда юк чакта җирләмәдем, моңа хокукым да юк, мулла Әхмәревнең аны ни сәбәпле миңа ябуын аңламыйм**, бәлки, үзен аклар өчендер»*, – дип җавап биргән.

«Балаларны христианнарга тәрбиягә бирергә!»

Мәзин, мулла, Хәким Камаев һәм Фекла Тимофееваларның күрсәтмәләре аерылганга, стан приставы шул ук көнне «очная ставка» үткәрә. Йөзгә-йөз китереп сорау алганда **мулла да, Хәким Камаев та мәетне җирләгән чакта туганы Әбүталип Камаевтан тыш кеше булмады, ә Гайнетулланы мәзин җирләде** дигән күрсәтмә бирә. Фекла Тимофеева исә, оныгымны кем җирләгәнен белмим, дип бара. Мулла белән мәзин бер-берсенә күрсәтәләр.

***

13 гыйнварда стан приставы Шахт, Фекла Тимофееваны, оныкларын, мулла һәм мәзинне кулга алып, аларны Чистайга озата. Соңрак мәхкәмә: *«Мулланы хөкем итәргә, Гөләйзаның балаларын, округ идарәсе аша, христианнарга тәрбиягә бирергә, мәзинне туган авылына кайтарып җибәрергә»*, – дигән карар чыгара.

Мулла: «Беркетмәдә хата киткән – Гөләйзаны мин җирләмәдем»

1846 елның 17 гыйнварында өяз мәхкәмәсендә Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәревтән сорау алу дәвам иткән. Ул: *«Хәким Камаевның законлы хатыны рәвешендә яшәүче Гөләйзаның чынында Пелагея исемле һәм чукындырылган булуын, Хәким белән никахсыз яшәвен белмичә, аны татар мөселманы һәм Хәкимнең никахлы хатыны дип санап, аларның балаларына мөселманча исем куштым һәм метрика кенәгәсенә теркәдем»*, – дип җавап биргән. *«Гөләйзаның чукындырылуын белгәннән соң, аны ни өчен мөселманча җирләдең?»* – дигән сорауга: *«**Аны мин җирләмәдем, ул Хәкимнең туганы – староста Әбүталип Камаев күрсәтмәсе буенча җирләнде**, моңа шаһитлар бар»*, – дип җавап бирә. Аны 12 гыйнвардагы сорау алу күрсәтмәләре

Безнең мирас №5 май 2020

НА 6 МѢСЯЦОВЪ
ЦѢНА 85 КОП. СЕР.
Для Мѣщанъ и Крестьянъ.

ПО УКАЗУ ЕГО ВЕЛИЧЕСТВА, ГОСУДАРЯ ИМПЕРАТОРА
НИКОЛАЯ ПАВЛОВИЧА,
САМОДЕРЖЦА ВСЕРОССІЙСКАГО,
и прочая, и прочая, и прочая.

Примѣты:
Лѣта 40.
Ростъ
Волосы
Брови
Глаза
Носъ
Ротъ
Подбородокъ
Лице
Особыя примѣты:
Нѣтъ

Объявитель сего [illegible] уволенъ въ разные города и селенія Россійской Имперіи для собственныхъ надобностей отъ [illegible] впредь на [illegible] то есть: тысяча восемьсотъ [illegible] , а по прошествіи срока явиться ему обратно; въ противномъ же случаѣ поступлено съ нимъ будетъ по законамъ. Данъ по документу, записанному въ книгѣ подъ № 311 изъ [illegible] Уѣзднаго Казначейства съ приложеніемъ печати онаго. [illegible] тысяча восемьсотъ [illegible] года. [illegible]

Мәзин Мөхәммәтсәлим улы Мөхәммәтшаның срогы чыккан паспорты

белән таныштыргач: *«Мин Гөләйзаны җирләдем дип әйтмәдем, пристав миннән тәрҗемәчесез сорау алганга, яки мин русча начар аңлатканга, яисә пристав минем җавабымны дөрес аңламаганга, яки мин приставның соравын аңламаганга беркетмәдә хата киткән»*, – ди. *«Хәким Камаев та Гөләйзаның синең тарафтан җирләнүен күрсәтә»*, – дигәнгә, ул: *«Үзенең туганының гаебен яшерү өчен шулай әйтә, чөнки Әбуталип Камаев кушуы буенча, Гөләйзаның мәете мөселманча да, христианча да җирләнмәде, ә йоласыз күмелде, шундый ук ялгышлар, аңлашылмаучылыклар мәзин тарафыннан җирләнгән Гайнетуллага кагылышлы күрсәтмәләрдә дә киткәндер»*, – дип, шома гына аңлатма биргән. Мулла үзен Хәкимнең балаларына мөселманча исем кушуы һәм аларны метрика кенәгәләренә теркәве буенча гына гаепле санаган. Закон буенча метрикада кешенең тууы да, үлеме дә күрсәтелергә тиеш булганлыктан, ул да Гайнетулланың үлемен метрикага теркәп куйган, имеш. Бу материалларга таянып, өяз мәхкәмәсе, мулла Әхмәт Әхмәревкә карата тиешле карар кабул итү өчен, эшне земство мәхкәмәсенә җибәргән.

Шахтны Лебедев алыштыра

Шушы араларда чукындырылган татарларның канын эчкән – зиратларда яңа каберләрне казытып, мәетләрнең нинди йолалар буенча җирләнүен тикшереп, мөселманлыкка кайткан татарларны үтереп яки үтергәнче кыйнап, тиешле күрсәтмәләр алган, бу турыда тикшерүләр үткәрелсә дә, Казан губерна идарәсе тарафыннан яклау табып җәзадан котылган һәм, киресенчә, гаепсез кешеләрне гаеплегә чыгарып, хәрби хезмәткә алдырткан һәм Себергә сөрдергән Чистай өязенең 2 нче стан приставы Александр Иванович Шахтны башка кеше – Лебедев

алыштырган. Земство мәхкәмәсе, пристав Лебедевка мөрәҗәгать (№52, 30.04.1846 ел) итеп, мулла Әхмәт Әхмәревнең эшен тикшерү турында хәбәр иткән. Әмма билгесез сәбәпләр аркасында эш тоткарланып, аңа бер елдан соң гына әйләнеп кайтканнар. Авылның бер төркем кешесеннән, мөселманча ант иттереп, сорау алынган.

Беренче булып Әхсән Ярмөхәммәдев җавап тоткан. Ул: *«Минем атым – Әхсән Ярмөхәммәд улы, миңа 55 яшь, мөселман, хөкемгә тартылганым булмады, укый-яза белмим, 8 нче ревизия буенча, Чирүле Шонталасы авылы дәүләт крестьяны итеп теркәлдем. Авылдашым Хәким Камаев белән аның законлы хатыны рәвешендә яшәгән мәрхүмә Гөләйзаның мөселманча муллабыз Әхмәт Әхмәрев тарафыннанмы, әллә инде элеккеге староста Әбүталип Камаев кушуы буенчамы җирләнгәнен белмим, әмма* ***Гөләйзаның староста Әбүталип Камаев һәм Хәким Камаев тарафыннан йоласыз җирләнүе турында ишеткән идем****. Башка хәбәрем юк»*, – дип җавап биргән. Аннан соң башка шаһитлар, да шул рәвешле җавап тотканнар. Әллә инде бу «шаһитлар», чыннан да, берни белмиләрме? Яки, алдан сөйләшеп, бер сүздә булырга килешеп, гаепне Гөләйза мәетен җирләүне оештыручы, аның иренең туганы – староста, инде вафат булырга өлгергән Әбүталип Камаевка сылтап, җеп очын «суга салырга» телиләрме?

> «Гөләйза һәлак була, аның балалары, Россия законнары буенча, аталарыннан аерып, көчләп чукындырыла һәм христиан динендәге төрле гаиләләргә тәрбиягә бирелә. Кызганыч, хәзерге көндә «Сак-Сок» хәлендә калган бу балаларның язмышы билгесез.

«Гөләйзаның балалары чукындырылган»

Чистай дини идарәсе архивындагы документларның берсендә: *«Мәрхүмә* ***Гөләйзаның уллары*** *Габделвахит һәм Габделҗаббар 13 июльдә Актау чиркәве рухание тарафыннан* ***христиан диненә кертелделәр*** *һәм чукындырганда Габделвахитка – Афанасий Васильев, ә Габделҗаббарга – Андрей Якимов исеме кушылды. Афанасий Васильев – Актау крестьянины Василий Афанасьевка, ә Андрей – шул ук авыл кешесе Степан Ивановка тәрбиягә бирелде. Чистай округы башлыгының булышчысы Жухарев»*, – дип язылган.

Чистай дини идарәсе Актау приходы руханиларына: *«Чыннан да, Гөләйзаның балалары Габделвахит һәм Габделҗаббар алар тарафыннан чукындырылган һәм Актау авылы христианнарына тәрбиягә бирелгән булсалар, моны рапорт белән расларга, киләчәктә балаларның христиан динендә тәрбияләнүләрен, христиан дине йолаларын тәгаллек белән үтәүләрен күзәтеп торырга»*, – дигән Указ чыгарган. Указ 13 августта Актау авылы руханиена җибәрелгән. 1846 елның 6 ноябрендә Актау атакае Яков Алякринский дини идарәгә юллаган рапортында: *«Дини идарәнең 13 августтагы Указына җавап итеп, чыннан да, Кыр Шонталасыннан мәрхүмә Гөләйза Измаилованың балалары Габделвахитны һәм Габделҗаббарны 13 июльдә чукындырдым, беренчесенә Афанасий исемен куштым, ул Актау авылыннан иске керәшен Василий Афанасьевка тәрбиягә бирелде. Икенчесенә Андрей исеме куштым, үрсәти сыйфатында Яким Иванов булды, ул иске керәшен Степан Ивановка тәрбиягә бирелде. 1846 елның 6 нчы ноябре. Иерей Яков Алякринский»*, – дип язган.

«Рус авылларына күчереп утыртылырга тиешлеләр!»

1847 елны Казан җинаять эшләре палатасы мәхкәмәсе, «Гөләйза турындагы» эшне карап чыкканнан соң: *«...гаепләнүче* ***52 яшьлек мулланы 6 айга төрмәгә утыртырга, мәзинне авыл расправасында 3 тәүлек тотып, аңа көмеш акча белән 50 тиен штраф салырга****, Кыр Шонталасы һәм башка авылларда гаиләләре белән мөселманлыкка кайткан* ***чукындырылган татарларны чиркәү булган һәм православие динендәге халыклар яшәгән җирләргә күчереп утыртырга, урындагы чиркәү әһелләренә түземлек белән христиан диненең асылын аңлатырга****»*, – дигән карар чыгара.

Кыр Шонталасы һәм Байтирәк авылында гомер итүче мөселманлыкка кайткан чукындырылган татарларны чиркәүле рус авылларына күчерү күп чыгымнар таләп иткәнгә, бу Указ гамәлгә ашырылмыйча кала. Казан казна палатасы карары буенча бер генә юл кала – үгет-нәсыйхәт. Моның өчен атлар белән күчереп йөртелә торган тәгәрмәчле чиркәүләр куллану киңәш ителә. Бу үгетләүләргә, дөресрәге, кысу-изүгә түзә алмыйча, Кыр Шонталасыннан нибары бер гаилә – Илья Федоровлар гына 1855 елда кабат христиан диненә кайта һәм Иске Иванаево авылына күчеп китә.

Мулланың Сенатка апелляция язуы сәбәпле, декабрь аенда Казан губерна идарәсенең яңа Указы чыга. Анда: *«Сенатның, эшне мулла Әхмәрев апелляциясе буенча карап, җәзаны йомшартуы сәбәпле, аны* ***1 айга төрмәгә утыртырга****»*, – диелә.

Йомгак

Шулай итеп, 13 елга сузылган «Гөләйза эше»нә нокта куелган. Аның соңгы битендә: *«...эш бөтен пунктлары белән үтәлде, аны архивка тапшырырга, Җинаять эшләре палатасына, Губерна идарәсенә хәбәр итәргә»*, – дип боерык бирелгән. *«Боерык 1850 елның 11 июлендә үтәлгән»*, – дип тә язылган.

Нәтиҗәдә, Гөләйза һәлак була, аның балалары, Россия законнары буенча, ата-ларыннан аерып, көчләп чукындырыла һәм христиан динендәге төрле гаиләләргә тәрбиягә бирелә. Кызганыч, хәзерге көндә «Сак-Сок» хәлендә калган бу балаларның язмышы билгесез. Ә калганнар исә, вакытның шактый узуы, түрәләрнең алмашынуы һәм судтан судка йөреп күпләрнең «башларын бутау» сәбәпле, җәзадан җиңел генә котыла, эш урыннарын да саклап кала. Соңгы карар буенча, мулла Әхмәт Әхмәрев Гөләйзаны мөселманча җирләгәне, аның балаларына татарча исем биргән өчен түгел, ә сорау алганда төрлечә күрсәтмәләр биргән өчен(!) Чистай төрмәсендә бер ай утырып чыга. Мәзин исә Гөләйзаның улы Гайнетулланы күмгән өчен түгел(!), ә стан приставына дорфалык күрсәткәне һәм срогы чыккан паспортын кире кайтармаганы өчен авыл расправасында 3 тәүлек ябылып тора һәм 50 тиенлек штрафка тартыла. Мөселманлыкка кайткан керәшеннәр дә рус авылларына күчерелмичә кала.

Озакка сузылган күпсанлы суд процесслары (ә биредә аларның берничәсе генә тәкъдим ителде) формаль рәвештә генә уза. Аларның да максаты бер: керәшеннәрне һәм мөселман дин әһелләрен мөмкин булган кадәр куркытып тору, аларның күпләп ислам диненә кайтуларын яки кайтырга өндәүләрен чикләү. ■

I БӨТЕНРОССИЯ МӨСЕЛМАННАР КОРЫЛТАЕНДА ХАТЫН-КЫЗЛАР МӘСЬӘЛӘСЕ*

Альмира Шәрәфиева

1917 елның 1 маенда Мәскәү шәһәренең Әсәдуллаев йортында Бөтенроссия мөселман корылтае ачыла. Аның эшендә Россиянең барлык төбәкләреннән 900дән артык делегат катнаша, шуларның 112се – хатын-кыз. Беренче утырышта ук форум рәисе **Гаяз Исхакый**: *«Әфәнделәр! Безнең җыелышта катнашкан мәртәбәле кунакны, Гаспринскийның кызын – Шәфика ханымны сәламлик!»* – дип сүзен башлый. Съезд президиумына сайланган **Сәлимә Якупова**дан соң мөгаллимә **Заһидә Борнашева** да үзенең сәламләү сүзләрен җиткерә. Литва мөселман хатын-кызлары исеменнән котлау сүзе белән **Анна Мартушас** чыгыш ясый. Ул: *«Милләтнең, аның мәдәниятенең алга китүенә һәм камилләшүенә барлык әгъзаларының камиллеге аша гына ирешеп була дип уйлыйбыз. Әлеге прогресс һәм бу мәдәният моңа чаклы бер урында тора, чөнки әлегә кадәр халыкның яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар ир-атларның эшенә катыша алмый иде. Хокуклары, алга китеш юлында хәрәкәткә йогынты ясау мөмкинлеге булмаганлыктан, алар мәдәният үсешенә киртә булган, алгарышны тоткарлаган. Һәм, киресенчә, хәзер идарә эшләренә, реформаторлык эшчәнлегенә яңа иҗади көчләр – мөселман хатын-кызларының көче җәлеп ителергә тиеш»*, – ди.

Заһидә Борнашева

*Мәкаләне әзерләүдә күрсәткән ярдәме өчен, укытучым Динә Габделбәр кызы Мостафинага олы рәхмәтемне белдерәм.

Территориаль мәсьәлә

Әлеге мәсьәлә съездны ике лагерьга – федералистлар һәм унитаристларга бүлә. Беренчеләр территориаль автономия өчен көрәшкәндә, икенчеләр милли-мәдәни автономия даулый. Бу бәхәсләрдә хатын-кызлар да катнаша. Мәсәлән, **Разия ханым Сөләйманова**: *«Мин Оренбургтан килдем. Мине җибәргән хатын-кызларның теләкләрен җиткерәсем килә. Ул хатын-кызлар һәм ханымнар федерация яклы. Ир-атлар белән хатын-кызлар барлык хокукларда һәм эшләрдә дә бердәм булырга тиеш, диделәр»*, – дип, федератив корылышны яклап чыгыш ясый.

Унитаристлар территориаль корылыш проблемасының хатын-кызлар мәсьәләсе дә икәнен искәртеп үтә. Алар фикеренчә, хатын-кызлар федератив төзелештә үз хокукларын яклый алмый, Россияне федерацияләргә бүлү федерацияләрнең аерым эш башкаруына китерәчәк. Бу мәсьәлә буенча хатын-кызлар исеменнән **Фатыйма Коләхмәтова**: *«Россиянең киләчәк милли дәүләт төзелеш формасы хатын-кызлар хәрәкәтенә зур йогынты ясар. Мөселман милләтләре, ир-атлар безнең белән бергә эшләячәк, алга китәчәк. Тик сез федерация вакытында ир-атлар хатын-кызларга алар теләгән кадәр хокук бирәчәгенә ышанасызмы? Юк, хокук та, ирек тә бирмәячәкләр. Алар хатын-кызларны хәерче тормышыннан азат итә алмаячаклар. Бер әфәнде: «Сез нәрсә, хатын-кызларны өйләреннән ирекккә чыгарырга уйлыйсызмы?» – дип кисәтә. Бу сүзләрдә зур мәгънә бар: һәр милләт аерым эшкә тотынганда, анда бу вакытка кадәр качып калган кара көчләр өстен булачак. Алар безнең ирекккә беркайчан да хезмәт итмәячәк, ә бөтен тән һәм күңелләре белән аңа каршы торачак. Мин монда аерым делегат. Хатын-кызларның хәлен яхшыртуда ярдәм итәсем килә. Әмма минем намусым федералистлар өчен тавыш бирергә кушмый. Аларның киләчәге начар дип уйлыйм»*, – дип билгеләп үтә.

Эш мәсьәләсе

Февраль инкыйлабыннан соң эшчеләр яңа көч белән үз таләпләрен куя башлый. Карарда 8 сәгатьлек эш көне, 42 сәгатьлек бәйрәм ялы тәкъдим ителә. Эшче гүзәл затларга кагылышлы мондый карарлар кабул ителә: хатын-кызларны сәламәтлеккә зарар китерә торган эшкә алырга ярамый; хатын-кызлар, сабый көткән мәлдә, хезмәт хакын саклап, 4-6 атнадан соң ял алырга тиеш; хатын-кызлар, баланы ашату өчен, эштән һәр өч сәгать саен азат ителергә тиеш.

Мәдәни-агарту эшләре

Мәгариф мәсьәләсе дә, булачак милләтне тәрбияләүдә мөһим фактор буларак, көн тәртибенә куела. Мәгарифтәге реформалар өчен җәдитчеләр актив көрәшә. Съезд милләтнең гыйлем дәрәҗәсен күтәрүне генә түгел, ә туган телне саклап калу мәсьәләсен дә тикшерә. Съезд башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрдә укуны туган телдә алып барырга, рус теле аерым фән буларак укытылырга тиеш дигән карар чыгара. Анда, җирле традицияне һәм мөмкинлекне искә алып, «урынына карап, ир вә кыз балаларның бергә укулары матлубтыр», дип тә әйтелә.

Әминә Мөхетдинова

Хатын-кызлар мәсьәләсе турында фикер алышу

Милли лидерлар съезд вакытында хатын-кызлар мәсьәләсенең арада иң җитдие булачагын алдан ук аңлый. Сәбәбе шунда ки: төрле милләт хатын-кызларының гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хокуклары бик нык аерылып торган.

Съездда мөселман хатын-кызларының Россия мөселманнары Диния нәзарәте идарәсендә катнашуы мәсьәләсе дә хәл ителә. 10 майда алты казый вазыйфасына 38 кандидат тәкъдим ителә. Казыя вазыйфасына өч хатын-кыз – **Фәхрелбанат Акчурина, Мөхлисә Буби** һәм **Мәрьям Паташова**лар чыгарыла. Нәтиҗәдә, Мөхлисә Буби казыя итеп сайлана.

Якуб Хәлили Мөхлисә Бубины Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә сайлау уңаеннан: *«Без ислам дөньясында мондый күренешне белмибез. Хәтта ислам дәүләте булган Төркиядә дә мондый хәл юк. Бу вакыйга хатын-кызларның эш һәм хокукларда тигезлеген раслый»*, – дип чыгыш ясый.

Хатын-кызлар мәсьәләсе буенча фикер алышуларда катнашу өчен 80 кеше языла, барлыгы 3 доклад тыңлана.

Беренче булып Кырымнан **Илһамия Туктарова** сүзен башлый: *«Сәяси һәм социаль хокуклар, гаилә-көнкүреш хәлен яхшырту, хатын-кызларның Учредительное Собрание сайлауларында катнашуы, хатын-кызлар оешмалары төзү – хатын-кызлар вәкилләре бу проблемаларны Мәскәү съездына өстәмә рәвештә карауны ышанып тапшырдылар. Бу съездда безнең карарларны беркетү көчле һәм зыялы милләт аналарын формалаштыру, гаилә кору, хатын-кыз дөньясына бәйле болытны кудыру өчен беренче адым булачак»*. Алга таба ул: *«Без хатын-кызларның сәяси хокуклар өлкәсендә дә барлык гражданлык хокукларына ирешүен телибез. Без инде бүген үк аларның гаилә мөнәсәбәтләренең тамырларын агулаучы агуларны юк*

Диния нәзарәте идарәсе. Алар арасында урта рәттә — Мөхлисә Буби

итү мөмкинлеген файдаланырга тырышабыз. Безнең әниләребез, апаларыбызның һәм сеңелләребезнең бүгенге көнгә кадәр дәвам иткән газаплары һәм үпкәләүләре туктатылырга мөмкин дип уйлыйбыз», – дип дәвам итә.

Съездда хатын-кызларның катнашуы ир-атлар арасында ризасызлык тудыра. Әмма кайберләре, мәсәлән, **Хәсәнгата Габәши**: *«Мин, карт мулла, безнең арада хатын-кызлар булуы борчыган кешеләргә мөрәҗәгать итәм: ачык йөзле хатын-кызлардан курыкмагыз, ябык күңелле кешеләрдән куркыгыз»*, – дип, аларны яклап чыга.

Фатыйма Коләхмәтова да бу уңайдан үз сүзен әйтә. Ул чыгышын хокуклар, мөселман хатын-кызларының коллык хәлендә яшәве турында ачынып сөйләүдән башлап җибәрә. Россиядә мөселман хатын-кызларының дискриминациясе турында: *«Татар хатын-кызын кара, тынчу йортта бәйләп тәрбиялиләр. Аңа әтисе дә, ире дә, балалары да баш була. Чөнки алар анда сәяси, милли һәм дини хокуклары алынган колны күрә»*, – дигән фикер белдерә.

Әминә Мөхетдинова үз докладында, изге Коръәнгә таянып, ике җенеснең дә тигез хокуклылыгын раслый. Аерым алганда, ул болай ди: *«Әгәр күпхатынлылык әлегә кадәр урынлы булса, хәзер ул мөмкин түгел. Без бит хәзер намус белән эш итәргә тиеш. Һәр илдә бу гореф-гадәтләр гасырлар алмашы белән юкка чыккан. Борынгы заманнардан калган гореф-гадәтләрне бетерүдән башка сезнең чарагыз юк!»*

Мөселман хатын-кызларын яклап, **Һади Атласи** да шактый кыю чыгыш ясый. *«Хөрмәтле әфәнделәр! Бу җәберләү безгә, безнең хатын-кызларга үткәннәрдән бирелде. Һиндстанда хатын-кызларны утта яндыру йоласы бар иде. Гарәпләр, кыз*

тугач, аны җиргә күмгәннәр. Чөнки кыз туу бозыклык саналган. Әгәр Һиндстанда мөселман хатын-кызларын утта яндырсалар, без, татарлар, хатын-кызларны утсыз яндырабыз. Безнең хатын-кызлар утсыз дүрт дивар арасында яна. Гарәпләр кызларны тереләй күмеп ташласа, безнең ир-атларыбыз хатын-кызларын дүрт дивар артында мәңгелек газапларда тоталар. Бездә хатын-кызлар бөтен хокуклардан да мәхрүм. Алар бездә «бушлай пешекчеләр». Безнең кызларның һәм хатын-кызларыбызның билгеле бер бәясе бар. Татар кызлары утыз сумга бәяләнә! Һәм без – аларны сатып алучылар! Җитәр аларны сатып алырга! Җитәр аларны шулай кыерсытырга! Аларны аш бүлмәсендә тотарга да җитә!» – ди ул.

***

Дебат һәм чыгышлардан, шактый зур каршылыклардан соң, I Бөтенроссия мөселман съезды «Хатын-кызлар мәсьәләсе турында» 10 пункттан торган резолюция кабул итә.

1) Шәригатьнең хитабларында ир белән хатын бер. Хатыннарның сәяси, иҗтимагый эшләргә катышырга шәригать алдында хокуклары бар. Шунлыктан, **хатыннарның сайлау эшләренә катышулары шәригать буенча тиеш**.

2) Хатыннары тигез хокуклы булган милләт кенә көчле булып, яшәү һәм бу хокукта тигезлекне хатыннарның канун төзи торган мәхкәмәләрдә үзләре хазир булганда гына чынбарлыкка чыгару мөмкин булганлыктан, **мөселманнар бөтен сәяси хокукта ирләр белән тигез булсыннар. Хатыннар ил корылтаена сайлый һәм сайлана алсыннар**.

3) Сайлау вә сайлану эшләре мөселманнар өчен яңа бер эштер. Бердән, хатыннарыбыз моңа кадәр иҗтимагый эшләргә катнашып өйрәнмәгәнлекләреннән, икенчедән, ирләре хатыннарының сайлау урыннарына баруларына каршы тору ихтималы булганга күрә, халкыбызның яртысы булган хатыннарыбызның тавышлары югалмасын өчен: **«Ил корылтаена сайлау вакытында һәрбер мөслимәнең сайлауга катышуы бурыч булсын. Мөслимәләргә тавыш бирү өчен ирләрдән аерым урын билгеләнсен»**.

4) Русия мөселманнары арасында кыз һәм егетнең ризалыгыннан башка никах уку бик күп булып, бу эш гаилә хәятенең тынычсызлыгына вә шул гаиләдә үскән балаларның бәхетсезлегенә сәбәп булганлыктан, **никах вакытында кияү белән кыз үзләре булсыннар**.

5) Гаиләдә ир белән хатын тату тормаганда, күп вакытларда хатын иреннән аерылып китәргә теләсә дә, аны ире аермыйча газаплап тота. Татулыксыз, гаиләдә кысынкы тормышта тору хатын өчен җәбер, гаиләдәге балаларның тәрбиясе өчен зарарлы булганга күрә, съезд, хатыннарның хокукын һәм киләчәк буынның тәрбиясен игътибарга алып, ошбу карарны чыгарды: **«Ошашмаган тәкъдирдә хатынның иреннән аерылып китәргә хакы булуы никах вакытында никах дәфтәренә кертелсен»**.

6) Төркестан һәм Кавказда, шулай ук Казакъстанда 11-12 яшьлек сабый кызларны кияүгә бирү гадәт хөкеменә кергәнгә, бу эш хатыннарның зәгыйфьләнүләренә, вакытсыз үлүләренә

һәм зәгыйфь балалар җитештереп киләчәк буынсыз, зәгыйфь вә көчсезлегенә сәбәп булганга, съезд, **Русиянең кирәк шималендә (төньяк), кирәк җанүбендә 16 яшьтән ким булган кызга никах укылмасын** дигән карарны чыгарды.

7) Милләт балалары таза һәм сау булсын өчен һәм дә гаилә бәхетсезлекләренең байтагы ир йә хатынның йогышлы авыруларга дучар булуыннан килгәнгә күрә, шул бәхетсезлекләр белән көрәшү өчен, съезд: **«Никах вакытында кияүнең дә, кызның да йогышлы авырулары булмавына кулларында шәһадәтнамәләре булсын»**, – карарын кабул итте.

8) Күп вакыт ирләрнең бер хатын өстенә икенче хатын алырга бер уен төсле генә итеп караулары һәм әүвәлге хатыннарын бер дә гаепсез хәлдә аерып җибәрүләре гадәт булып киткәнлектән, бу эшнең урынсыз кылынуларга сәбәп булганлыгын да игътибарга алып, съезд: **«Никах вакытында кияүдән бер хатын өстенә икенче хатын алмаска язу алынсын. Әгәр дә инде бер-бер сәбәп белән икенче хатын алса, карт хатынын аерып, аңар нәфәка бирсен»**, – карарын кабул итте.

9) Казакъстанда кыз балаларны аналары кечкенәдән үк калым малына саталар. Соңгы көндә хатын аерылырга теләсә, калым малын кайтарып бирергә мәҗбүр була. Бу калым – мәһәрдән башка бернәрсә булып, кызны атасыннан сатып алганда бирелә торган бернәрсә. Шул сәбәпле, съезд, казакъ кызларының хокукларын игътибарга алып: **«Казакъ кызлары кияүгә барганда, калым малы алу булмасын. Моңар кадәр калым малы алынып куелган казакъ кызлары, үз ризалыкларыннан башка, әйтелеп куелган кешеләренә бармаска хаклы булсыннар»**.

10) Күп хатыннар төрле сәбәпләр буенча фәхешханәләргә барып керергә мәҗбүр булалар. Кайсылары аннан котылырга чаралар эзләсәләр дә, фәхеш тугрысындагы кануннар сәбәпле, алар гомергә бәхетсезлектә калалар. Шул сәбәптән, **фәхешханәләр һәм фәхеш тугрысындагы законнар бетерелсен**.

Менә бу ун маддәдән гыйбарәт карарлар бөтен килеш кабул ителә. Аннан соң Фатыйма туташ Коләхмәтова тарафыннан хатын-кыз мәсьәләсе секциясенең докладчысы сыйфаты илә тәкъдим ителгән ике маддә кабул ителә.

Әлеге карар әүвәлге ун маддәгә кушыла:

1) Мөслимәләр сәяси вә граждански бөтен хокукта ирләр белән бертигез булсыннар.

2) Күпхатынлылык, инсаният вә гадәткә хилафлык булганга күрә, катгый рәвештә бетерелсен.

*Съезд карарларын **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

***

I Бөтенроссия мөселманнар съезды 1917 елның 11 маенда Коръән уку белән тәмамлана. Съездан соң татар хатын-кызлар хәрәкәте активлаша. Әмма татар зыялылары татар дәүләте төзелеше кебек «мөһимрәк» мәсьәләләр белән шөгыльләнә башлый. ■

Галәветдин хәзрәт Җамалетдиновка ни өчен яла ягылган?

Равил Сәлиев

XX гасыр башында Иске Татар Кармәтендә (хәзерге Аксубай районының Иске Кармәт авылы) ике мәхәллә, ике мәчет һәм ике мулла булган. Авыл халкы арасында икенче җәмигъ мәчетнең имам-хатыйбы Галәветдин Җамалетдиновның беркайда да укымаганлыгы, гомумән, аның укымышсызлыгы һәм наданлыгы турында фикер таралган. Хәтта мулланың Коръәнне начар укуы, вәгазьләре күңелсез һәм эчтәлексез булуы да искә алына. Әлеге сафсата кемнеңдер «җиңел кулы» белән интернет буенча да «йөри». Шактый бай мәгълүматлы «Кочующие» командасы сайтында да: «Авылда ике мәчет, ике мулла булган. Берсенең исеме – Галәветдин Җамалетдинов. Ул – укымышсыз кеше. Икенче мулла – Хәсәнҗан Әхмәрев», – дип язылган. Ә иң кызганычы – мәкалә авторы бу мәгълүматны күктән алып язмаган, аңа бу турыда авыл халкы сөйләгән! Мулланың авылдашлары исә, Галәветдин хәзрәтнең наданлыгы турындагы хәбәрне төбәк тарихы белән берникадәр шөгыльләнгән Салих абый Әхмәтшин язмаларына нигезләнеп сөйли икән.

Дөресен әйткәндә, миндә Салих абый Әхмәтшинның, кайбер шәҗәрәләрен искә алмаганда, язмалары юк. Шуңа күрә мин Хәсәнҗан мулланың хәзерге вакытта Зәй шәһәрендә яшәүче кызы Ләйлә апа Әхмәтовага шалтыраттым. Әйтерсең лә, ул минем шалтыратуымны көтеп кенә торган:

– Равил, туганым, хәзер мин сиңа Салих абый Әхмәтшинның Галәветдин Җамалетдинов турында язып калдырганнарын укыйм. Минем кул астымда бер кочак язу бар!

– Язам, язам, Ләйлә апа, укыгыз!

– Салих абый Әхмәтшин (урыны оҗмахта булсын!) менә шундый сүзләр язып калдырган: *«Хәзерге Ленин урамы белән Тукай яки Вахитов урамы кисешкән җирдә югары оч мәчете урнашкан иде. Бу мәчеттә Җамалетдинов Галәветдин муллалык итә иде. Үтә кадимче, беркая да укымаган, диләр. Малае Гамалетдин, үзләренә җыеп, кадимчә балалар укыта иде. Халык сөйләүләре буенча, бу мулла дөрес кыйраәт буенча укымаган, вәгазе эчтәлексез, сүзгә бай түгел, аның мәхәлләсеннән күп кешеләр икенче мәхәлләгә күчкәннәр. Мәчете дә иске, кечкенә иде».*

– Ләйлә апа, әтиегез Хәсәнҗан хәзрәт Әхмәрев, ни өчендер, бу турыда язмаган?..

– Чыннан да, минем әти Галәветдин мулланың наданлыгы турында бер дә искә алмый. Ул аның алдаганлыгы турында искәртә, әмма, ни өчендер, бу хакта тәфсилләп язуны кирәк дип санамаган…

– Салих абый Галәветдин мулла турында: *«...беркая да укымаган, диләр»*, – дип, кемнәндер ишеткәнне генә яза. Димәк, авылның иң укымышлы кешеләреннән берсе булырга тиешле бу кешегә кара тамга аның язмасына кадәр үк сугылган! Кемдер аның биографиясен каралтыр өчен элек үк «тырышкан»!

Галәветдин хәзрәт Җамалетдинов

– Салих абый Әхмәтшин кем сүзен язып калдырганын әйтә алмыйм. Боларны Аллаһы Тәгалә үзе генә белә инде!

Миндә Галәветдин мулла Җамалетдинов исеменнән язылган ике документның күчерелмәсе бар.

Беренче документ хәзрәтнең Казан губерна идарәсенә 1910 елның 30 гыйнварында язган үтенеченнән гыйбарәт: «*Имею честь покорнейше просить Губернское Правленіе благоволить прислать мне копию со списка самостоятельных домохозяевъ прихожанъ вввереннаго мнъ 2-го прихода соборной мечети, дабы я знал в случае встретившейся необходимости кто именно из домохозяевъ состоятъ прихожанами къ оказанной 2-ой соборной мечети и кто не состоитъ, так какъ таковыхъ списковъ нетъ и въ 1-ой соборной мечети, то у нас между нами муллами происходятъ нежелательные недоразумения, по получении же списка недоразумений уже быть не можетъ. На что и буду ожидать распоряжения*». [ТР МА. 2 ф., 2 оп., 7954 с.б., 13 б.]

Аңлашыла ки, беренче мәчет имам-хатыйбы Хәсәнҗан Әхмәрев һәм икенче мәчет имам-хатыйбы Галәветдин Җамалетдинов арасында мәхәллә халкы өчен ызгыш булган, югыйсә, исемлек сорап вакыт уздырмас иде. Галәветдин хәзрәт, ике арадагы вазгыятьне артык куертуны кирәксенми генә, «недоразумения», дип яза. Бер айдан соң үз үтенечена җавап та ала ул. 1911 елның 27 гыйнварында мулла Галәветдин Җамалетдинов 1 нче җәмигъ мәчеткә йөрүчеләрдән яңа мәхәллә

булдырырга теләүчеләрнең исемлеген алуы турында расписка яза. [ТР МА. 2 ф., 2 оп., 7954 с.б., 25 б.] Бу инде икенче документ.

Күп нәрсәне ачып сала торган өченче документ та бар. Анда 1906 елның 5 нче декабрендә үк икенче мәхәлләне аерып алып, мәчет салырга уйлаулары хакында сүз бара: «*...решено образовать нами изъ себя отдельный самостоятельный 2-й приходъ съ постройкой новой мечети, почему намъ необходимо для вновь образуемого прихода избрать кого-либо муллою, что въ нашемъ обществе имеется однодеревенецъ Галяутдинъ Зямалетдиновъ хорошо свъдущий въ правилахъ и обрядахъ магометанской религии и что Зямалетдиновъ на занятие должности муллы въ образуемомъ нами новомъ 2 приходъ изъявилъ свое согласие, а потому мы единогласно постановили: избрать и избрали въ должность муллы ко вновъ образуемому нами приходу одножителя крестьянина Галяутдина Зямалетдинова 43 летъ, которого обязуемся съ семействомъ его содержать на свой счетъ прилично его званию и при этом удостоверяемъ, что Галяутдинъ Зямалетдиновъ человекъ жизни трезвой, поведения хорошего, под судомъ и следствиемъ не состоялъ и не состоитъ, обряды и богослужения по магометанской религии выполнить в состояніи*». Шуннан соң 1907 елның 26 февралендә икенче мәхәллә мәчете мулласы итеп Галәветдин Җамалетдиновны сайлаулары хакында әйтелә. [ТР МА. 2ф., 2оп., 8373 с.б., 10б.]

Искәртеп үтик: мәхәллә кешеләре Галәветдин Җамалетдиновны аек акыллы, яхшы холыклы кеше буларак сыйфатлыйлар. Иң мөһиме – булачак мулла гыйбадәтне һәм ислам дине буенча барлык йолаларны да җиренә җиткереп башкарып чыгарга сәләтле!

ТР Милли архивында Галәветдин Җамалетдиновның 1908 елда Уфадагы Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, указлы имамлыгын раслаткан таныклыгы да саклана. Шулай ук имамның 1909 елда Чистай шәһәрендәге 4 сыйныфлы училищены тәмамлау турында да таныклык алганын билгеләп үтәсе килә. Димәк, авыл имамының дини һәм дөньяви гыйлеме камил булган, ул рус теленнән дә имтиханны уңышлы тапшырган. Шушы документларны өйрәнгәннән соң, 2 нче мәчет мулласы Галәветдин Җамалетдинов беркайда да укымаган, ул гыйлемсез булган, дип әйтергә җөрьәт итә алмыйбыз.

***

Архив документларына караганда, мәхәллә аерып мәчет салу процессы да шактый каршылыклы булганга охшаган. 1906 елның 4 декабрендә Хәсәнҗан Әхмәрев Аксубай волость идарәсенә: «*...на постройку новой мечети я согласия дать не могу, такъ какъ существующая мечеть не оштукатурена изнутри и на постройку её прихожане задолжали 550 рублей*», – дип яза.

Шул ук көнне икенче мәхәлләгә аерылып чыгарга теләүче кешеләр дә Аксубай волость идарәсенә хат язалар: *«Мы, нижеподписавшиеся прихожане, образующие новый 2-ой приходъ, въ деревнъ Старо Татарской Киреметь, заявляемъ, что за постройку мечети, существующей теперь, прихожане её нисколько не должны, так какъ на уплату долга 500 руб. общество нынешней осенью продало 10 десятинъ земли по 50 руб. за каждую однодеревенцу своему Ишмухамету Сабитову, что и удостоверяемъ грамотные собственноручнымъ своимъ подписомъ» (подпись).*

Ә хәзер Салих Әхмәтшин язып калдырган мәгълүматны – *«мәчете дә иске, кечкенә иде...»* дигәнне тикшереп карыйк. Иске Кармәт авылында яшәүче Василий Петрович Кузьмин сүзләренә караганда, ул үзенең зурлыгы буенча беренче мәчеттән бик аз гына калышкан. Совет хакимияте чорында озак вакыт буш торган, сугыштан соң гына юк ителгән.



13

Свидѣтельство

Настоящее свидѣтельство, съ приложеніемъ казенной печати Чистопольскаго городского 4-х классного училища, выдано Галяутдину Зямалетдинову крестьянину деревни Старо-Татарской Карметы Якушкинской волости Чистопольскаго уѣзда Казанской губерніи, въ удостовѣреніе того, что онъ успѣшно выдержалъ испытаніе въ знаніи русскаго языка, установленное для кандидатовъ на должность сельскаго муллы.

Января 13 дня 1909 года. Г. Чистополь Каз. г.

№ 16

Предсѣдатель коммиссіи Учитель-инспекторъ

Члены

Секретарь Совѣта

У сего

Галәветдин Җамалетдиновка Чистайда 4 класслы училище тәмамлап, рус теленнән имтихан бирүе хакында таныклык. 1909 ел

12

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

По указу Его Императорскаго Величества, въ присутствіи Оренбургскаго Магометанскаго Духовнаго Собранія, вслѣдствіе просьбы крестьянина Казанской губерніи, Чистопольскаго уѣзда, деревни Старо-Татарской Карметы Галяутдина Зямалетдинова Гайнуллина и согласно 1424 ст. XI тома 1 части (изд. 1896 г.) было ему, Гайнуллину, учинено испытаніе въ знаніи правилъ магометанской религіи, по которому оказался быть способнымъ: имамомъ и мугаллимомъ.

Въ удостовѣреніе чего и выдается ему, Гайнуллину, это свидѣтельство, съ тѣмъ, что оно, показывая о его познаніяхъ, не предоставляетъ ему права исправлять духовныя требы впредь до утвержденія его въ духовномъ званіи губернскимъ начальствомъ въ приходъ, въ который будетъ избранъ. Городъ Уфа, июля 27 дня, 1908 г. Гербовымъ сборомъ оплачено.

За Предсѣдателя Оренбургскій Муфтій (Хаджи)

Членъ Собранія Кашаф

Члены-Ахуны:

У сего печать

5948

Галәветдин Җамалетдиновка Диния нәзарәтеннән имам-хатыйп булырга һәм мөгаллимлек итәргә хокук биргән документ. 1908 ел

95 яшьлек әтием Зөфәр Сәлиев менә ниләр сөйләде: *«Галәветдин мулла Җамалетдиновның мәчете Хәсәнҗан Әхмәрев мәчете кебек үк зурлыкта булган. Без белгәндә бу мәчет буш торды, дөрес, сугыштан соң аны ашлык саклау склады итеп кулландылар. Аннан орлыкны саклауга алуымны әле дә хәтерлим»*.

Әгәр дә Иске Татар Кармәте авылының имам-хатыйбы Галәветдин Җамалетдинов укымышсыз, надан кеше булса, ул икенче мәхәллә аерып мәчет салырга сәләтле булыр идеме? Һичшиксез, авылыбыздагы икенче мәчет – Галәветдин хәзрәтнең тырыш хезмәте һәм моны архив документлары да раслый.

Әйткәнемчә, үзенең «Истәлекләр»ендә авылыбыз имам-хатыйбы Хәсәнҗан Әхмәрев Галәветдин мулла Җамалетдиновның укымышсыз булуы турында бер сүз дә әйтми. Алар бит озак еллар дәвамында бер-берсеннән бернічә адым гына ераклыкта булган мәчетләрдә вәгазь сөйлиләр, кайчандыр үзара дус та булганнар...

* * *

XX гасыр башында мулла Хәсәнҗан Әхмәрев Иске Татар Кармәте авылында җәдитчелек хәрәкәтен башлап җибәрә, беренче җәмигъ мәчетне, ир һәм кыз балалар өчен аерым мәктәпләр төзетә, китапханә ача. Ул, авылда беренчеләрдән булып, балаларны укыту өчен парталар һәм язу тактасы куллана башлый. Дәресләрендә, гарәпчәдән бигрәк, татар теленә өстенлек бирә, география һәм ислам тарихын укыта. Х.Әхмәрев укыту процессына иганәче сәүдәгәрләрне, аеруча мәшһүр бай Әхмәт Хөсәеновны җәлеп итә. Вәлиулла хәзрәт Якупов «Истәлекләр»гә («Иман»

нәшрияте, 2004) соңгы сүздә: *«Асылда бу менеджерлык операциясе бик дөрес башкарылган, хәтта күп кенә галимнәребез, дәрәҗәле урыннарга ия булсалар да, аның асылын аңлый алмыйлар»*, – дип яза.

Шул ук вакытта Хәсәнҗан Әхмәрев үзенә дошманнар да туплый, хәтта авылны ташлап китәргә мәҗбүр була. «Бездә коммунист мулла бар», – дип, аның өстеннән донос язалар. «Истәлекләр»ендә: *«Мин карагруһчылар тарафыннан динсез дип сүгеләм, яшьләр-фәнчеләр тарафыннан каты динче булуым берлә сүгеләм. Минемчә, дин гыйлеме, фән гыйлеме – дин-исламның ике баласы. Динчегә – фән, фәнчегә дин кирәк»*, – дип, үзе хәлен һәм фикерен белдерә ул.

Хәсән Туфан үзенең беренче укытучысы Х.Әхмәревне бик яратып искә ала һәм үзенең шагыйрь буларак формалашуында аның зур роль уйнавын күрсәтә. «Давыллы еллар лирикасы» (1970) исемле җыентыгындагы «Бәлки, шагыйрь булмас та идем» дигән кереш мәкаләсендә әдип бу мәсьәләгә аерым туктала: *«Соңга таба минем «белем даирәм» тагын да киңәя төште. Безнең авылның мулласы Хәсәнҗан абый Әхмәрев мине, үз өенә килгәләп, китаплар, газетлар укып йөрергә чакырды... Хәсәнҗан абый безне кояш тирәсендә әйләнүче планеталар һәм галәмнең төзелеше белән дә аз-маз таныштырды»*.

Хәсәнҗан хәзрәт, «Истәлекләр»ен тәмамлап: *«Дус булып бик каты алдаучылар – Акбулат мулла Шакирҗан, Чистай техникумы директоры Зариф учитель, Кармәт мулласы Галәветдин Җамаллар булды»*, – дип яза. Әйткәнемчә, Галәветдин мулла Җамалетдинов аны ни өчен алдаганы турында әйтми, әмма дусты булуы хакында гына искәртә.

* * *

Галәветдин Җамалетдиновның мулла булганга кадәрге тормышы безнең өчен караңгы булган кебек, алдагы язмышы ничек булганлыгы хакында да авылдашлары белми. ТР Милли архивында сакланган документка караганда, ул тумышы белән Иске Кармәт кешесе түгел. Аның әнисе – Яңа Карамалыда яшәүче Камалетдин Монасыйповның кызы – 1891 елда Иске Кармәт кешесенә кияүгә чыккан. Бу вакытта улы Галәветдингә 28 яшь була инде. Архивта 1930 елның 25 маенда Чистай кантонының Аксубай волосте буенча сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән затлар исемлеге бар. Бу исемлеккә Г.Җамалетдиновның гаиләсе – хатыны һәм өч баласы теркәлгән. Шулай итеп, ул 66 яшендә халык дошманы була. Күрәсең, халык дошманы булгач, кайберәүләр аның турында төрле тузга язмаган нәрсәләр язарга һәм әйтергә мөмкин дип уйлаганнардыр... Кызганыч, Хәсәнҗан Әхмәревтән аермалы буларак, ул безгә үзенең истәлекләрен язып калдырмаган. Һәрхәлдә, Галәветдин мулла Җамалетдинов укымышсыз, надан түгел! Аны кадимчелектә һич кенә дә гаепли алмыйбыз. XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында муллаларның күбесе кадимче булган. Кадимче һәм җәдитчеләр яки аларны хуплаучы төркем, мәхәллә халкы, байлар арасында каршылык еш күзәтелгән. Бу төркемнәрнең бер-берсен кимсетүләре табигый булып, совет тарих фәнендә «җәдитче – акыллы», «кадимче – надан» дип берьяклы тасвирлау традициягә әйләнеп киткән. Менә шулай итеп, Галәветдин хәзрәткә дә «надан, укымышсыз» дигән кара тамга сугыла. Ә асылда исә, киресенчә, кадимчеләр гореф-гадәт, тәрбия һәм гарәби уку сагында ныграк та торганнардыр әле!

Бер сүз белән кешенең тулы биографиясен каралтырга, аның тарихтагы урынын түбәнсетергә, рухын рәнҗетергә мөмкин. Әле кемне диген – Иске Кармәтнең Аллаһ йортын төзеткән мулласын! Ә менә миңа аны аклау өчен архив тузанына чумып күпме утырырга, тулы бер мәкалә язарга кирәк булды. ■

Татар матбугаты тарихы

«Иттифакъ» газетасы


اتفاق
بتون روسیه علما اتفاقی نڭ ناشر افکاریدر.
برلەشیك بتون مسلمانلر!
«اتفاق»
اولوغ اشکه تشبث.
طوپراقلی مختاریت.

«Иттифакъ» газетасының беренче саны. 1918 ел

Мөселман дин әһелләренең совет хакимияте урнашканнан соң беренче махсус газетасы 1918 елның 31 гыйнварында чыга башлый. Шигаре – «Берләшсен бөтен мөселманнар!» Әлеге басманы чыгару мәсьәләсе 1917 елның июль аенда узган Беренче голәмәләр съезды вакытында ук хәл ителә. Бу хакта махсус программа да кабул ителеп, эш «голәмә иттифакының идарәи мәркәзиясе»нә тапшырыла. Әмма матди һәм мәгънәви, идарәи мәркәзиянең Казанда яши торган әгъзалары аз булу сәбәпле, газетаны чыгару эше ярты елга тоткарлана.

Әлеге басманың максаты турында газетаның үзендә үк: ***«Иттифакъ»ның мәсләге тәрәккыйпәрвәрлек булып, халкымызны берлеккә вә дөрест бер юлга өндәүдер һәм моңа кадәр милләтебездә рәһбәрлек (юлбашчылык) иткән голәмәи динне (дин әһелләрен) әхвәл заманнан хәбәрдар итеп, милли, иҗтимагый вә сәяси агышларда якыннан таныш кылырга җитди хезмәт куюдыр. Иң мөһим вазыйфасы да милләтне иттифакъ вә берлеккә дәгъват булганлыктан, исемен дә «Иттифакъ» кую тиеш табылды. Газетамызның өстенә йөкләнгән вазыйфасы – дин сыйныфын химая (яклау) вә халкымызның дини вә әхлакый тәрбия, уку вә укыту эшләрен тәрәккый итүдер»***, *– дип язылган.*

Матбугат белгече **И.Рәмиев** *газета турында:* ***«Без, руханилар, сәясәткә катышмыйбыз диючеләрнең гәзитләрен карасаң, һәр номеры сәяси төс бирелгән мәкалә вә хәбәрләр белән тулы. Шул рәвешчә, безнең байлар, ярлылар сыйныфы юк, булмаска тиеш, мөселманнар бер җан, бер тән, ди дә, «Иттифакъ» гәзите голәмә сыйныфына аеруча әһәмият биреп, аларның хәлләрен яхшыртырга тырышачактыр, ди. Сыйныфый баскычтан төп үз файдаларын яклап яза»***, *– дип әйтә.*

Газетаның иң актив авторларыннан шагыйрь һәм мулла Мөхәммәдсадыйк Иманколый (1870-1932), мулла Касыйм әс-Салихи, Исмәгыйль Габдиләр булган. Басманың сәхифәләрендә «Байлык вә ярлылык», «Ислам вә социализм», «Идел-Урал өлкәсе», «Русия мөселманнары вә голәмә сыйныфы» кебек милли дәүләтчелек, большевиклар һәм милли сәясәт, муллаларның хәле хакында үтә җитди мәкаләләр дә дөнья күргән.

Атнага бер мәртәбә дүрт битлек булып Казанда «Өмид» типографиясендә басылып килгән газетаның барлыгы ундүрт номеры чыга. «Иттифакъ» 1918 елның урталарында туктатыла.

Игътибарыгызга андагы кайбер хәбәрләрне тәкъдим итәбез.

Шәфкатьлеләр дикъкатенә

30 төрек әсирә хатыннарыннан бер фирка тәшкил ителгәндә, аларны Казаннан Одесса аркылы Төркиягә җибәрү чараларына керешелде. Шуның өчен Казан округындагы төрек әсирләрен белгән затлар һәм мөәссәсәләр *(оешмалар)*, рәхим итеп, түбәндәге адрес белән әсирләрнең ватан адресларын һәм хәзер кем тәрбиясендә яшәгәнлекләрен белгертеп, тиз көндә язсалар икән. Адрес: Казань, «Вошуро, военному ахуну Багаутдинову».

Иттифакъ. – 1918. – №1. – 31 январь.

Мөселман тимер дружиналары

Шәһәремездә мөселманнарның үзләренә революционный ыштаб төзелеп, эш күрелә башлаулары илә һәр мәхәлләдә мөселман күңелле гаскәрләре – тимер дружиналар ясалды. Бөтен мәхәлләләрдә хәзер шушы тимер дружиналар ашыгыч рәвештә аякка бастырыла.

Иттифакъ. – 1918. – №4. – 21 февраль.

Хоканд фаҗигасе

Төркестанда җирле мохтарият[1] игълан ителгәннән бирле анда большевиклар сартларга *(хәзерге үзбәкләр)* каршы төрле катгый чаралар күреп, ниһаять,

[1] Төркестан мохтарияте 1917 елның 28 ноябрендә хәзерге Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан территориясендә оеша. 1918 елның 22 февралендә большевиклар тарафыннан куып таратыла.

мохтарият башында торучыларны тотып, Төркестан мохтарияте дигәнне бетереп куйганнар иде. Инде тагын Төркестанда җирле халык белән большевиклар арасында тынычсызлык башланган вә бу тынычсызлык соңга таба гаять дәһшәтле фаҗига төсләренә кергән. Шул җөмләдән, большевиклар бу көндә Төркестан эчендәге Фиргәнә өлкәстенең иң олуг вә җанлы шәһәрләреннән булган Хокандны тупка тотканнар. Шәһәрдә олуг байлар гына түгел, хәтта һәрбер йортлы кеше таланып, йортларына утлар төрткәннәр, хәдсез-хисапсыз кешеләр суелган, мәчетләр җимерелгән. Соңыннан исә берникадәр кешеләр кулга алынган. Кулга алынганнар эчендә Шаһиәхмәдев (татар), Чанышев, Хафиз Нурмөхәммәдев вә Габдулла Газин әфәнделәр дә бар. Юрист Шаһиәхмәдевнең бер кулы да сынганлыгы аңлашылды. Һәрхәлдә, Төркестанда никадәр вакытлардан бирле мөселманнарны сую, шәһәрләрен тупка тоту, йортларын яндыру кебиләр һаман кызганнан-кыза гына бара.

Төркестан мохтариятен оештыру эшендә, үзбәкләр һәм казакълар белән бергә, татарлар да катнаша. Аларның беренчесе – Ислам Шаһиәхмәдев (1886-1922), журналист, мохтарият рәисенең урынбасары, вице-премьер. Аның абыйсы, әлеге мәкаләдә искә алынган Шаһгали Шаһиәхмәдев – югары белемле юрист. Икенчесе – Мәһди Чанышев, Хәрби Шура рәисе.

1921 елгы ачлык вакытында әлеге газетаның мөхәррире булган Мөхәммәдсадыйк Иманколый Мәскәүнең Ачларга ярдәм Үзәк комиссиясе тарафыннан, Идел буе ачлары файдасына иганә-ярдәм җыяр өчен, Бохарага һәм Хивага командировкага җибәрелә.

Иттифакъ. – 1918. – №6. – 20 март.

Беренче май көне

Эшче халкының гомуми вә урта булган 1 нче май көне Казанда тыныч кына үтте, һичбер тәртипсезлекләр булмады. Халык урамда нөмаишләр *(демонстрация)* кылып йөргәндә, берничә җирдә тукталып, нотыклар да сөйләнде. Юнысовлар мәйданындагы митингта сөйләүче хатыйблар эчендә Ильяс әфәнде Алкин да мөнбәргә менде вә алкышлар эчендә кызу нотык белән үзенең фикерен әйтеп төште.

Бу бәйрәмгә Казан мөселманнары узган елдагы шикелле күп катыша алмадылар. Чөнки бу көннәрдә Казан мөселманнарында узган ел бу вакытта булган өмидләр вә шатлыкларның эзе дә юк. Бу көннәрдә эчке Русия мөселманнары өчен бәйрәм итә торган көннәр түгел, кайгы вә матәм көннәре иде. Бөтен Эчке Русия вә Себер мөселманнарының күз нурлары урынында газиз вә мөхтәрәм булган олуг мөәссәсәләре *(оешмалары)* – Милли Идарә һәм аның шөгъбәләре тупас көч тарафыннан таратылу вә ябылулары, һич шөбһәсез, мөселманнар өчен иң зур кыйгылардандыр ки, бу вакытта анларның күзләренә бәйрәмнәр күренерлек түгелдер.

Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының Милли идарәсе – милли-мәдәни мохтариятнең югары башкарма идарәсе 1918 елның гыйнварында Милләт Мәҗлесе карары белән оеша. Рәисе – Садри Максуди. 1918 елның апрелендә Совет хакимияте тарафыннан тыела.

Иттифакъ. – 1918. – №10. – 3 май.

Хокандта Төркестан мохтарияте таркатылган мәл. 1918 ел

Ханымнар өчен төрекчә-нимесчә курслар

Өченче көннән бирле Фатыйма Аитова гимназиясендә ханымнар өчен төрекчә вә нимесчә махсус курслар ачылды. Теләгән ханымнарның шунда барып язылулары тиеш. Шәһәребездәге мондый вакытлы дәресләрдән файдаланып калырга без гомумә хатын дөньясына киңәш итәмез.

Иттифакъ. – 1918. – №10. – 3 май.

Ибтидаи мәктәп укытучыларының протесты

Казан ибтидаи *(башлангыч)* мәктәп укытучыларының 29 апрельдә булган гомуми җыелышы, Милли Идарәнең таратылуы мөнәсәбәте белән озак мөзакәрә *(бәхәс)* иткәннең соңында, түбәндәге карарны чыгарды: «Без, Русиядә яшәүче мөселман төрек-татарлары, аерым милли тел, милли әдәбият вә башка милли хосусияткә малик *(ия)* тарихи бер милләт булдыгыбыздан, безнең милли-мәдәни берлегемезнең бөтенлеге өчен үзебезгә махсус мөәссәсәләр *(оешмалар)* булуы табигый. Мәдәният дөньясында һәр милләт фәкать милли-мәдәни мөәссәсәләре берлә генә чын хокуклы булып яши.

Хәзерге туганлык, тигезлек шигарен алда торкан халык хөкүмәте үзенең төп максатларыннан берсе итеп «Һәр халыкның үз тәкъдирен хәл итүне үзенә тапшыру тиеш» дигән шигарьне алган иде. Шулай була торып та, бу хөкүмәт тарафыннан безнең мәркәз – Милли Идарәбез таратылды. Без, бөтен Казан ибтидаи мәктәп укытучылары, Милли Идарәбезнең таратылуына җаннарыбыз белән ачынабыз. Милли-мәдәни берлегебезне бетереп, бер милләт булып яшәвебезгә бик зур зарбә *(бәхетсезлек)* итеп аңладыгыбыздан, шуңар ирек бирүче халык хөкүмәтенең бу эшенә үзебезнең разый булмаганлыгыбызны ап-ачык итеп әйтәмез».

Иттифакъ. – 1918. – №10. – 3 май.

Журналга ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Борһан Шаһиди *(1894-1989) –* *Кытайның күренекле дәүләт эшлеклесе, галим һәм язучы*

Март аенда Буа якташлык җәмгыяте офисында әлеге шәхескә багышланган түгәрәк өстәл утырышы узды. Анда Буа якташлык җәмгыяте президенты **Ирек Закиров**, «Җыен» татар теле һәм мәдәнияте үсеше фондының рәисе **Разил Вәлиев,** академик **Индус Таһиров,** «Борһан Шаһиди» китабын төзүче **Гәрәй Рәхим,** профессор **Хатыйп Миңнегулов**, «Җыен» фондының башкаручы директоры **Фуат Рәфыйков**, «Татнефть» АҖнең «Рухият» яңарыш фонды директоры урынбасары **Рамил Миңнуллин,** Б.Шаһидинең «Ялкынтау газабы» пьесасын тәрҗемә итүче **Әхәт Гаффар**, Б.Шаһидинең тулы биографиясе чагылыш тапкан махсус китап язып, аны татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарган автор **Ринат Мингалиев**, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон,** «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталары һәм «Татарстан» радиосы журналистлары **– Р.Минһаҗ**, **Й.Шәрәпова**, **Ф.Лотфуллина** катнашты. Борһан Шаһиди мирасы, Кытайда һәм Россиядә татар факторы турында барган әңгәмәдә әйтелгән кайбер фикерләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.

Борһан Шаһиди һәм Кытай Коммунистлар фиркасе ҮКның 1 нче рәисе Мао Цзэдун

Разил Вәлиев:

– Бөек шәхесләр – һәр милләтнең тәрәге, аның алтын баганасы. Шуны истә тотып, «Җыен» фонды инде ике дистә ел дәвамында күренекле шәхесләребезгә багышланган китаплар чыгарып килә. Галимнәребез тарафыннан әзерләнгән алты дистә китап дөнья күрде инде. «Шәхесләребез» сериясеннән чыгачак китапның чираттагысы Борһан Шаһидигә багышланачак. Ул – Аксу авылында туып, 15 яшенә чаклы Буа төбәгендә яшәп, аннан Кытайга барып, шунда гомер итеп, дәүләт дәрәҗәсендә дан казанган, хәтта Мао Цзэдунның ярдәмчесе булган күренекле шәхес. Галим буларак, ул «Уйгырча-кытайча-урысча лөгать» төзи, шигырьләр яза, аның драма әсәре барлыгы да билгеле. Борһан Шаһиди Кытай белән мөселман илләре арасында төп арадашчыларның берсе була.

Без берничә ел элек Кытайның Голҗа һәм Өремче шәһәрләрендә булган идек. Шунда Борһан Шаһидинең улы һәм аның гаиләсе белән очраштык. Алар белән бергәләп «Туган тел»не җырлаганыбыз әле дә истә.

Борһан Шаһиди – шактый каршылыклы шәхес. Аны Кытайда һәрчак күккә чөеп кенә торганнар, димәс идем. Ул озак еллар төрмәдә дә утыра. Шенҗан-Уйгыр автономияле районында яшәүче татарлар язмыш аны төрле юнәлешләргә этәргән, дип тә саныйлар. Ни генә сөйләсәләр дә, аның башкарган олуг хезмәтләрен берничек тә инкяр итеп булмый. Ул, чыннан да, зур шәхес – галим, язучы, сәясәтче… Борһан Шаһидигә тәүге тәрбия һәм белем биргән халык – татар халкы. Аның тамырлары монда. Шуңа да без аны үзебезнеке дип саныйбыз!

Гәрәй Рәхим:

– Борһан Шаһидинең хәзерге Татарстан территориясендәге эшчәнлеге артык зур түгел. Дөрес, аның турында төрле ялгыш фикерләр дә таралган. Ә чын фикерләрне, аның татарның олуг шәхесе икәнлеген белүчеләр азрак. Максатыбыз – Борһан Шаһидинең безгә аз билгеле булган якларын ачу һәм шәхесенә гадел бәя бирү.

Биографиясе турында сөйләгәндә, ул, беренче чиратта, тумышы белән татар, аның туган теле – татар теле, беренче әсәрләре Казанда басылып чыккан газеталарда татар телендә дөнья күрә.

Борһан Шаһидинең Кытайдагы галим һәм дәүләт эшлеклесе буларак хезмәтләре кытай һәм уйгыр телендә. Ләкин без, ул үзенең эчке халәте һәм таланты белән чын татар булганы өчен, «Шәхесләребез» сериясеннән чыгачак бу китапны татарча бастырып чыгару ягында. Шул сәбәпле, кытай һәм уйгыр телендәге хезмәтләре татар теленә тәрҗемә ителде. Аның иҗади мирасы белән кызыксыну да татар җәмәгатьчелегенең бурычы булырга тиеш дип саныйм.

Китапка материалларны җыю катлаулы булды, чөнки Борһан Шаһидинең безнең илдә басылган әсәрләре аз. Ә менә Кытайда галим, әдип, дәүләт эшлеклесе бу-

ларак язган хезмәтләре, шигырьләре бихисап, сәхнәгә куелган пьесасы бар. Бу әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итүче белгечләрне табарга кирәк булды. Әлеге мәсьәләдә КФУның Рамил Хәйретдинов җитәкчелегендәге Халыкара мөнәсәбәтләр һәм көнчыгышны өйрәнү институтының бер төркем галимнәре ярдәмгә килде.

Ринат Мингалиев, Борһан Шаһидинең тормышы һәм эшчәнлеге турында саллы фактлар һәм фотолар туплап, китап язган. Миркасыйм Госманов, Йолдыз Хәлиуллин, Тәүфыйк Әйдиләрнең мәкаләләре бар. Буа якташлык җәмгыятенең дә аның белән бәйле кешеләре Кытайга барып кайтты. Алар Борһан Шаһидинең туганнары белән күрештеләр, ул булган җирләрне күрделәр, интервьюлар һәм истәлекләр язып алдылар. Болар барысы да җыентыкка кирәчәк.

Ринат Мингалиев:

– Минем «Борһан Шаһиди. Тарихта калдырган эзләр» дигән китабым 2011 елның май аенда 2000 данәдә басылып чыкты. Бу китап, Буа якташлык җәмгыяте тарафыннан, төрле өлкәләрдә яшәүче татарларның милли оешмаларына, китапханәләргә җибәрелде. Үземдә калдырылган 250 данәнең 50гә якынын Кытайның Өремче шәһәрендә яшәүче туганнарыма һәм танышларыма, ә калганнарын Татарстандагы дусларыма бүләк иттем. 2011 елның августыннан башлап сентябрь урталарына кадәр Өремчедә яшәргә туры килде. Шул вакыт эчендә Кытайда яшәүче татарлар, китабымны укып, андагы тарихи вакыйгаларның дөрес күрсәтелгән булуын хәбәр иттеләр. Димәк, алар, казан татарлары бик авыр аңларлык диалектта сөйләшсәләр дә, анда язылганнарны төгәл аңлаганнар. Татарстанда яшәүче татарларга килгәндә, минем китапны укып караганнарның күбесе нәрсә турында язылганны аңлап бетерә алмаулары турында әйттеләр. Үзебезнең татарларның саф әдәби телләрен белмәүләре мине уйга калдырган иде. Бу мәсьәләдә күңелемдә өмет чаткылары уятучылар да булды. Суд системасында эшләүче дусларымның берсе, китабымны укыгач: «Абзый, бу китабың бик матур телдә язылган!» – дип бәя бирде. 2014 елның язында мин, китабымны рус теленә тәрҗемә итеп, «Бурхан Шахиди. Следы в истории» дигән исем астында 1000 данә тираж белән бастырып чыгардым.

Хатыйп Миңнегулов:

– 1983 елны мин өч ай Ташкентта командировкада булдым, андагы Шәрыкны өйрәнү институтының кулъязмалар фондында эшләдем. Шундагы бер уйгыр егете: «Сез нигә Казанда Борһан Шаһидине күтәрмисез? Ул бит бөек, даһи зат!» – дигән иде.

Соңгы елларда Казакъстанга еш йөрим. Мөстәкыйльлек алганнан соң, казакъ галимнәре кытай чыганакларын шул дәрәҗәдә өйрәнәләр ки, анда бу эш белән шөгыльләнүче махсус белгечләр дә бар. Алар төрки, казакъ, уйгыр һәм

татарларга мөнәсәбәтле материалларны даими рәвештә китап итеп бастырып чыгара торалар. «Уйгырларны, кытай татарлары тарихын өйрәнә башласак, Борһан Шаһидигә төртеләбез. Сезнең галимнәрегез нигә аны өйрәнми?» – диләр. Борһан Шаһидинең китабын булдыру бик тә мөһим. Аны мөмкин кадәр тулы, камил итеп эшлисе иде. Алга таба, шуңа нигезләнеп, башка тикшеренүләр дә булыр.

Әхәт Гаффар:

– Күренекле татар язучысы Җәвад Тәрҗеманов Борһан Шаһиди турында: «Аны Нижгар ярминкәсендә зирәк малай булганы өчен приказчик итеп куйганнар. Шунда бер зур дәрәҗәле хәрби килеп чыккан да Борһанны үзенә денщик итеп алып киткән. Моның гыйлемгә сәләтен белеп, аны югары уку йортында укыткан. Ул менә шулай күтәрелеп киткән», – дип сөйләгән иде.

Борһан Шаһидинең дүрт пәрдәлек зур пьесасы Кытайда куелган. Пьесаның жанры билгеләнмәгән иде – трагедия дип куйдым. Әсәр шуның кадәр камил ки, аны бүген үк сәхнәгә куярга мөмкин. Уйгырларның ул вакыттагы сәяси тормышы безнең бүгенге вазгыятькә туры килә. Анда «Галиябану», «Зәңгәр шәл» пьесаларына охшаш мотивлар, җырлар да бар.

Индус Таһиров:

– Шушы эшне башкарып чыгарга алынганы өчен «Җыен» фондына һәм Буа якташлык җәмгыятенә зур рәхмәт! Әлбәттә, Борһан Шаһиди – бөек шәхес. Аңа әлегә кадәр тулысынча бәя бирелгәне юк. Бөтенебез беләбез: бүгенге дөньяда кытай факторы зур роль уйный, һичшиксез, аның белән хисаплашырга тиешбез.

Әмма Кытайда һәм Ерак Көнчыгышта, гомумән, дөньяда татар факторының тиешле дәрәҗәдә күрсәтелгәне юк. Хәзерге көндә безне мескен рәвештә генә күрсәтеп киләләр. Ә бит Кытайда татар факторы бик борынгыдан килә. Аларда нинди музыка дисәң, безнең музыка! Бер Кытай галименең миңа болай дип әйткәне бар: «Бездә – сезнең моңыгыз! Бездә – сезнең музыка!» Татар музыкасы Япония һәм Вьетнамга кадәр барып җитте. Кытай музыкасы татарныкына охшаш. Әмма шул ук вакытта бүгенге татар сәхнәсендә яңгырый торган җырларыбызның күбесе татарныкына охшамаган! Хәзерге көндә җырны шоуменнарга гына тапшырып калдырырга ярамый! Кайчак радиотыңлаучыларның сораулары буенча концерт тыңлыйм. Бер генә тыңлаучы да татар милли җырын тапшыруны сорамый. Зәвыгыбыз шулай түбәнмени?

Борһан Шаһидинең Кытай үсешенә керткән өлеше нинди? Ни өчен ул иң дәрәҗәле җитәкчеләрнең янында эшләгән? Чөнки аларга аның фикере кирәк булган! Кытайдагы татар фикере турында әлегә кадәр юньле тикшерү булганы юк. Борһан Шаһидигә мөнәсәбәтле бу мәсьәләгә зуррак игътибар бирелсен иде.

Безнең мирас №5 май 2020

«Борһан Шаһиди» китабын төзүче Гәрәй Рәхим һәм Буа якташлык җәмгыяте президенты Ирек Закиров

Татарның дөнья мәдәниятенә керткән өлеше, әйткән фикерләре иксез-чиксез. Аяныч ки, аларны барлый алганыбыз юк.

Шикләнмим: татар Җир Кояш тирәсендә әйләнүдән туктаганчы яшәр. Әмма ул ни рәвештә булыр? Элеккечә бөек дәүләтле булырмы? Дөньяга үз йогынтысын арттыра алырмы? Шуның өчен, әлбәттә, безгә татарның, сан ягыннан бигрәк, хәзерге сыйфаты турында уйларга кирәк...

Разил Вәлиев:

– Кытайдагы татарларның күбесе дәрәҗәле урын алып торган, ул бүген дә шулай. Алар – укытучы, табиб, араларында хәтта хатын-кыз генерал да бар. Кытай татарлары Сабан туйларын да гөрләтеп үткәрәләр, зиратларны да карап тоталар. Борһан Шаһиди – татар белән уйгырны берләштергән шәхес. Уйгырларның татарларга уңай мөнәсәбәте юктан гына барлыкка килмәгән. Аларның дәреслекләренә Тукай шигырьләре кертелгән. Берзаман Голҗа шәһәрендә, кунакханәдән чыгып, урам буйлап барганда, ресторан тәрәзәсеннән колакка таныш көй ишетелә башлады. Ресторанга кергән идек: уйгырлар «Сарман» җырын үз телләрендә җырлап утыра... Очрашулар вакытында уйгыр шагыйрьләре безгә Тукай шигырьләрен яттан сөйләделәр. Кызганыч, XX гасыр дәвамында татарның Шәрыкка мөнәсәбәте үзгәрде. Без Көнбатыш мәдәниятенә, Европага йөз белән борылып, Шәрыкны читкә тибәрдек. Кытайдан яки Япониядән безгә иҗат төркемнәренең, театрларының, галимнәренең килгәне бармы? Борһан Шаһидинең иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнү безне Шәрык дөньясына якынайта төшсен иде.

Гәрәй Рәхим:

– Уйгыр язучыларының ПЕН-клубы бар. Алар: «Уйгырлар татар әдәбиятын шулкадәр яхшы белә иде һәм без үзебезне татар кешеләре дип саный идек. Сез безне татар дисәгез дә, без риза», – диләр.

Татарлар Россия дәүләтен күтәрүдә, аны данлауда хезмәт куя. Хәзерге көнгә кадәр әлеге процессның дәвамын күрәбез. Россиядә Татарстан социаль-икътисадый яктан беренче урында, республикабызның дөнья күләмендә дәрәҗәсе югары.

Индус Таһиров

«Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар. 20 март, 2020 ел

Ринат Мингалиев:

– Уйгыр мәгърифәтен күтәрү эшен башлаучылар – татар мөгаллимнәре. XX гасыр башында уйгырлар арасында белемле кешеләр бик сирәк булган. Турфан өлкәсендәге Астана шәһәрендә яшәүче сәүдәгәр, уйгыр мәгърифәтчесе Мәксүт Мөһиди, 1909 елда Казанга килеп, Хәйдәр Минһаҗетдин улы Сайрани белән таныша. Хәйдәр аңа татар балаларына яңа юнәлештә белем бирүе турында сөйли. Мәксүт Мөһиди аңа Астанада да шундый ук юнәлештә укыту эшләрен оештырырга тәкъдим итә. Хәйдәр 1909 елдан башлап Астанада Мәксүт Мөһиди йортында бер төркем балаларга белем бирә башлый. Уйгыр теле татар теленә якын булганга күрә, уку-язу «җәдит»чә башкарыла. Укучылар саны ел саен арта бара һәм яңача укырга Өремчедән кадәр килә башлыйлар. 1913 елга Мәксүт Мөһиди мәдрәсәгә янкорма класслар эшләтә. 1914 елны Хәйдәр Казаннан тагын берничә укытучыны чакыртып ала. Шулар арасында Малик Чанышевның «Кытайда татар мәгарифе тарихы» дигән хезмәтендә искә алынган Гөләндәм абыстайның ире Мөһибулла Хәбибуллин да була. Без Ирек Мөниревич белән, Астанада аның каберендә булып, Гөләндәм абыстай куйдырткан ташны фотога төшереп алган идек. Шул вакытта безне бер уйгыр кешесе үз өенә кунакка чакырды. Аның әтисе Астана мәктәбендә татар мөгаллимнәрендә укыган икән. Әтисенең әйтүенә караганда, алар мәктәптә бер телдә, ә өйгә кайткач, икенче телдә сөйләшә торган булганнар. Шул сәбәпле, алар татар телен уйгырларның әдәби теле дип уйлаганнар.

Разил Вәлиев:

– Кытайда 5-6 мең чамасы татар яши. Голҗада озак еллар татар мәктәбе эшләгән. Без, шул мәктәп бинасына кереп, булачак академигыбыз М.Госманов укыган партага да утырып карадык. Без барганда, анда музей оештырырга җыеналар иде. Татарлар Кытайда иң алга киткән цивилизацияле халыкларның берсе санала. Югары белем алучылар саны буенча, процентлар белән чагыштырганда, татарлар Кытайда беренче урында тора. Шунлыктан, аларның Кытайдагы төрки халыкларга, аеруча уйгырларга йогынтысы зур булган.

Индус Таһиров:

– Россиядә дә татар факторының тиешле дәрәҗәдә бәяләнгәне юк. Дөрес, Мәскәү дәүләтенең Алтын Урдадан чыкканын танырга мәҗбүр булдылар. Казанны яулап алдылар да татар факторы бетте дип уйлыйлар. Һич кенә дә алай түгел! Аннан соңгы елларда да Европа биредәге биләмәләрне Россиянеке дип танымый: «Тартария», «Казан ханлыгы» җирләре дип уйлый, карталарга шулай төшерә. Көнбатыш белән мөнәсәбәтләрне җайга салырга кирәк булганнан соң, Мәскәүдә «Казанское царство» дигән рәсми-дәүләти мөһер булдыралар. Халыкара килешүләрне менә шул мөһер белән ныгыта торган булганнар. Урта гасырларда Россия ни өчен шуңа бара? Чөнки аны танымыйлар, Казан ханлыгы юк, ә рус патшалары шул исем белән халыкара мәйданга чыга. Шулай итеп, татар факторы мөстәкыйль татар дәүләтләре беткәннән соң да дәвам итә. Татарлар Россия дәүләтен күтәрүдә, аны данлауда хезмәт куя. Хәзерге көнгә кадәр әлеге процессның дәвамын күрәбез. Россиядә Татарстан социаль-икътисадый яктан беренче урында, республикабызның дөнья күләмендә дәрәҗәсе югары. Бу бит юктан түгел! Ул элеккеге татар факторының дәвамы.

Ирек Закиров:

– Буа районының Аксу авылыннан бертуган Шәһретдин, Борһан, Гыйльметдин, Галимҗан Шәрәфләр чыккан. Гыйльметдиннең кызы Шәфика Шәрәф астроном, фән докторы булган. Профессор Рәмзи Вәлиевнең Галимҗан Шәрәф турында «Фаҗига» дигән китабы бар. Бертуган Шәрәфләрнең эшчәнлеге, иҗаты һәм фаҗигале язмышлары хакында яңа китап чыгарып булмасмы? Буа якташлык җәмгыяте бу эштә ярдәм итәчәк.

Ринат Мингалиев:

– Ирек Мөниревичнең фикерен хуплыйм! Бертуган Шәрәфләрнең әле биш кыз туганы да булган. Шул кыз туганнарының балалары турында да берничә сүз әйтеп китү кирәктер. Җәлилчеләрнең берсе булган Фуат Булатов – Зифа Шәрәф-Булатованың улы. Атаклы библиограф, профессор Энҗе Кәрим кызы Сәгыйтова – Халисә Шәрәф-Сәгыйтованың кызы. Күренекле язучыбыз Җәвад ага Тәрҗеманов – Һаҗәр Шәрәф-Тәрҗемановaның улы. Мәшһүр композитор Алмаз Монасыйпов – Фатыйма Шәрәф-Монасыйпованың улы. Бу шәхесләрнең һәрберсе турында аерым китап язарлык.

Индус Таһиров:

– Тел галиме, язучы, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Галимҗан Шәрәф турында сөйләгәндә, аның дәүләтчелегебезне тергезүгә керткән өлешен, һичшиксез, беренче урынга чыгарырга кирәк. Революциягә кадәр үк ул Петербургта «Татар учагы» дигән сәяси оешма булдыра. Ильяс Алкиннар шуның мәктәбен үтәләр. Идел-Урал, ТАССРның беренче карталарын Галимҗан Шәрәф төзи. Ул дәүләтчелегебез өчен көрәшеп корбан була. Гомумән, тормыш юлларын барлыйсы, кылган гамәлләренә яңача бәя бирәсе шәхесләребез бихисап.

*Журналга **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*
Фотолар beznenmiras.ru сайтында ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Принц Ито белән күрешү

Принц Ито ул көннәрдә бакчасындагы җәйге йортында яши иде. Бакчалары Нигатага якын гына яр буенда икән. Поездга утырып, без шунда килдек. Бер егерме минут җәяү барасы булды. Олы юлның ике ягында да биек-биек агачлар үсә, иртәнге салкынча һавада тирә-ягыбызга каранакарана атлыйбыз. Каршыбызга бер кеше килә. Безгә таба килеп җитәрәк таныдык: Принц Ито үзе икән. Яныбызга килеп җитте, исәнләштек. Ул, елмаеп, болай диде:

– Ялгышмасам, син Ибраһим булырга тиеш.

– Әйе, Сезнең белән күрешеп сөйләшү шәрәфенә ирешермен дигән өмет белән килүем.

– Рәхим итегез, мин чиксез шат. Тик алдан ук гафу үтенәм: вакытым бик аз. Тәхет варисының «Автомобиль белән киләчәкмен» дигән телеграммасын алдым, бүген аның белән ауга барабыз.

– Алай булса, рөхсәт итегез, башка бер көнне килербез, – дидем дә Конт Окоманың хатын суздым.

– Тәкъдим хатына ихтыяҗ юк. Мин болай да Сезне көтә идем. Очитайаның үзенә дә әйткән идем, – дип, тәкъдим хатын, карап та тормыйча, кесәсенә тыгып куйды. – Тагын ике сәгатьләп вакытыбыз бар. Бу форсаттан файдаланыйк та, тәхет варисы килгәч, Сез китәрсез, – диде. Боларны сөйләшә-сөйләшә бакча өенә кадәр килдек.

Чәйләр эчтек, төрле темаларга сөйләштек.

Принц Ито – япон халкының иң бөек фикер иясе, үз гомерендә озак еллар министрлыкларда эшләгән. Соңгы елларда исә Корея буенча иң өстен командачы булган. Хәтта Кореяда да аңа зур өстенлекләр бирелгән, үзе теләгәнчә эш йөртү ирегенә ия булган.

Бераздан Принц Ито болай диде:

– Кичерүегезне алдан ук үтенгән идем инде, вакытым бик аз, бүген Сезнең белән җитди мәсьәләләр буенча сөйләшә алмаячакбыз. Шул ук вакытта Сезне янымнан җибәрәсем дә килми. Шулай да бернәрсә сорарга телим Сездән. Зинһар, әллә ниләр уйламагыз, максатым – бары тик сәбәбен белергә теләвем генә, чөнки кешенең вөҗданына каршы барып хәрәкәт итүе өчен мотлак зур бер сәбәбе булырга тиеш дип уйлыйм. Бу шундый хәл: мондый нәрсәләр һичбервакыт сәбәпсез генә була

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

алмый, тик нинди сәбәп була алыр икән? Үзем бик күп уйландым бу хакта, акылым белән берни дә аңлый алмадым. Бу Кавказ мөселманнары, үзләре теләп, сугышка ни өчен килеп катнаштылар икән? Идел мөселманнарының, хәрби хезмәткә алынган гаскәри булсалар да, үз теләкләре белән килмәгәнлекләре мәгълүм хәл иде. Кавказ мөселманнары белән булган бу хәлнең нинди сәбәпкә нигезләнгән булуы мөмкин?

Бу хакта миннән Принц Итога кадәр дә сораучылар булды һәм бу минем өчен бик авыр мәсьәлә иде. Ничек кенә җавап бирергә уйласам да, кимчелегем гаебемнән зуррак булачак. Гомумән, ул Рус-япон сугышына Кавказ мөселманнарының үз теләкләре белән барып катнашулары бөтен мөселман дөньясы өчен йөз карасы булды. Ләкин ни эшләмәк кирәк, булган шул менә.

Теләр-теләмәс кенә: «Минем үземнең дә берни аңлый алганым юк, җаһиллектән башка бернинди сәбәп тә күрмим», – дип әйтергә мәҗбүр булдым. Принц Ито кебек шәхестән, беренче күрешүебездә үк, мондый сүз ишетү миңа, чынлап та, бик авыр иде.

Принц Ито, кабатлап, тагын болай диде:

– Зинһар өчен, әллә ниләр уйламагыз, максатым бары тик бу хәлнең сәбәбен сорашып белү иде. Русиядә мөселманнарның гаделсезлеккә дучар халык икәнлекләрен беләм. Шулай була торып та, русларга үз теләкләре белән теркәлеп сугышка китү өчен йә көчле мәҗбүрилек, яисә нинди дә булса бер зур мәнфәгать сәбәп булырга мөмкин. Миңа шундый бер фикер килгән иде: бу Кавказ мөселманнарының форсаттан файдаланулары булмадымы икән? Беләсез лә инде, андый вакытларда хөкүмәттән берәр нәрсә таләп итәргә мөмкин. Мәсәлән, «Без үз теләгебез белән сугышка катнаша алабыз. Әгәр дә сез безгә шундый-шундый өстенлекләр бирсәгез,

без бу сугышка үзебез теләп барырбыз...», – дисәләр, шул юл белән шактый гына өстенлекләр кулга төшерә алачаклар, сугышка да катнаша алалар. Әгәр чынбарлыкта моңа охшаш берәр нәрсә булган булса, без: «Афәрин!» – диячәкбез. Бар да үз мәнфәгатеннән чыгып эш йөртә. Милләте өчен һәртөрле форсаттан файдалана икән, моны яхшы дип табарга кирәк: «Афәрин!» – дияргә кирәк, әлбәттә.

– Ул дәрәҗәдә үк булмаса да, нигездә, берәр төрле мәнфәгать күз алдында тотканнардыр, эшнең асылын мин дә белмим.

– Мәмләкәтебездә, иншәАллаһ, тагын берничә ай калырсыз, тагын күп тапкырлар күрешербез. Тәхет варисының килеренә ярты сәгать вакыт калды, кичерә күрегез, ләкин бик тиздән, шушы ике-өч көн эчендә күрешүебезне үтенәм.

Мин аннан, поездга утырып, Йокохамага якын гына урнашкан Ходокайа дигән авылга киттем. Бу яктагы авыл кешеләреннән ишетеп, Ходокайа кечкенә генә авыл булса да, йортларының бик төзек һәм матур булуын, үзләренең газеталары чыгуын белә идем инде. «Ниҗи Ходокайа», ягъни «Ходокайа көннәре» дип атала торган бу газета атнага бер тапкыр басылып таратыла икән.

Биредә мин төн кунарга калдым. Авыл халкы бик зурлап кунак итте. Авылларның кайбер үзенчәлекләре билгеле, мәсәлән, авыл җире тыныч, аулак була. Бу авылдагы кешенең күплеге исә шәһәрләрдәгегә караганда артыграк та күзгә ташлана: чөнки шул кечкенә генә авылда өч фабрика бар, ул фабрикаларның эшчеләре барысы да авылда яши. Ике мәктәп, бер китапханә һәм бер уку залы бар. Моннан тыш, ук ату ярышлары үтә торган махсус бер җир бар, биредә иртә-кич, вакыт булганда ук атып күңел ачулар була икән. Болар, әлбәттә, авылларның барысында да бар.

Аннары мин биредән кабат Токиога киттем. Иртәгесе көнне төрмәләрен барып карарга карар бирдем.

Токиода төрмә

Токиодагы атаклы Сугамо төрмәсен барып күрим дип, рикша белән төрмә ишек төбенә килеп туктадым. Нәрсә генә диим икән: бу төрмәме, мәктәпме, ял бакчасымы, фабрикамы? Ни дияргә дә белмим. Бу төрмә диелгән җирнең урам капкасы хан сарае капкасы кебек күренә. Капка ачык, анда бары тик бер полиция кешесе генә тора һәм ул да безгә бер сүз дә әйтмәде. Без капкадан эчкә уздык. Төзек, матур бакча күреп, шаккатып торам. Моны күргән кеше, биредә төрмәдер, дип уена да китерә алмас. Бакча бик зур һәм бөтен җирендә тәртип. Төрмә белән бакча арасында бернинди бәйләнеш тә күрмим. Төрмәдә йөргәндә, мин тоткыннарга кызыгып карар дәрәҗәдә идем, хәйран калдым. Бакча беткән җирдә бер бина янына килеп җиттек. Сакчылардан берсе булса кирәк, безне каршы алды: «Рәхим итегез!» – диде, алдыбызга чыгып, безне кабул итү бүлмәсенә озатып куйды. Анда бер биш минутлап көтеп утырганнан соң, чәй китерделәр, аннары берсе аягүрә торып басты да:

– Теләгегез ни иде, рәхим итеп сөйләгез, – диде.

– Төрмәне карыйсым, күрәсем килә, – дидем.

– Визит карточкагызны рәхим итеп бирегезче, – диде.

Мин визит карточкамны бирдем. «Биш минут көтеп торыгызчы. Төрмә җитәкчесенә белдерим», – дип, бу кеше китеп барды. Биш минут та үтмәгәндер, төрмә җитәкчесе Йамагами җәнаплары килеп, безне үзе белән таныштырды.

Без дә үзебез белән таныштырганнан соң, мин:

– Рөхсәт итсәгез, төрмәне карап йөргәнгә кадәр, берничә сорау бирәсем килә, – дидем.

– Рәхим итегез, сорагыз.

– Тоткыннарның саны ничәгә җитә?

– Бүгенге көндә 1843 кеше.

– Иң күп дигәндә, төрмәгездә ничә кеше була?

– Иң күп булганда да, 2000 кешегә җиткәнен хәтерләмим. Соңгы елларда тоткыннарның саны хәтта кими бара. Бу елгы сан, узган елгы белән чагыштырганда, 14 кешегә кимрәк.

– Төрмәдә тауар җитештерүдән керемегез күп буламы?

– Ике йөз мең йен тирәсе керем була.

– Иң авыр җинаять эше өчен җинаятьче иң күбе ничә елга төрмәгә утыртыла ала?

– 12 елдан да күбрәк юк.

– Төрмә кеременнән тоткыннарның өлешенә күпмесен бүлеп бирәсез? Хезмәт хакы бармы?

– Һөнәргә карата билгеләнә. Кулыннан эш килә торган һөнәр әһеле һәм өйрәтә дә белүчеләр 70 процент ала. Гади эшче булганнар 30 процент ала. Боларны комиссия билгели. Комиссиядә дә тоткыннарның үзләре арасыннан өч кеше бар. Бу өч кешене эчке комиссия кешеләре арасыннан үзләре сайлап куялар.

– Эчке комиссия нәрсә ул?

– Без: «Эчке комиссия», – дибез. Төрмәдә 12 кешедән торган бер комиссия бар. Эшчеләрнең вазыйфалары һәм төрмәнең эчке эшләре бу комиссия карары буенча билгеләнә. Моннан тыш, бездә әле бер тышкы комиссия дә бар. Болар да 12 кеше. Боларның тугызы хөкүмәт тарафыннан билгеләп куела, өчесен үзләре эчке комиссия әгъзалары арасыннан сайлап куялар.

Бу сөйләшүдән соң, төрмәне карап йөрергә дип чыктык. Сәгать кыл 12 иде. Башта төрмә китапханәсенә килдек. Китапханә бик кечкенә, 15-20 кеше генә сыярлык. Китап куя торган җирләре дә бик юк. Шул сәбәпле, китапларны тоткыннарга үзләренә алырга рөхсәт итәләр, бар да үз камерасында укый икән. Китапларның күпчелеге – әхлак һәм дин турында. Төрмә башлыгы Йамагами җәнаплары: «Миңа бик уңайсыз. Безнең шәһәр хакимияте идарә эшләрен бик акрын алып бара. Шушы китапханәнең хәле турында инде ничә тапкыр язганмындыр, һаман эшли алмыйлар, һаман сүз биреп кенә котылалар», – диде.

Китапханәдән без тагын зур бер бакчага килеп чыктык. Бакчада сары киемле берничә кеше эшләп йөри иде. Башлык Йамагами әфәнде: «Бу – төрмәбезнең иген кыры. Төрмәгә кирәк булган ашлык һәм яшелчә биредә үстерелә, читтән берни кертмибез», – диде.

Аннары фабрикага, искиткеч зур эш урынына килдек. Төп гыйбрәт дәресе нәкъ менә монда иде. Бу – гаять озын коридор, ике ягында да эш урыннары бар. Башта тукучылык бүлегенә килдек. Без ишектән керүгә үк, сакта торган хәрби кеше шактый кычкырып нидер әйтте. Бөтен тоткыннар, эшләреннән туктап, билләрен бөгеп иелделәр, хөрмәтләп сәлам бирделәр. Хәрби сакчы тагын кычкырды, барысы да кабат эшкә тотындылар. Бу бик зур тукыма фабрикасы икән. Япония гаскәренә хәрби өс киеме өчен кирәкле тукыма биредә җитештерелә, моның янәшәсендәге бүлекләрдә киселә, аның янындагыларында тегелә. Бишенче бүлектән ул әзер өс киеме, чалбар булып чыга.

Аннан соң кулчатыр бүлекләре бар. Безгә мәгълүм кулчатырларның һәр кисәге аерым-аерым бүлекләрдә җитештерелә, бишенче бүлектән исә әзер кулчатыр булып чыга. Араларында иң гадиләре булган кебек, иң нәфисләре дә, ханымнар өчен махсус җитештерелә торган кулчатырлар да бар. Мин бу кулчатыр бүлекләренең тимер өлешләрен ясый торган бүлегендә игътибар иттем: биредәге тимерчеләрнең

ару һәм пөхтәлекләре шаккатарлык дәрәҗәдә иде. Утта тимер кыздырып торучының колак артларына кадәр карадым, тузанның эзен дә күрмәдем, югыйсә, үзе кызудан тиргә баткан иде.

Аннан соң бүрек җитештерү бүлекләре бар, алары бары тик ике генә бүлектән тора иде. Монда бик четерекле эшләр башкарыла. Аннан соңгы бүлекләрдә – гаскәри күлмәк һәм аяк киемнәре, гаскәри кирәк-яраклар. Юл капчыкларына кадәр барлык нәрсәләр дә биредә җитештерелә икән. Монда тимер эшләре дә, агач эшләре дә башкарыла. Хәтта велосипед та яңа баштан җитештерелеп чыгарыла. Кирәкле эш җиһазлары кызыгып, күзеңне ала алмас дәрәҗәдә иде.

42 бүлек эш җирләрен карап чыкканнан соң, ашханәләренә килдек һәм әзер ашларын күрдем. Биредәге арулык искиткеч иде, бу бары тик Япониядә генә була ала торган арулык. Петербургта зур-зур рестораннарның кухняларында да мондый арулык күрә алмассың. Аннан соң мунчаларын карарга киттем. Мунча ике зур бүлемнән гыйбарәт. Икесендә дә зур җылы су бассейннары бар. Су агыза торган җирдәге уемнар бик ару иде. Мунчаның бер бүлемендә 52 су краны санадым.

Аннан соң туры гыйбадәтханәләренә таба киттек. Төрмә башлыгы Йамагами җәнаплары безне кийусин (ягъни дин әһеле) әфәнде белән, аны безнең белән таныштырды. Кийусин җәнаплары безгә аңлатып, сөйләп барды, шулай коайдо ишегеннән кердек. Коайдо гаять гади, эчендә бары тик бер мөнбәр кебек нәрсә, бер юка кара такта, өстендә япон хәрефләре белән язылган ниндидер бер гыйбарә генә бар. Аның мәгънәсе мондый: «Кол, җаны борчулы булганда, Аллаһтан ни генә сораса да, догасы кире кагылмас».

Кийусин Таките җәнаплары болай диде:

– Без, һәр якшәмбе көнне биредә тоткыннарга әхлак һәм тәрбия дәресе биреп, вәгазь сөйлибез, үгет-нәсыйхәт бирәбез.

– Төрмәгә кергәннән соң, тоткыннарда берәр төрле үзгәреш буламы, Сез моны күрәсезме, әхлакларында берәр үкенү галәмәте сизеләме?

– Бик зур үзгәрешләр күрәм. Бик начар булып килеп, соңыннан бик яхшы булып чыгып киткән кешеләребез бар. Сүз тәэсирсез калмый. Безнең төрмәдә тәрбияләнеп чыккан бик билгеле кешеләр бар мәмләкәтебездә.

Аннан хастаханәләренә киттек. Кийусин Таките җәнаплары да безнең белән бергә барды. Монда да биналар бик төзек иде. Без килгәндә, 26 авыру кеше бар иде. Бик күп дигәндә дә 50 кешедән артмый икән. Хастаханәнең үзенең аерым бер бакчасы бар һәм ул да авыл хуҗалыгы мәктәбе дип әйтерлек дәрәҗәдә иде.

Соңыннан тоткыннарның йоклый торган җирләрен барып карадым. Бу да зур бер бина, озын коридор. Ике яклатып бүлмәләр, анда арулык һәм тәртип искитәрлек, гыйбадәтханә дип уйларлык иде. Тоткыннарның урын-җирләре шулкадәр ару иде ки, хәтта ышанырлык та түгел. Көндез биредә беркем дә юк, барысы да әле күптән түгел генә без карап йөргән фабрикаларда эшлиләр.

Эш вакыты иртәнге алтыдан кичке сәгать бишкә кадәр, бер сәгать көндезге ял һәм бер сәгать ярым көндезге аш вакыты, нәтиҗәдә, 8,5 сәгать эшлиләр икән. Кичен ике сәгатьләп уку-өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Бөтен төрмәдә бары тик 21 кешенең генә уку-язуы юк, аларның да сигезе үз исемен яза белә.

Төрмәне тулысынча карап чыкканнан соң, кабат җитәкчелек бүлегенә килдек. Сәгать төгәл өч иде.

Төрекчәдән

***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №5 май 2020

«Сагындыра туып-үскән җир»

(Исфәндияр Ишгай)

«Безнең мирас»ны укучылар хәтерлидер: журналның быелгы (ягъни 2020 елгы) 1, 2, 4 нче саннарында мөһаҗәраттәге татар әдәбияты турындагы язмаларыбыз басылып чыккан иде. «Мәскәү татарларының штабы» (җитәкчесе – Рөстәм әфәнде Ямалиев) үтенеченә, матди ярдәме белән андагы материаллар, шулай ук Шиһаб Нигъмәтинең 1953 елда Мюнхенда нәшер ителгән җыентыгы өстәмә тираж белән басылып чыкты [Шиһаб Нигъмәти. «Әй, татарым, әй, син – җаным!» (Казан: Ихлас, 2020. – 84 б. Басмага әзерләүчесе – Х.Миңнегулов). 2020 елның 18 мартында Казанның «Миллият» йортында «Мәскәү татарларының штабы» бу басманы тәкъдим итү кичәсе оештырды. Киң җәмәгатьчелек (әдип һәм галимнәр, журналистлар, сәнгать әһелләре, сәясәтчеләр...) катнашкан бу чарада мөһим фикерләр яңгырады. Анда башка төбәк вәкилләре дә булды. Алар арасында шагыйрьнең Омскида (Омбыда) гомер кичерүче оныгы Муса Нигъмәтуллин да бар иде. Ул – 1965 елгы, ике институтта укып, инженер һәм психолог белгечлекләрен алган, ислам диненнән дә яхшы хәбәрдар, «Коръән» дә укый, Омскидагы татар милли-мәдәни тормышында да актив катнаша. М.Нигъмәтуллин Казанга да еш килеп тора икән. Кичәдә ул бик төпле чыгыш ясады. Миңа аның белән бераз әңгәмә дә корырга туры килде.

Муса әфәнде бабасы хакында аерым мәгълүматлар бирде. Ул 1990, 1991 елларда ике мәртәбә Алманиягә дә барган. Бабасы ул вакытта Мюнхеннән артык ерак булмаган «Брюкберг» шәһәрчегендә яшәгән (шунда ук җирләнгән дә). Бик тә абруйлы шәхес икәнлеген, берничә телдә (татар, урыс, төрек, алман...) иркен сөйләшүен дә искәртте.

Ш.Нигъмәти туган авылы Рәнчектә (себерчә – Рәнсектә), Свердловскидагы татар педтехникумында укый, үз авылында һәм Карагай мәктәпләрендә эшли. Бәдри исемле кызга өйләнә. Маркс, Нигъмәтулла, Эрнест исемле уллары була. Аларның күпсанлы балалары бар. Совет чорында Алманиядә әсирлектә булучыларга бик тә тискәре мөнәсәбәт, эзәрлекләүләр булу аркасында, шагыйрьнең гаиләсе, туган-тумачалары төрле төбәкләргә күчеп китәргә мәҗбүр ителә. Ш.Нигъмәти сугыштан соң Цицилия исемле алман хатыны белән янә гаилә кора. Сания исемле кызы, оныклары булуы мәгълүм.

Муса әфәнде бабасының «Дөнья гражданины» («Гражданин мира») паспортына ия булуын, төрле илләргә баруын, күренекле кешеләр белән аралашуын (болар арасында Төркия Президенты да бар) искә төшерде. Баксаң, Ш.Нигъмәти Истанбул университетында да лекцияләр укыган икән. Оныгы карашынча, Идел-Урал легионы төзелүкүп меңләгән татар-башкортларның гомерен саклап калуга ярдәм итә.

Әңгәмә вакытында янә бер кызыклы факт ачыкланды. Мусаның әтисе Нигъмәтулла, Тубылдагы педагогик уку йортын тәмамлагач, Вагай районының Сопра мәктәбендә мөгаллим булып эшләгән икән. Бу авыл — шагыйрь Булат Сөләймановның (1938-1991) туган төбәге. Муса әфәнде фикеренчә, алар туганлык җепләре белән дә бәйләнешле икән.

Ш.Нигъмәтинең оныгы хәзерге вакытта бабасы, нәсел-нәсәбе хакында китап язуы турында да искәртте.

* * *

Күрерменме шатлык, азатлыкны
Мине үстергән туган халкымда?!

* * *

«Аһ, мин нигә тудым анадан?!»

* * *

Күтәр башың, яңгырасын таушың,
Хөррият булсын мәңге юлдашың!

* * *

Тату яшә, нәслең үрчет, тарат,
Аерылмый милли юлыңнан...

Болар һәм аларга охшаш үкенечле һәм сагышлы да, максатчан һәм өметле дә юлларны гомеренең ярты гасырдан артык өлешен читтә уздырган Исфәндияр Ишгай (Әсфәндияр Чынбай) (1.02.1908-16.06.1992) иҗатыннан күпләп китерергә

Исфәндияр Ишгай улы Илхан белән



мөмкин. Аның исеме, әсәрләре мөһаҗирлектәге милләттәшләребезгә шактый таныш. Илдә дә бу затны теге яки бу дәрәҗәдә белүчеләр бар.

Советлар берлеге таркалгач, башка мөһаҗир әдипләр белән бергә, аның да исеме, әсәрләре илдә телгә алына башлады. Мәсәлән, Әбрар Кәримуллин «Төркиядә «Казан» журналы» мәкаләсендә (Казан утлары. — 1997. — №2) бу шагыйрьнең эшчәнлеге, аерым әсәрләре хакында кайбер мәгълүматлар бирә (163 б.). Тәүфикъ Әйдинең «Кардәшләр кочагында» исемле китабында (К., 2000) «Әсфәндияр Чынбай» турындагы күзаллаулар тагын да тулылана төшә (211-219 б.). Язма авторы бу зат белән Анкарада очрашуын да искә төшерә, аңа мондый тасвирлама да биреп китә: «Озын буйлы, озынча йөзле, күбектәй ап-ак чәчле абзый. Сиксән өчне тутырса да *(димәк, бу очрашу 1991 елда булган. — Х.М.)*, әле аек фикер йөртә, озын-озак гомер агышында туплаган тәҗрибәсен һәм белемен яшьләргә тапшырып калдырырга каударлана, шуңа күрә, безне тыңлаудан бигрәк, үзе сөйләргә комар» (211 б.). Т.Әйди бу затның тормышы, иҗаты, аеруча 1956 елгы җыентыгы турында мөһим генә фикерләр әйтә, аның шигъриятен шактый югары бәяли. Без фәкыйрегезнең дә ике гасыр аралыгында, нигездә, мөһаҗәрәт тематикасына язылган мәкаләләрендә [Аларның кайберләре безнең «Чит илләрдәге татар әдәбияты» (К., 2007, 142, 244-245… б.), «Иҗади гамәлле шәхесләр» (К., 2014, 98-99, 236… б.) исемле китапларда туплап бирелгән] И.Ишгай турында аерым күзәтү-фикерләр бәян ителә, хәтта аның «Яшүсмер», «Чын дус…» шигырьләре, улы Илхан белән төшкән фоторәсеме дә укучыларга тәкъдим ителә. Әмма шулай да әле бу затның тәрҗемәи хәле, иҗаты тиешенчә өйрәнелмәгән, барланмаган.

И.Ишгай белән якыннан аралашкан Минһаҗ Исмәгыйли, Шакир Абилов аның башлангыч гомер юлын Төмән тирәсендәге атаклы мәдрәсәле Янбайга бәйләп [шагыйрь Мәүләкәй Юмачиковның (1834-1910) укыган, эшләгән карьясе], шагыйрьнең фамилия-кушаматын да (Янбай, Чынбай) шуның белән бәйләнештә аңлаталар иде. Минем бу якларда, шул исәптән, Янбайда да берничә мәртәбә булганым бар. Шундагы очрашу-әңгәмәләрдә дә И.Ишгай Янбайда яшәгән, бирелдәге мәдрәсәдә укыган дип әйтүчеләр булды. Т.Әйди исә бу затның Тубыл төбәгендәге Кызылбайда тууын, башлангыч белемне шунда алуын искәртә (214 б.).

И.Ишгай 20-30 нчы елларда күп кенә татар зыялылары укыган Свердловск татар педтехникумында, Оренбург пединститутының татар бүлегендә белем ала. Аның үз төбәгендәге бер мәктәптә, Ульяновск (1937-1938) һәм Тубыл (1938-1941) педучилищеларында татар теле һәм әдәбияты укытуы мәгълүм. Шушы елларда ул гаилә дә корып җибәрә. Аның 1944 елда әсирлектә язган бер шигырендә мондый юллар бар:

> …*Хатын уңды, алты бала үстердек,*
> *Арабыздан мәче узмады.*
>
> …*Күркәм холык, белем орлыкларын*
> *Мәктәп гөлләренә тараттык.*

Сугыш башлангач, күпләр кебек, И.Ишгай да фронтка озатыла. 1941 елның декабрендә, Мәскәүне саклаганда, ул әсирлеккә эләгә. Польша, Алмания һәм Франция җирләрендәге лагерь-төрмәләрдә иза чигә, Идел-Урал легионына да тартыла. Билгеле булганча, Советлар берлегендә әсирләргә бик тә тискәре караш

яши. Шуннан куркып, аларның шактые туган җирләренә кайтмыйча кала. Болар арасында И.Ишгай да бар. Биредә ул милли-мәдәни чараларда катнаша. И.Ишгай 1948 елда, бер төркем милләттәшләре белән, Төркиягә күчеп килә. «Ишгай» тәхәллүсен дә куллана башлый. И.Ишгай әүвәл Измир тирәсендәге Маниса шәһәрендә яши, төрек кызына өйләнә, өч балалары була. Төрле урыннарда эшли. Анкарага күчкәч, аның атаклы «Төрек культур институты»нда хезмәткәр булуы да билгеле. И.Ишгай Төркиядә яшәү елларында берничә китап бастыра, милли-мәдәни, фәнни тормышта актив катнаша. «Казан утлары»нда (1972. – №6) без бастырган «Сөһәйл вә Гөлдерсен» турындагы публикациягә нигезләнеп, ул «Kazan» мәҗмугасында (1978. — №22) «Сәйф Сараиның яңа табылган әсәрләре» исемле мәкаләсен дә урнаштыра. И.Ишгай Төркиядәге һәм, гомумән, мөһаҗәрәттәге милләттәшләребез белән аралашып тора. Болар арасында аның аеруча әсирлектә вакытта танышкан Минһаҗ Исмәгыйли (1910-1995) белән дуслыгы гыйбрәтле. Алар хәтта бер-берсенә багышлап шигырьләр дә язганнар. «Чын дус» һәм «Дустым шагыйрь Исфәндияргә» дип исемләнгән бу парчаларда эмоциональ табигатьле, авыр язмышлы әлеге ике авторның бер-берсен тирәнтен аңлавы, үзара ихтирам-хөрмәт билгеләре ачык гәүдәләнә. Шигырьләрнең тәүге һәм соңгы строфалары болай яңгырый:

...Синдә күреп батыр милләтчене,
囚囚

Эштә тугрылыклы илдәшне,
Сөенәм мин, Минһаҗ, чит илдә дә
Тапканыма дусны, диндәшне.

* * *

Җырла, дустым Ишгай, матур итеп,
Җырла кычкырып татар җырларын.
Мактап Сарай, Кашлык шәһәрләрен,
Ак Идел һәм Җаек буйларын.

Гомеренең яртысыннан артыгын Төркиядә уздырган Себер татар шагыйре 1992 елда шул мәмләкәттә үк вафат та була, бик күп мәшһүр милләттәшләребез кебек, шунда ук (Анкарада) җирләнә дә.

И.Ишгай әдәби иҗат белән яшьтән үк шөгыльләнә башлый. Ә.Кәримуллин, Т.Әйди язуынча, аның шигырьләре 1928 елдан алып сугышка кадәр Мәскәү, Оренбург, Свердловск… калаларында нәшер ителүче гәҗит-журналларда, төрле җыентыкларда дөнья күрә. Бу елларда ул Хатыйп Госман, Абдулла Әхмәт, Нәкый Исәнбәт, Галимҗан Нигъмәти кебек әдип-галимнәр белән аралаша. И.Ишгай белән бер чорда Оренбург пединститутында укыган Шакир ага Абилов (1915-2004) әлеге затның шактый билгеле булуы, төрле чаралар оештыруы хакында сөйли иде, хәтта аның кайбер шигырьләрен яттан укуын да хәтерлим.

И.Ишгай төрмә-лагерьларда да, сугыш беткәч тә, Төркиягә күчеп килгәч тә, кулыннан каләмен төшерми. 1956 елда ул Анкарада тәүге җыентыгын бастыра. Алга таба аның «Вөҗдан гыйсыяны» (1962), «Хөррият, хөррият» (1963) исемле китаплары дөнья күрә. «Kazan» һәм кайбер башка мәҗмугаларда үзенең кайбер язмаларын бастыра. Шунысы гыйбрәтле: ул, Төркиядә гомер кичергән кайбер милләттәшләребез кебек, төрекчәгә күчми, үзенең газиз ана телендә язуын дәвам итә. Латинча хәрефләр белән басылган китаплары — моның ачык мисалы.

Кызганыч ки, И.Ишгайның Төркиядә басылган җыентыкларының бары берсе генә безнең кулыбызда бар. Шуңа күрә хәзергә 1956 елда дөнья күргән китап хакында гына сүз алып барырбыз.

«Җәһәннәмнән котылганнар» дип исемләнгән кечкенә форматлы әлеге җыентык 65 биттән гыйбарәт. Ул Төркиядә гамәлдә булган латин язуында. Бу илдә, кагыйдә буларак, башка төрки кавемнәрне үз исемнәре белән (татар, үзбәк, казакъ...) түгел, ә «төрек» дип атау гадәткә кергән. Еш кына әлеге атамага географик характердагы аныклагыч сүзләр дә өстәлә. Моның бер чагылышын без 1956 елгы китапта да күрәбез. Аның теле «Идел-Урал төрекләре ләһҗәсендә» дип искәртелгән. И.Ишгай үз шигырьләрен, Ш.Нигъмәти, М.Исмәгыйли кебек, саф татар әдәби телендә язган. Әмма Анкара җыентыгында, гәрчә сирәгрәк кенә булса да, аерым төрекчә сүзләр, элементлар да очрый. Алар инерция буенча төрек мөхәррире, наширлары тарафыннан кертелгән, күрәсең. Китап Мехмет Мөхеддин дигән кешенең төрекчә язылган кереш мәкаләсе белән ачыла (3-4 б.). Антисоветизм рухындагы бу язмада Советлар берлегендәге «Идел-Урал кавеме»нең язмышы, китап авторы, җыентыкның эчтәлеге, төзелеше хакында гына аерым мәгълүматлар бирелә.

Җыентыкта 31 шигъри әсәр урнаштырылган. Күпчелегенең язылу вакыты һәм урыны күрсәтелгән (Берлин, Миттенвальд, Ной-Ульм, Мюнхен...). Алар, нигездә, авторның Алманиядә яшәгән чорында, төгәлрәге, 1943-1948 нче елларда иҗат ителгән. Бары икесенең генә, («Ирек тавышы», «Җәһәннәмнән котылганнар») Төркиядә (Маниса, Һаузада) язылып, 1953 елда төгәлләнүе искәртелә. Әсәрләрнең күпчелеге лирик характерда. Берничәсе генә лиро-эпик табигатьле. Арада мәсәлләр дә күзгә ташлана («Партбилет»лы үрдәк», «Башын ашадылар», «Кәҗә күзлегендән»). Васыять, киңәш эчтәлегендәге бер робагый да бар («Аңлап сөйсәң ярны, керсез ярат!..»). Шигъри үлчәмнәрнең күпчелеге традицион (9, 10, 11 иҗекле юллар). Ике шигыре («Алдаган гыйшыкның җыры», «Күмелгән калебнең эзе») татар сүз сәнгатендә сирәк очрый торган өчьюллык строфа белән иҗат ителгән.

Каен булып гыйшкым үрелеп,
Яшел яфрак ярып шаулый-шаулый,
Күз алдымда торды күренеп.

Синең күңлең — сайрар сандугач,
Аңа кунып өзелеп сайрый-сайрый,
Оя корды, матур яз булгач...

* * *

Бик көттем, килмәде, үпкәләп соңыннан,
Хат салдым. Аяныч, ул барып,
Ул барып җитмәгән...

Китапның ахырында «Оеткылары алманчадан», ягъни немец поэзиясеннән файдаланып язылган өч шигырь дә урнаштырылган («Кайгылы ана», «Дөнья шул, дөнья», «Каршылык тулы тормыш»). [Билгеле ки, Алманиядә яшәп алган яисә гомер кичергән әдипләребез (Г.Исхакый, Рәшит Рәхмәти, Ш.Нигъмәти, М.Исмәгыйли, шул исәптән, И.Ишгай да) немецчә сөйләшкәннәр, укыганнар].

1956 елгы җыентыктагы әсәрләрнең идея-тематикасы, аеруча андагы сәяси

мотивлар Т.Әйди язмасында ярыйсы гына яктыртылган. Шуңа күрә әлеге һәм кайбер башка мәсьәләләргә кыскача гына кагылып китәбез.

И.Ишгай – гаять катлаулы, фаҗигале чор кешесе. Ул Рәсәй һәм Совет империясенең ачысын да, төчесен дә күрә, ишетә, кичерә, хәтта: «Нигә тудым мин анадан?» – дип әйтүгә кадәр барып җитә. Инкыйлаблар, дөнья һәм илдәшләр сугышлары, коточкыч ачлык еллары, сыйнфый көрәш, шәхес культының рәхимсез сәясәте дистәләрчә миллион кешеләрне корбан итә, төрмә-сөргеннәрдә газап чиктерә, камгак («перекати-поле») кебек, торган, яшәгән җирләреннән, илләреннән качып, күчеп китәргә мәҗбүр итә. Гадәттә, мондый яшәешне мифологик мәгънәдәге җәһәннәм сурәте белән атыйлар. Андый образ-картина гавам сөйләмендә, әдәбиятта, сәнгатьтә еш кулланыла. И.Ишгай да илдәге шул чор тормышын җәһәннәм белән тиңли. Китапның исеменә дә чыгарылган бу атама — җыентыктагы иң күләмле әсәр (13-25 б.). Бераз эпик элементларны да үз эченә алган әлеге поэма үзенең эчтәлеге, яңгырашы белән публицистик характерда. Анда илдәге гаделсезлекләр, эзәрлекләү-кан коюлар күптөрле чаралар ярдәмендә шактый тулы картина рәвешендә тасвирлана. Автор фикеренчә, Советлар берлегендәге аянычлы хәлләрнең, җәһәннәмдәй вазгыятьнең төп сәбәпчесе – совет хакимияте, коммунистик партия диктатурасы. Мәгълүм ки, мондый караш, ягъни антисоветизм, антибольшевизм ул чорда дөньяның күп мәмләкәтләрендә, аеруча Европада гаять киң таралган идеология, сәясәт. Аларның төп асылын Кремльнең большевистик хакимиятенә каршы көрәш тәшкил итә. Аны җиңмичә, илдә бернинди милли һәм шәхси азатлыкка да ирешеп булмый. Милли азатлыкка, хөрриятккә ирешү — автор иҗатындагы төп мотивларның берсе. «Җәһәннәмнән котылу» гына түгел, ул җәһәннәмнең төп сәбәпләрен дә бетерү, үз илеңдә матур, бәхетле яшәү – бу чордагы күп авторларның, шул исәптән, И.Ишгайның да максат-бурычы; чөнки «җәһәннәм»нән тыштагы ил-мәмләкәтләрдә дә ал да гөл түгел, аларның да үз проблемалары җитәрлек.

Мәгълүм ки, Советлар берлегендә – илнең үз эчендә андагы рәсми сәясәтне, Кремль хакимиятенең эш-гамәлләрен тәнкыйтьләү бик куркыныч иде. Шәхес культы чорында миллионлаган кешеләрнең бер гаепсезгә җәзага тартылуын, юк ителүен дә онытырга ярамый. Чит мәмләкәтләрдә, мөһаҗирләр иҗатында, аеруча Г.Исхакый әсәрләрендә исә Советлар берлегендәге хакимиятнең сәясәте, эш-гамәлләре кискен тәнкыйтьләнә, милли тормыштагы гаделсезлек-баштаклыклар фаш ителә, азатлык, хөрлек мәсьәләләре үзәккә куела. Шушындый ук сыйфат Ш.Нигъмәти, И.Ишгай һәм кайбер башка әдипләрнең иҗатларында да күзәтелә. Совет чорында «дошман», «сатлык» дип бәяләнгән бу төр затларның «антисоветчыл», «антикоммунистик» карашлары, СССР таркалгач, гавами колач алды. Инде соңгы чирек гасырда партия хакимияте дәверен олысы да, кечесе дә, урысы да, татары да, гади кешесе һәм җитәкчеләре дә сүгә, тәнкыйтьли, гаепли. Мондый вазгыять мөһаҗәрәттә язылган әсәрләрне, аларның авторларын да, тарихи шартларны исәпкә алып, объектив яктыртуны, бәяләүне таләп итә.

И.Ишгай күп кенә язмаларында эчке бер драматизм, киеренкелек күзәтелә. Автор, бер яктан, «җәһәннәми» вазгыять хөкем сөргән илне, андагы режимны кискен тәнкыйтьли. Икенче яктан, шул ил — аның газиз туган җире, асыл Ватаны, аннан аерылу, чит туфракта яшәү – лирик герой өчен газап. «Кайда булмыйм, кояш бер булса да, Сагындыра туып үскән җир», – бу И.Ишгайның яшәү чынлыгыннан саркып чыккан төп мәгънә. Сагыну, сагыш, җирсү авторның бәгырен телгәли. Ул өнендә генә түгел, төшләрендә дә ата-анасын, гаиләсен, якыннарын, туган

табигатен сагына. Зиндан-лагерьларда, чит мәмләкәтләрдә гомер уздырырга мәҗбүр булган лирик геройда җирсү хисләре күп мәртәбәләр көчле. 1956 елгы җыентыгындагы шактый юллар моны раслап тора.

Якташы, чордашы, язмышташы Ш.Нигъмәти (1912-1995) шигырьләрендәге кебек, И.Ишгай китабында да Себернең урман-сулары, Иртешләре, туган халкының гореф-гадәтләре, «сөннәт туйлары» еш телгә алына. Күрәсең, шуларны искә төшерү аңа билгеле бер юаныч бирә, күңел җәрәхәтләрен дәвалый. Нинди генә киртәләр, кыенлыклар булса да, автор газиз туган якларына кабат кайту турында хыяллана:

...Кабат кичтем абынып киң дөньяның
Утын-суын, михнәт авырын;
Мыскыллавын, ачлык җәзаларын,
Эссе-салкын, җилен-давылын.
Ят илләрне гиздем, күмсәләр дә,
Үз илемдә каулап үлемгә...
Бу көннәргә җиттем, мең шөкер, сау
Йөрәгемнең саклап түрендә
Атам-анам, туган, дус-ишләрне,
Туган авыл, туган өйләрне,
Туган сулар, туган басуларны,
Туган халкым, туган көйләрне.
Әйтче, чынлык, тагын булырмынмы,
Йөрерменме алар алдында?
Күрерменме шатлык, азатлыкны
Мине үстергән туган халкымда...

Игътибар итегез: әрнү-сыкрану, газап-михнәт, теләк-өмет белән сугарылган бу юллар – һич тә хыял җимеше түгел, ә кырыс чынбарлыкның, шәхси язмышның конкрет гәүдәләнеше.

1956 елгы җыентык, гәрчә шактый кечкенә булса да, гомумән, фикер-күзәтүләргә, факт-мәгълүматларга, уй-кичерешләргә, шигъри сурәтләргә һәм чараларга шактый бай. Анда тарих та, соңгы дәвер тормышы да, сәясәт һәм әхлак та, мәхәббәт һәм табигать тә (еш кына алар үзара тыгыз бәйләнештә бирелә) гәүдәләнеш тапкан. Лирик геройның фаҗигале, аянычлы язмышы, шигырьләрдәге уй-кичерешләр бүгенге укучының да игътибарын җәлеп итәрлек. XX йөз татар сүз сәнгатендә бу китапның да үзенә лаеклы билгеле бер урыны бар.

Хатыйп Миңнегулов,
филология фәннәре докторы, КФУ профессоры ■

Җиңүгә – 75 ел

Тальян моңы

Сәяф Шәйхи

Әтием Гарафетдингә багышлыйм

Күңелемне телеп,
Кинәт кенә
Яңгырады тальян тавышы.
Сулыш алмый тыңлыйм
Тетрәндергеч моңны,
Бу кемнең соң күңел сагышы?

Тын һавада йөзә
Гармун моңы,
Кем уйный соң шулай сайратып?
Моңнар канатында
Үткәннәргә кайттым,
Моңсу хисләремне яңартып.

...Малай чагым, сугыш беткән еллар,
Сагыш тулы иде авылда.
Күпме ир-егетләр
Ятып калды
Сугыш дигән утлы давылда?!

Бик күпләрнең берсе –
Минем әти,
Утыз җиде яшьлек ир-егет.
Алтмыш елым узды, әтиемнең
Җылы сүзләренә тилмереп.

Тик бер генә тапкыр,
Күзләремә карап:
«Улым», – диеп әйтүен ишетсәм,
Сабый чакка кире
Йөгереп кайтыр идем,
Килеп керсә әгәр ишектән.

Кайтмады шул әти,
Кара язу гына
Шакып керде өебез ишеген.

Шул мизгелдә
Сугыш дигән афәт
Дер селкеткән сабый бишеген.

Улы калган илдә,
Җыры калган,
Вараксины калган өстәлдә.
Әгәр кайталмасам,
Улым уйнар, диеп,
Әйткән булган илдән киткәндә.

Насыйп булмады шул
Әтием гармунында
Авыл көен сузып уйнарга.
Уйнамадым кичке уеннарда,
Уйнамадым Сабантуйларда.

Әни мәрхүмәгә үпкәләмим,
Күңелем бармый,
Кулым да һич бармый язарга.
Ни эшләсен,
Бер пот бәрәңгегә
Алыштырган аны базарда.

Мәрхәмәтсез, явыз
Ачлык килеп,
Урын алгач өстәл артында,
Әни бәгырькәем,
Күз яшьләрен йотып,
Чыгып киткән кышкы салкында.

Соңгы адым –
Бары шушы гармун,
Соңгы ышаныч, өмет яктысы.
Әйтә иде әни:
«Атаң төсе киткәч,
Саулыгымның бетте яртысы».

Сәяф Шәйхи (Сәяф Гарафетдин улы Шәйхиев) 1941 елның 1 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районындагы Урта Сон авылында туган. Шигырьләрен мәктәптә укыганда ук яза башлый. Күпсанлы шигырьләре, хикәяләре төрле район һәм республика газета-журналларында дөнья күрде. Әдәби эшчәнлеге өчен ул Мамадыш район газетасының Дмитрий Крещенов һәм Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш район хакимиятенең Шәйхи Маннур исемендәге премияләренә лаек булды.

Аерым әсәрләре үз вакытында «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарында, «Идел» журналында басылган шагыйрьнең Чаллы һәм Казан нәшриятларында 11 китабы дөнья күрде.

С.Шәйхи 2012 елның октябрендә вафат булды.

Ә аннан соң
Күпме еллар узды,
Язмыш баштан сыйпап тормады.
Сугып екты, тартып торгызмады,
Таптап үттем диеп уйлады.

Ләкин ялгышты ул,
Үстек әрсезләнеп,
Ятимлеккә бирешеп тормадык.
Тамак ачкач, әнис тамыры чәйнәп,
Киләчәкне көтеп чыдадык...

...Күңелләрне телеп,
Кинәт кенә
Яңгырады тальян тавышы...
Үткәннәрдән кайткан җыр-моңнарның
Киләчәккә китеп барышы.

Күңелем тагын
Сагыш белән тулды –
Сискәндергеч моңны тыңладым да.
Әтием рухы,
Тальян моңы булып,
Йөри кебек авыл урамында...

Сәяфнең әнисе Бибихәдичә

Үсмер Сәяф

...Канлы-яшьле, авыр, газаплы сугыш елы дип тормаганмын, туасы булгач, барыбер туасы инде, озак көттерүнең нигә кирәге бар, дигәнмендер, 1941 елның 1 сентябрь иртәсендә Кызыл Йолдыз районының Урта Сон авылында дөньяга аваз салганмын. Сизенгәнмендер инде, күрәсең, әтиемә, өченче сентябрь көнне яу кырына чыгып китәргә дип чакыру килгән булган. Әнием мәрхүмә дә: «Син иртәрәк тудың, әтиемне күреп калыйм дип уйлагансыңдыр», – дип әйтә иде. Нинди уйлау ди ул... Ә, бәлки, уйлаганмындыр да... Хәтерләмим.

Тальян гармуны белән бергә мине кочагына алып урам әйләнгәннән соң, үзенең бу дөньяда дәвамы, аның гомерен дәвам итәрлек улы калуына сөенеп китеп барган әтием.

Әтиемә шул китүеннән әйләнеп кайту насыйп булмый. Мәскәү астында барган канкойгыч сугышларның берсендә 1941 елның 13 октябрендә һәлак була ул. Үзе дә юк, сурәтләре дә юк карарга...

Сугыштан соң, авыр еллар.
Керфекләрдә – өмет яше...
Кайтмаганнар кайтыр, диеп
Өметләнде карты, яше.

Керфекләрдә – сугыш яше,
Ә күзләрдә – түземлелек...
Авыл башы. Җил капкадан
Әти кайтып керер кебек. ■

Мәрҗани хәзрәтнең вафаты*
(1818-1889)

Мәрҗани хәзрәте соңгы елларда үзенең картайганлыгын вә ашаган ашларының эшкәртелүе читенләшкәнлеген сөйли иде. Үлем хастасыннан элекке җәйдә Урдага кунакка барып кайтуында пароходта сөйләгән сүзләре арасында гаиләсенә бәйләнеше булган бер кешедән зарланып сөйләгәндә: *«Минем гомеремнең ахыр вакытлары җитте, мин инде озак яшәмәм, Аллаһы әгъләм [яхшырак белүче], мин бу кыштан гына чыгармын»*, – дигән иде. Чыннан да, ошбу сәфәреннән кайткач та Ташкичүгә барды, ата вә бабаларының каберләренә зиярәт итеп, сәламәт кардәшләре белән күрешеп кайтты, кыш ахырларында авырый башлады. Авыруы көчәеп, мәдрәсәгә килүдән гаҗиз булгач, ханәсенә чакырып, дәрес бирде. Ханәсенә дәрескә шәкертләрнең яшьрәкләре дә барып, күп шәкерттән ханәнең һавасы да бозылмасын өчен, «Тәүзыйх» дәресенә керүчеләрнең генә баруы мәслихәт табылып, беренче шартның икенче бүлегеннән булды, бу дәрес 1306 ел, 13 рәҗәбтә иде, вә икенче дәрескә гакыйдә укучылар гына барып, дәрес алып кайттылар.

Вә шулай дәрескә шәкертләр бүлеп-бүлеп кенә җибәрелеп торды. Соңра, хәзрәтнең хәле авырлана башлагач, шәкертләрне дәрескә барудан туктатты. Беркөнне остаз

*Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. («Шәхесләребез» сериясеннән). – Казан: Җыен, 2010. – 534-536 б.

Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтнең 45 яшендәге рәсеме

хәзрәтләре безнең иптәшләрдән Хафиз бине Шаһиморат вә Кәшшаф бине Шаһимәрдан вә бу фәкыйрь өчебезне чакыртты. Без барсак, остаз рахимәһүллааһү [Аллаһы Тәгалә аны ярлыкасын] тәмам үлем түшәгенә яткан иде. Яткан урынында безгә бу васыятьне сөйләде: *«Минем китәр вакытым якынлашты, мин сез өчегезне «Хашийәтет-Тәүзыйх»ны төзәтүдә үземнән соң калдырдым, яхшы игътибар берлән төзәтегез, мин язган дип кенә асыл нөсхәгә туры китерү белән канәгатьләнмәгез, әгәр дә өчегез бергә каршылыклы тапкан урыныгыз булса – үзегезчә төзәтерсез, мин дә сезнең кебек бәндәмен, хата кылуым бик мөмкин, хатадан бәндә азат булмас»*, – дип, янә берничә нәсыйхәтләрдән соң: *«Хушыгыз! Аллаһыга тапшырдым»*, – диде, безгә мәдрәсәгә кайтырга рөхсәт итте.

Сонынннан янә көннән-көн хәле зәгыйфьләнде, вә, ниһаять, 1306 һиҗри ел, шәгъбанның 28ендә дүшәмбе көнгә каршы кичтә сәгать сигездә бу галәмне калдырып китте, вә дүшәмбе көн сәгать икедән соң җеназасын мәйданда бик күп халык белән улы Борһанеддин хәзрәт үтәде. Рахимәһүллааһү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ [Аллаһы Тәгалә аны киң рәхмәте белән ярлыкасын].

Авыруы вакытында даими рәвештә Коръән укыган вә: *«Коръән мәгънәләре күңелгә җиңеллек бирә»*, – дигән. Вафат булачак көн көндез бер арада: *«Бу көн сәгать сигездә алырга киләләр»*, – дип әйтеп куйган. Гомеренең соңгы вакытларында әйткән сүзләре: *«Һәрвакыт Коръән укыгыз, һич иренмәгез, рәхәтлек күрерсез»*. Соңрак «...вә ләү әннә күръәнән сүййират биһил-җибәлү әү кутыйгат биһил-әрду әү күллимә биһил-мәүтә, бәл лилләһил әмру җәмига...» [Ул Коръән белән таулар урыннарыннан авышыр, җир ярылыр, йә үлеләр телгә килер. Бәлки, һәр эш тә Аллаһ хозурында] аятен кабатлап укыганнан соң «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр; лә иләһә илләллаһү вәллаһү әкбәр; Аллаһү әкбәр вә лилләһил хәмдү»не, аннан соң «Сөбханәлләзи әгъта күллә шәйэин халькаһү сүммә һәдә...» [Һәрнәрсәне бар кылып, соңыннан аңа туры юл күрсәткән Аллаһы Тәгалә һәр кимчелектән азаттыр] аятен укыган, актыкта: «Аллаһү раббүнә вә раббүл-галәмин» [Аллаһ безнең Раббыбыз һәм барча галәмнәрнең Раббысы] дигән.

Мәрхүм остазның «Хашийәтет-Тәүзыйх» китабын бастырырга үзенең яшәгән вакытында ук җитәр кадәр чыгымны Салих бине Сабит Гобәйдуллин биргән иде, вафатыннан соң ошбу китап басылды. Баштагы биш төпне без өч иптәш дөресләдек. Соңыннан берничә кыенлыктан Хафиз белән мин төзәтү мәҗлесенә килүдән гозерле булдык. Биш төптән соңгыларын Кәшшаф әфәнде берүзе төзәтте, вә бу турыда җаваплылык аның җилкәсендә калды. Гафаллаһү Тәгалә ганнә вә ганһү әҗмәгыйн [Аллаһы Тәгалә безне дә, аны да, барчабызны кичерсен].

Габдеррахман бине Исмәгыйль бине Гомәр әл-Хаҗитархани (1867–1933).
1331 ел, зөлхиҗҗә 29 ■

Безнең мирас №5 май 2020

Яңа Татар бистәсе мирасы

Мәрҗанинең кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Мәгълүм булганча, мәшһүр галимебез Ш.Мәрҗани Казан шәһәренең атаклы Яңа бистә зиратында җирләнгән. Аның кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында. Әле үләренә өч ай кала ук, ягъни 1889 елның 25 гыйнварында, үзенең шәкерте мулла Гобәйдуллага ул хат белән ошбу васыятен язган: *«Үлсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше генә күтәреп китәрлек булмасын. Һәм рус сүзе, рус елы куелмасын»*[1]. Галимнең каберенә көрән төстәге граниттан эшләнгән зур, мәһабәт бер таш куелган. Аның тексты гарәп графикасында, татар һәм гарәп телләрендә язылган, вафат булу датасы һиҗри ел исәбе белән күрсәтелгән.

Таштагы текстның укылышы:
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаэддин
2) Мәрҗани
3) хәзрәтләринең җәмегъ итдеге асаре
4) фазыл вә кәмалинә борһан катыйгдыр бәлдәи Казанда
5) кырык сәнә микъдары ләвазиме имамәт вә нәшре голүм идеб
6) 1306 сәнә һиҗриййә шәгъбан мөбарәкнең ахыр йәүмендә
7) 73 синнендә иртихаль даре бәка әйләде рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

[1]Шәрәф Ш.Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәт илә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире – Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 191.

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Нәзым

2) әл-мәүтү фииһи күллүн-нәәси йәштәрикүү

3) вә ләә сүүкатүн йәбкаа вә ләә мәлик».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Нәзым

2) ә-ләә иннәмәәд-дүнйәә кә-зыйлли сәхәәбәтин

3) әзалләткә йәүмән сүммә ганкә идъмәхәлләт

4) фә-ләә тәккә фәрхәәнән биһәә хиинә әкъбәләт

5) вә ләә тәккә җәзәгаанән ләһәә хиинә вәлләт».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Мәшһәдүл-имәәми галләәмәтил-гаалими

2) саахибит-тәсаанииф-

3)–ил-фәәикати вәт-тәхкыйкаатир-раaикати Шиһабеддин бине

4) Баһаэддин әл-Мәрҗани иртәхәлә иләә рахмәти

5) Раббиһи тәгаммәдәһү Сүбхәәнәһү би-гафвиһи вә кәрамиһи гашиййәтә йәүмил-әхәди

6) ли-ләйләтин бәкыййәтин мин шәгъбәәнин сәнәтә 1306

7) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:

1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаведдин

2) Мәрҗани

3) хәзрәтләренең җыйган әсәрләре

4) хөрмәт һәм камиллегенә катгый дәлил. Казан шәһәрендә

5) кырык ел микъдары имамлык вазыйфаларын [үтәп] һәм гыйлемнәр таратып,

6) һиҗри 1306 ел мөбарәк шәгъбанының ахыргы көнендә

7) 73 яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһы Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы:

1) «Шигырь:

2) Үлем алдында һәр кеше бертигез,

3) гади халык та, патша да».

Сул ягы:

1) «Шигырь:

2) Чынлыкта, дөнья болыт күләгәсе кебек:

3) бүген сине күләгәдә тота, соңыннан югала.

4) Ул килгән вакытта аның белән шатланма

5) һәм ул киткән чакта аның өчен кайгырма».

Арткы ягы:

1) «Имам, күренекле галим,

2) бик яхшы әсәрләр

3) һәм гүзәл хезмәтләр иясе Шиһабеддин бине

4) Баһаведдин Мәрҗани кабере. Раббысы

5) рәхмәтенә (Аллаһ Сөбханәһү аны гафу итсен һәм хөрмәтләсен) кич белән якшәмбе көн

6) һиҗри 1306 (мең өч йөз алтынчы) елның
7) шәгъбаны тәмамланырга бер төн кала күчте».
Таш үлчәмнәре: 206(223)x52-55x35-38.

1911 елда Р.Фәхреддин якын дусты һәм фикердәше Г.Баруди белән бергә Мәрҗани каберен зиярәт кылган. Шул вакытта ул, ташның тулы текстын язып алып, аны үзенең хезмәтендә теркәп калдырган[2]. Әмма шунысы бар: Р.Фәхреддиннең тексты белән хәзерге вакытта сакланган таш тексты арасында бераз аерма бар. Мәсәлән, аның укылышыннан аермалы буларак, «Мәәтәл-гаалиму вә мәәтәл-гааләм» җөмләсе хәзерге ташта юк. Шулай ук «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ» җөмләсендә Р.Фәхреддин текстында «Тәгааләә» сүзе төшеп калган. Башка җирләре исә туры килә. Димәк, Мәрҗани вафат булганнан соң куелган кабер ташы соңыннан икенчегә алыштырылган, дип әйтергә нигез бар.

Галимнең беренче ташы Гобәйдулла исемле шәкерте тарафыннан утыртылган булган. XX гасыр башында Мәрҗани кабер ташының тузган булуы хакында Борһан Шәрәф болай язып калдырган: *«Шиһаб ахунд»ның кабер ташы берничә заманнар Казан мәкъбәрәсендә иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган»*[3]. Элек Мәрҗанигә куелган таш өстендә тулган ай торган. Г.Тукай үзенең мәшһүр «Шиһаб хәзрәт» шигырендә юкка гына галимне шуның белән чагыштырмаган:

«Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт».

Димәк, тулган ай – Мәрҗанинең символы. Әле 2017 елның язына хәтле ул тулган ай бар иде, ләкин соңыннан, галимнәр белән дә, җәмәгатьчелек белән дә киңәшләшмичә, аны ак төстәге ярымай сурәтенә алыштырып куйганнар. Әгәр дә элеккесе урынына тагын шундый ук яңа тулган ай сурәте куйган булсалар, яхшырак һәм дөресрәк булыр иде. Ярымайлы кабер ташлары күп, ә менә тулган ай куелган таш татарларда берәү генә иде, тик, кызганыч ки, хәзер юк инде. ■

---

[2] Фәхреддинев Р.С. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 179-179.
[3] Шәрәф Б.Мәрҗани хакында җавапларым // Шура. – 1911. – № 24. – Б. 759.

Батырлар табыла вакыт белән...

Илфар Габдрахманов

Тарихыбызда әле бик күп ак таплар бар, язылаcы мәкаләләребезнең һәм язмаларыбызның чиге юк. Күп еллар элек районыбыз газетасында Югары Тегермәнлек авылы лачыны, Бөек Ватан сугышы каһарманы, Ленин һәм Сугышчан Кызыл Байрак орденнары кавалеры Имам Низамов турында мәкаләләрем чыккан иде. Эзләнүләр нәтиҗәсендә моңа кадәр билгеле булмаган мәгълүматлар табылды, батырның тормышы, язмышы ачыкланды.

80 нче елларда мәктәптә укыганда икенче бер героебыз турында ишеткәнем булды. Атаклы разведчик дип горурланып сөйли иде аның турында авылдашларым. Сугышта һәлак

Газиз Габдрахманов җирләнгән туганнар каберлеге. *Калининград өлкәсе, Калинино бистәсе*

булган бу якташыбыз турында эзләнү эшләрен озак алып бардым, ниһаять, аның батырлыгын раслаучы документлар табылды, табылу гына түгел, алар мине шаккатырды, шатландырды. 1923 елда Югары Тегермәнлек авылында туган Газиз Габдрахманов батырлыклары өчен ике тапкыр Сугышчан Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз һәм Дан орденнары белән бүләкләнгән ләбаса! Ә хәзер бөтенесен дә тәртип буенча…

Сугыш алды документлары арасында авылдагы хуҗалыклар исемлеге Татарстан Республикасы Милли архивындагы 1 нче тасвирламаның 12 нче эштә сакланган, 1938-1939 елларга караган хуҗалык кенәгәсеннән шушы мәгълүматларны алырга мөмкин. 196 нчы сан белән Габдрахманова Шәмселхәят хуҗалыгы язылган. 1887 елгы бу авылдашыбыз улы Газизҗан (1923 елда туган) белән торган. 1935 елда алар колхозга кергәннәр, сыер, бозау, 6 сарык тотканнар. Шәмселхәят әби белемле булган, улы 7 класс белем алган (1933 елда авылыбызда җидееллык совет мәктәбе ачылган була). Әлеге гаиләнең йорты 1928 елда салынган. Шул ук елда абзар, келәт төзелгән. 1930 елда сарай корыла, синнекләре 1920 елда ясалганы билгеле.

1941 елның 22 июнендә сугыш башлана. 23 июньдә авылда шул уңайдан митинг була. Анда резолюция кабул ителә: *«Без, Югары Тегермәнлек авылы «Яңа юл» колхозчылары һәм авыл интеллегенциясе, тынычлыкны, тыныч хезмәт итүне сөюче Ватаныбызга безнең ил белән төзелгән договорны оятсыз рәвештә бозып һөҗүм итүче Германия фашистларына каты нәфрәт белдерәбез.*

Бу котырынган этләр үзләренең явыз фикерләрен тормышка ашыра алмаслар.

Безнең җиңелмәс Кызыл Армиябез Хәрби Диңгез һәм Һава флотыбыз котырынган дошманга тиешле отпорны бирер, аны тар-мар итәр.

Без, «Яңа юл» колхозы колхозчылары, сизгер дисциплиналы, оешкан булырбыз. Колхозыбызда намус белән эшләп, социалистик милекне күз алмасы кебек саклап, дәүләт йөкләмәләрен вакытыннан элек үтәп, социалистик Ватаныбызның оборонасын, куәтен тагын да ныгытырбыз.

Без чын күңелдән Ватанга, партиябезгә һәм хөкүмәтебезгә бирелгәнлегебезне белдерәбез. Без дошманны тәмам тар-мар итү өчен кулыбыздан килгәннең бөтенесен эшләрбез. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең чакыруы белән без барыбыз да Ватан сугышына барырга хәзерлегебезне белдерәбез. Без җиңәрбез, чөнки безнең белән Бөек Сталин җитәкчелек итә. Яшәсен коммунизм! Яшәсен бөтендөнья хезмәт ияләренең Ватаны – СССР! Яшәсен Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе, Хәрби Диңгез һәм Һава флоты! Яшәсен Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе! Яшәсен Халыклар юлбашчысы Сталин!»

Шушыңа охшаш документ 5 июль көнне дә 128 кеше җыелган җыелышта кабул ителә: *«Без, Югары Тегермәнлек авылы «Яңа юл» колхозы колхозчылары, юлбашчыбыз иптәш Сталинның 1941 елның 3 июлендә радио буенча чыгышын тыңлаганнан соң, түбәндәге карарга киләбез:*

1. Без, Совет гражданнары, фронтта гына түгел, тылда да фашизм өстеннән җиңүе хәл ителгәнлеген, безнең һәр эшебез фашизмга удар булып торганлыгын яхшы аңлыйбыз. Без юлбашчыбыз Сталинның чакыруына бердәй кеше булып кушылабыз. Без, «Яңа юл» колхозы колхозчылары, юлбашчыбыз Сталинның мөрәҗәгатенә җавап итеп, безнең Ватаныбызга җитди куркыныч туган көндә үзебезнең Ватаныбызның бәйсезлеген, бөтенлеген тәэмин итү өчен, фашизм өстеннән тәмам җиңүне тәэмин итү өчен, кулыбыздан килгәннең барысын да эшләргә сүз бирәбез. Безнең һәрбер эшебез фашизмга ныклы удар булып тора.

Без, «Яңа юл» колхозы колхозчылары, үзебезнең арабызда ныклы хезмәт дисциплинасы булдырырбыз. Безнең һәркайсыбыз үзенең өстенә алган эшне намус белән үтәр.

Без, «Яңа юл» колхозы колхозчылары, ант итәбез, без 1941 елның урып-җыюына иң яхшы рәвештә хәзерләнәбез һәм аны кыска вакыт эчендә югалтуларсыз үтәрбез.

Колхозда нинди генә эш булмасын, без ул эшне намус белән үтәрбез. Колхозыбызның милкен күз алмасыдай сакларга. Дәүләт йөкләмәләрен вакытыннан элек үтәргә. Урып җыю эшендә ирләрнең фронтка китүе аркасында кыенлыклар килеп чыкмасын өчен, урып-җыю машиналарында эшләү өчен кызларны өйрәтергә. Икмәкләребезне яхшы саклауны оештырырга. Һава һөҗүменнән һәм пожардан саклану чаралары оештырырга».

Әлеге җыелышларда Газизҗан да әнисе белән катнашкандыр дип уйларга кирәк. Авылдашлар аны кыскача гына Газиз дип йөрткәннәр. Документларда ул урысча Газис дип язылган. Аны 1943 елның 13 апрелендә армиягә алалар. 1943 елның 13 июненнән фронтта. 1943 елның 18 декабрендә ВЛКСМ сафларына кабул ителә. Комсомол билетының номеры – 19941777. 1943 елның 13 августында Харьков өлкәсендә кулы җиңелчә яралана, 1943 елның 23 декабрендә Городок дигән шәһәр янында икенче тапкыр җәрәхәтләнә, иягенә зыян килә. 1944 елның 14 августында батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә (11 нче Гвардия Армиясенең 059/Н приказы). 1944 елның 3 октябрендә Кызыл Байрак орденына ия була (11 нче Гвардия армиясенең 0143/Н приказы). Газиз Габдрахманов, үлгәннән соң, 1944 елның 6 декабрендә чыккан 095/н приказы белән III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә (командир отделения взвода пешей разведки 40 Гвардейского стрелкового Краснознаменного полка, гвардии старший сержант). Үлүе турында мондый мәгълүматлар билгеле: *«Дата рождения: __.__.1923. Место рождения: Татарская АССР, Кзыл-Юлдузский р-н, д. В.Тамандык. Дата и место призыва: Татарская АССР, Кзыл-Юлдузский РВК. Дата выбытия: 14.11.1944. Причина выбытия: умер, Госпиталь ХППГ 241. Первичное место захоронения: Восточная Пруссия, м. Мелькемен, западнее, 8 км, д. Варнен, могила №5, 1 ряд, 1-й с южного края».* Хәзер бу Калининград өлкәсенең Калинино поселогы. Торак пунктының үзәгендә батырлар каберлеге. Андагы плитәдә өлкән сержант Абдрахманов Г. исеме дә язылган. Архив документлары арасында 4 нче госпитальнең үлүчеләр исемлеге бар. Андагы язма буенча, Газиз 1944 елның 12 ноябрендә эче яралану аркасында вафат була.

Якташыбыз белән бәйле иң мөһим документ 1944 елның 31 октябренә карый. Бу язмага игътибар итегез әле: *«В период подготовки прорыва немецкой обороны и вторжения в Восточную Пруссию разведка, по приказу командования, выполнила ряд заданий по поиску военнопленного и разведыванию огневых средств и оборонительных сооружений противника на переднем крае.*

12.9.1944 года тов. Абдурахманов, как старший разведчик, руководил поиском. При приближении к переднему краю противника разведгруппа Абдурахманова столкнулась с немецкой разведкой с численностью до 60 человек. Использовав внезапность удара, Абдурахманов со своей группой шквальным огнем автоматов и гранатами посеял панику и дезорганизацию в рядах врага. Воспользовавшись этим, он захватил сам лично военнопленного, который дал впоследствии ценные сведения о противнике.

В очередном поиске 2.10.44 года товарищ Абдурахманов, будучи старшим захватывающей группы, бесшумно незамеченным подкрался к траншее противника, стремительным броском и ударом приклада он ошеломил бывалого немецкого солдата, несшего караульную службу. Захватгруппа, бесшумно вытащив немца из траншеи, вывела его в наше расположение. Разведчики привели в штаб полка «языка», давшего ценнейшие сведения.

18.10.44 г., разведывая группировку противника западнее с.Ланкупе (Восточная

Безнең мирас №5 май 2020



Кр. Знамя

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Фамилия имя отчество – АБДУРАХМАНОВ Газис
Военное звание – старший сержант
Должность, часть – Ком-р отделения взвода пешей разведки 40 Гв. стр. Краснознам. Полка 11 ГСГЮСД.

Представляется к высшей степени отличия – присвоению звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

1. Год рождения – 1923 г   2. Национальность – татарин
3. С какого времени в РККА – с 13.4.1943 года
4. Партийность – член ВЛКСМ с 18.12.43 г к/б 19941777
5. Участие в боях/где, когда/ – на фронтах отечественной войны с 13 июня 1943 года.
6. Имеет ли ранения и контуз. – легко ранен 13.8.43 в лев. руку под Ахтыркой-Харьковская область. Легко ранен 23.12.43 в нижнюю челюсть под г. Городком.
7. Чем ранее награжден – орденом "Кр. ЗВЕЗДА" пр. 059/Н от 14.8.44 года 11-й ГСГЮСД; орденом "КРАСН. ЗНАМЯ" прик. № 0143/Н 3.10.44 г 11-й Гв. Армии
8. Каким РВК призван – Казанским Горвоенкоматом.
9. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению или его семьи:

КРАТКОЕ КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО ПОДВИГА ИЛИ ЗАСЛУГ:

В период подготовки прорыва немецкой обороны и вторжения в Восточную Пруссию разведка по приказу командования выполнила ряд заданий по поиску военнопленного и разведыванию огневых средств и оборонительных сооружений пр-ка на переднем крае.

12.9.44 г. тов. АБДУРАХМАНОВ, как старший разведчик, руководил поиском. При приближении к переднему краю противника развед-группа Абдурахманова столкнулась с немецкой разведкой численностью до 60 человек. Использовав внезапность удара, Абдурахманов со своей группой шквальным огнем автоматов и гранатами посеял панику и дезорганизацию в рядах врага. Воспользовавшись этим, он захватил сам лично военнопленного, который дал впоследствии ценные сведения о пр-ке.

В очередном поиске 2.10.44 г. тов. АБДУРАХМАНОВ, будучи старшим захватывающей группы, бесшумно незамеченным подкрался к траншее противника, стремительным броском и ударом приклада он ошеломил бывалого немецкого солдата, несшего караульную службу. Захватгруппа, бесшумно вытащив немца из траншеи, вывела его в наше расположение. Разведчики привели в штаб полка "языка", давшего ценнейшие сведения.

18.10.44 г., разведывая группировку противника западнее с. ЛАНКУПЕ /Восточная Пруссия/, действуя группой в 3 чел., Абдурахманов достал ценные сведения о расположении и силах противника, а при столкновении с группой немцев отважные разведчики уничтожили до 20 немецких солдат и захватили пленного, подтвердившего ранее собранные данные. Тов. Абдурахманов питает безграничную ненависть к врагу. Любовь к Родине и сознание важности и ценности получаемых им данных о противнике воспитали в нем бесстрашного самоотверженного воина. Высокое мастерство и дерзость в выполнении задания выдвигают его в число лучших разведчиков РККА.

За бесстрашие и героизм в выполнении боевых приказов



тов. Абдурахманов достоин высшей степени отличия – присвоения звания "ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА".

Командир 40 ГСКП гв. подполковник /СКРЫННИКОВ/

31.10.44 г

Заключение вышестоящих начальников:

Достоин присвоения звания "Герой Советского Союза"
командир [illegible] гв. генерал-майор [illegible]

"2" ноября 1944 г.

Заключение Военного Совета Армии:

Достоин награждения орденом "КРАСНОГО ЗНАМЕНИ".

Командир [illegible] ГСК Гвардии генерал-майор / [illegible] /

"12" ноября 1944 года.

Заключение Военного Совета Фронта/Округа/

Заключение Наградной Комиссии НКО:

Отметка о награждении:

Өлкән сержант Газиз Габдрахмановны олы бүләккә тәкъдим итү турындагы документ

*Пруссия), действуя группой в 3 человека, Абдурахманов достал ценные сведения о расположении и силах противника, а при столкновении с группой немцев отважные разведчики уничтожили 20 немецких солдат и захватили пленного, подтвердившего ранее собранные данные. Тов. Абдурахманов питает безграничную ненависть к врагу. Любовь к Родине и сознание важности и ценности получаемых им данных о противнике воспитали в нем бесстрашного самоотверженного воина. Высокое мастерство и дерзость в выполнении задания выдвигает его в число лучших разведчиков РККА (Рабоче-крестьянская Красная Армия. – **И.Г.**).*

За бесстрашие и героизм в выполнении боевых приказов тов. Абдурахманов достоин высшей степени отличия – присвоения звания «ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА».

Әлеге документның авторы – 40 нчы гвардия полкы командиры, подполковник Скрынников. Аның югары җитәкчесе генерал-майор да 2 ноябрьдә бу документка раслап кул куя. Ләкин 12 ноябрьдә Армия командующие Гурьев бары тик Кызыл Байрак орденына гына лаеклы дигән виза куя. Фронт җитәкчелегенә бу «представление» барып җитми булып чыга, чөнки бүләкләнүгә тәкъдим итү документында Фронт советы җитәкчесенең визасы юк. Шулай итеп, авылдашыбызга Советлар Союзы Герое исеме бирелмичә кала.

Герой исеменә тәкъдим ителеп тә, бүләкләнмичә калган батырларыбыз тагын бар әле. Алар арасында авылдашымның булуы, бер яктан, шатландырса, горурлану хисләре уятса, икенче яктан, лаеклы бүләкне ала алмавы, әлбәттә инде, рәнҗетә.

Тулаем алганда, каһарман авылдашыбыз турында материаллар табу сөенечле хәл. Моңа кадәр билгеле булмаган мәгълүматлар ачыкланды, героебызның исеме Ватаныбызга кайтты. Эзләнүләр дәвам итә... ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

ОЛУГ МӨХӘММӘДКӘ – һәйкәл

Рәссам Рәфкат Вахитов рәсеме

Республикабызда киң колач белән ТАССР төзелүнең 100 еллыгына әзерлек бара. Шул уңайдан һәртөрле чаралар үткәрелә, ирешкән казанышларыбыз барлана, алга җитди бурычлар куела. Шөкер, шатланырлык, горурланырлык уңышларыбыз байтак. Нык чикләнгән булса да, мөстәкыйльлегебез дә бар. Әмма республикабызның юбилеена әзерләнгәндә үткәнебезгә борылып карау, дәүләтчелегебезнең чишмә башын күздән кичерү, бүгенге республикабызның элгәре булган дәүләтләрне төзүгә, аларны халыкара мәйданга чыгаруга, дөньяның иң алдынгы мәмләкәтләре дәрәҗәсенә күтәрүгә үзләреннән зур өлеш керткән шәхесләрне дә искә алып үтү урынлы булыр.

Мәгълүм булганча, болгарлар, татарлар гомер-гомергә дәүләт тоткан халыклар булганнар. Әле Х гасыр башларында ук болгар ыруг-кабиләләре Идел-Урал буй-

ларына күчеп килгәннәр һәм, шул төбәктәге күптөрле кабиләләрне туплап, Идел буе Болгар дәүләтен төзегәннәр.

Казан ханлыгы исә тарихыбызда аерым урын алып тора. Монда инде без дәүләтчелекнең барлык атрибутларын ачык күрәбез. Ни кызганыч, Идел-Чулман буенда чәчәк атып утырган бу дәүләт йөз елдан артык кына яшәп кала. Шуңа карамастан, ул безнең каныбызга, геннарыбызга дәүләтчелек рухын сеңдереп калдыра, халкыбыз тарихында гаять мөһим урын алып тора.

Бу язмада без ханлыкның бөтен тарихын сөйләп чыгуны максат итеп куймадык. Хәер, бу мөмкин дә түгел. Максатыбыз – игътибарны ханлыкка нигез салган кайбер шәхесләргә юнәлтү, аларның тарихтагы урынын кабат ассызыклап күрсәтү.

Тарихи чыганакларда: Казан ханлыгына Алтын Урда ханы Туктамышның оныгы, Җәләлетдин хан улы Олуг Мөхәммәд хан нигез салган, дип әйтелә. Хәзер инде ул чорның вакыйгаларын фаразларга гына мөмкин. Татарның урланган, таланган, яндырылган, баскын дәүләт елъязмачылары тарафыннан махсус рәвештә бозып язылган тарихыннан хакыйкатьне эзләп табу җиңел түгел. Әмма тарихчыларыбыз туплаган өзек-өзек мәгълүматлардан күренгәнчә, Алтын Урда тәхете өчен барган сугышларда Тимер хан улы Кече Мөхәммәд тарафыннан җиңелгәннән соң, Олуг Мөхәммәд, аз санлы гаскәре белән, Биләү (Белев) кальгасына барып урнаша. Бу хәл Мәскәү кенәзлегендә ризасызлык тудыра һәм Мәскәүнең бөек кенәзе Василий Икенче Темный, зур гаскәр туплап, Олуг Мөхәммәдкә каршы сугыш башлый. 1437 нче елның 5 декабрендә булган һәм тарихка «Биләү янындагы сугыш» дип кереп калган бу бәрелештә мәскәүлеләр җиңелә. Шулай да 1438 нче ел башында, ягъни берничә айдан соң ук, Олуг Мөхәммәд, гаскәре белән, Идел-Чулман елгалары тарафына китеп бара.

Танылган тарихчы, археолог, этнограф, тарих фәннәре докторы Михаил Худяковның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» дигән хезмәтендә Олуг Мөхәммәднең Биләүдән Болгар бәклеге җирләренә китүе әйтелә. Әмма даими кабатланып торган ызгыш-талашлардан, урыс князьләренең һөҗүмнәреннән, бигрәк тә князь Федор Пестрый җитәкчелегендәге урыс баскыннарының 1431 елгы көчле һәҗүменнән соң тәмам хәрабә хәленә килгән, халкы күпләп Чулман аръягына күченеп киткән төбәктә яңа дәүләт төзү перспективасын күрмәгән Олуг Мөхәммәд Казанга юл тота. **М.Худяков** бу хакта болай яза: ***«Поэтому хан Мухаммед избрал столицею своего государства не Булгар, а Казань, и новое ханство получило название Казанского ханства»*.*** Шулай итеп, бирелә – Алтын Урда дәүләте җирләренең төньяк өлешендә – Урта Идел буенда, элеккеге Болгар, Җүкәтау, Кашан, Казан һәм башка бәклекләрнең биләмәләрен берләштереп, Олуг Мөхәммәд 1438 нче елда Казан ханлыгын оештыра. *«Казан ханлыгына нигез салу планын гениаль план дип атарга була, чөнки Мөхәммәд хан борынгы җирле халыкның мәдәни үзенчәлеген аңлаган һәм Урта Иделдә мөселман дәүләтен торгызырга ниятләп, аның нык торачагын дөрес бәяләгән. Алдан күрүчәнлек белән эшләнгән проект зур осталык белән башкарылган һәм яңа төзелгән дәүләт бик куәтле килеп чыккан. Казан ханлыгына нигез салучының хәрби таланты һәм оештыру осталыгы аңа бу дәүләтне тиз арада шундый югарылыкка күтәрергә мөмкинлек биргән... Казан татарлары дәүләте боларның барысы өчен дә Олуг Мөхәммәдкә бурычлы»*, – дип яза М.Худяков үзенең алда искә алган хезмәтендә.

Мәхмүд хан турындагы кайбер язмаларда: *«Мәхмүд хан атасы вафатыннан соң Казан тәхетенә утыра»*, – дип әйтелә. Димәк, инде ханлык булган, аның

*Өземтәләрдәге исемнәр чыганаклардагыча бирелә.

тәхетендә Олуг Мөхәммәд утырган, Мәхмүд аның урынын ул үлгәч кенә биләгән. Мантыйк буенча шулай килеп чыга.

Әмма башка фикерләр дә бар. Тарих фәннәре докторы **Сәлам Алишев**, мәсәлән, Олуг Мөхәммәд, гомумән, Казанда булмаган дип саный. Аның фикеренчә, *«Казан дәүләтен (ханлыгын) Олы Мөхәммәд тә, Мәхмүд тә төземәгәннәр, 1445 елда бары тик династияләр генә алмашынган. Галимбәк (Казан бие. –* ***Г.Ш.****) үлгәч, Болгар династиясе тукталган, аның урынын Алтын Урдадан килгән Олы Мөхәммәд династиясе алган. Казан дәүләте исә XIV гасырдан ук яшәп килгән»*. (С.Алишев. «Казан ханлыгы тарихыннан»).

Академик **Индус Таһиров** С.Алишевның бу фикере белән килешеп бетми. Бу вакыйга *«...Болгар дәүләтендә ханнар алмашынуы гына түгел, аның сыйфат ягыннан да үзгәрүе була. Алтын Урда составындагы Болгар олысы яки вилаяте урынына асылда аны алыштырган яңа дәүләт барлыкка килә, Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд үзенең башкаласын Сарайдан Казанга күчереп куйган кебек була»*, – дип яза ул үзенең «Татар халкының һәм Татарстанның милли дәүләтчелеге тарихы» дигән хезмәтендә.

Тарих фәннәре докторы **Равил Фәхретдинов** та: *«...Мәхмүтәк, энеләре һәм атасының гаскәре белән килеп, Казанны ала, аның бие Галибине үтереп, Казан тәхетенә утыра. Менә шуннан яңа дәүләткә – Җүчи нәселеннән булган хан җитәкчелегендәге Казан ханлыгына нигез салына. Бу тарихи вакыйга 1445 елның 1 нче, яңа стиль белән 14 нче октябрендә, була»*, – дип саный. (Р.Фәхретдинов. «Татар тарихы»). **Димәк, быел Казан ханлыгы оешуга нәкъ 575 ел тула.**

Сүз дә юк: Казан шәһәре бу вакыйгаларга кадәр күп еллар алдан төзелгән була. Заманында ул Урта Идел буендагы иң матур калалардан санала. Безнең фикеребезчә, ул чорда Казан Болгар дәүләте составында *кала-дәүләт* сыйфатында, аның бер олысы – вилаяте булган. Европа тарихында андый мисаллар байтак. Олуг Мөхәммәд династиясе килеп урнашкач, шәһәрнең территориясе киңәя, аңа Болгар, Җүкәтау, Кашан һәм башка бәкләрнең биләмәләре дә кушыла. Сарайда хан булып торган, Төркия солтаны Морад II белән илчелек мөнәсәбәтләре урнаштырган, урыс кенәзләре белән аралашып яшәгән тәҗрибәле ханга да, әтиләренең үрнәген күреп, аның белән иңгә-иң торып походларда катнашкан улларына да моның өчен бөтен алшартлары булган урында яңа ханлыкны оештырып җибәрү артык кыен булмагандыр дип уйлыйсы килә.

Ханлыкка Олуг Мөхәммәд нигез салганмы, аның улы Мәхмүдме – бу очракта артык мөһим дә түгел. Биредә Р.Фәхретдиновтан тагын бер өзек китереп үтәбез: *«Олуг Мөхәммәд исә рәсми рәвештә Казан ханы булмаса да, аның исемен Казан тарихыннан аерып карап булмый. Ул – Казан ханнарының тарихына нигез салган кеше... Аның токымы Казан ханлыгы белән бу дәүләтнең беренче – тотрыклы һәм куәтле чорында идарә иткән»*.

Гомумән алганда, милли дәүләтчелегебезнең 3000 еллык тарихы бар. Бу язмада без, аның тарих күзлегеннән караганда, кыска, әмма үтә дә мөһим бер чорына гына тукталдык. Дәүләтебезнең чираттагы юбилеен билгеләп үтәргә җыенганда аның тарихындагы әлеге этапны да искә алып үтү урынлы булыр. Шул уңайдан татар халкы күңелендә күптән йөргән бер хыялны кабат искә төшереп үтәсем килә: Казаныбызның нәкъ уртасында, дәүләтчелегебезнең дәвамчанлык символы рәвешендә, ханлыкка нигез салган мәгърур хан һәйкәлен, ниһаять, күрәсе иде.

Габделхак Шәмсетдинов,
тарих фәннәре кандидаты ■

Истә, һаман да истә!

Шагыйрь
Әхмәт Исхакның
тууына 115 ел

Шагыйрь, СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1939) Әхмәт Исхак (Әхмәт Габдулла улы Исхаков) 1905 елның 1 маенда Казанда туган.

Аның «Кызыл кошлар» исемле тәүге шигыре 1923 елда «Кызыл Шәрык яшьләре» журналында басыла. «Таш урамнар җыры» дигән беренче шигъри китабы исә 1929 елда Мәскәүдәге СССР халыклары Үзәк нәшриятында дөнья күрә.

Ә.Исхакның кайбер китаплары: «Күңелле балачак» (1952), «Көзгегә үпкәләмә» (1959), «Ракеталар оча» (1961), «Мин җаваплы» (1964), «Уйланулар, елмаюлар» (1983), «Күңелле сәхифәләр» (2005).

Ул 1991 елның 24 июнендә Казанда вафат булды һәм Яңа бистә зиратында җирләнде.

Язучы
Мәгъсум Хуҗинның
тууына 90 ел

Күренекле язучы, оста хикәяче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986), СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1980) Мәгъсум Хуҗин (Мәгъсум Хәмидулла улы Хуҗин) 1930 елның 15 маенда Саба районының Тенеки авылында колхозчы гаиләсендә туган.

Әдипнең «Ерганак юл яра» дигән тәүге китабы 1961 елда басыла.

Хикәя жанрын үстерүгә керткән иҗади хезмәтләре өчен, М.Хуҗинга 1997 елда Татарстан Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге әдәби премиясе бирелә.

М.Хуҗинның кайбер китаплары: «Курагай атлары» (1973), «Авылым урамнары» (1978), «Урманлы үр» (1980), «Юл өзеге» (1990), «Мәхәббәт – һәлакәт?» (2000), «Айның уты сүнгән» (2004).

Ул 2008 елның 26 августында вафат булды.

Артистка
Галия Кайбицкаяның
тууына 115 ел

Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая 1905 елның 21 маенда Җаек (Уральск) шәһәрендә мәшһүр татар мәгърифәтчесе Мотыйгулла Төхфәтуллин гаиләсендә туган.

1923 елда ул Татар театр техникумына укырга керә. К.Тинчурин, С.Сәйдәшев, М.Фәйзи, Х.Әбҗәлилов, Ф.Ильская, Г.Болгарская белән аралаша.

Г.Кайбицкая 1940-1950 елларда Опера театры сәхнәсендә төп партияләрне (мәсәлән, «Алтынчәч» операсында – Алтынчәч, «Наемщик»та – Гөлйөзем, «Башмагым»да – Сәрвәр, «Качкын»да – Рәйханә, «Түләк»тә – Сусылу) башкара.

Г.Кайбицкая 1993 елның 16 маенда вафат булды.

Композитор
Фасил Әхмәтовның
тууына 85 ел

Күренекле композитор, Россия Федерациясенең (1992) һәм Татарстан Республикасының халык артисты (1995), РСФСРның (1981) һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1977), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фасил Әхмәтгали улы Әхмәтов 1935 елның 23 маенда Кукмара районының Салтык Ерыклы авылында туган.

1952 елда ул Казан музыка училищесының баян бүлегенә укырга керә. 1957-1962 елларда исә Казан дәүләт консерваториясенең теоретик композиция бүлегендә профессор А.С.Леман классында укый.

Ф.Әхмәтов, «Ф.Яруллин истәлегенә» дигән симфоник поэмасы өчен, Россиядә беренчеләрдән булып, М.Глинка исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Ф.Әхмәтов 1998 елның 6 сентябрендә вафат булды.

Язучы
Әбрар Кәримуллинның
тууына 95 ел



Күренекле татар галиме, китап белгече, библиограф, филология фәннәре докторы (1978), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1991) Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Татарстанның Саба районындагы Чәбия-Чүрчи авылында туган.

2000 елда дөнья күргән «Без тарихта эзлебез» дигән китабында автор татар халкының милли азатлык, тигез хокуклылык, мөстәкыйльлек өчен көрәшен фәнни-публицистик рухта яктырта.

Ул 2000 елның 18 сентябрендә вафат булды.

Язучы
Әмир Камалиевның
тууына 60 ел

Танылган драматург, прозаик, артист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1996) Әмир Аман улы Камалиев (Аманулла) 1960 елның 29 маенда Апас районының Шыгай авылында туган.

1984 елда Мәскәүдәге М.С.Щепкин исемендәге театр училищесына укырга керә. 1988 елда исә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли башлый. 1992 елда аның «Җәйге кырау» дигән тәүге драмасы Чаллы театрында куела.

Ә.Камалиевның кайбер пьесалары: «Әлепле әртисләре» (1995), «Итәкле кияү» (1995), «Кылый Кирам балдагы» (1996), «Кыйбла кайда?» (1998), «Моңлы ядкәр» (2001), «Бер кирпеч, ике кирпеч» (2004).

Ул 2019 елның 30 июнендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2020

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

«Туплар шартласа да, җырлар тынмый!»

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле.1943 ел

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, башка мәдәни үзәкләр шикелле үк, бик тиз арада хәрби тормыш ритмына кирәргә мәҗбүр була. Кайбер штатлар кыскара, Халык уен кораллары оркестры таркала, Фольклор кабинеты эшчәнлеге тукталып тора. Филармониянең 1941 елның 28 июнендәге 69 нчы фәрманыннан күренгәнчә, ул чорда бөтен эшчәнлек фронт бригадалары оештыруга юнәлтелә. Анда филармония, Опера һәм балет театры, радиокомитет солистлары – җырчылар, нәфис сүз осталары, биючеләр, баянчылар, скрипкачылар туплана.

Филармония артистлары Сәгыйть Алиев, Камил Басыйров, Гали Җәмлиханов, Фәйзи Садыйков, Шәриф Гәрәев, Нәзиф Сәлимов, Ильяс Якупов, Рәшит Гобәйдуллин, Габделхак Шаһиев, Мостафа Сәләхетдинов, Геннадий Гурфинкель, Николай Будрейко, Георгий Астапов, Рәйсә Волкова, Җәүдәт Айдаров, Николай Алексеев, Александр Бендецкий, Габдулла Рәхимкулов, Фәйзи Йосыпов, Георгий Астаповлар сугышка китәләр. Аларның шул еллардагы кичергәннәрен чагылдырган кайбер истәлек язмалары филармония музее архивында саклана. Шуларның кайберләренә тукталыйк.

Музыкант, гавай гитарасында уйнаган филармония артисты **Сәгыйть Алиев:** *«1941 елның көзендә Мәскәүдә татар декадасы булырга тиеш иде. Барлык сәнгать көчләре шуңа хәзерләнә башлады. 22 июнь көнне, якшәмбе көн булуга карамастан, филармониягә репетициягә җыелдык. Радио аша сугыш башлануы турында хәбәр ишеттек. Декадага хәзерлек эше туктатылды. Музыкантлар сугышка киттеләр. Мин 1941 елның декабрь аенда сугышка алындым. Казанда оештырылган 146 нчы пехота дивизиясенә эләктем. Сугышны Смоленск өлкәсендә башлап, җиңүне Берлинда каршыладым».* С.Алиев 1945 елның октябрь азагында Казанга кайта һәм үз эшчәнлеген Татар дәүләт филармониясендә дәвам итә.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оркестрының курайчысы, Бөек Ватан сугышы башлангач, яу кырында һәлак булган **Шәриф Гәрәевнең** туганнары филармония музеена җибәргән язмалардан күренгәнчә, ул Кенигсбергны штурмлауда катнаша. Пулеметчылар командиры, өлкән лейтенант Шәриф Гәрәев күрсәткән батырлыклары өчен орденнар белән бүләкләнә, фронтта өч тапкыр яралана, аннан, савыгып, тагын яуга китә. Кенигсбергка кадәр барып җитә. Үз коралын яхшы белгән Шәриф Гәрәев 1945 елның 9 апрелендә фашистларның бронемотоциклын, 3 офицерын, 9 солдатын юк итә, контратака вакытында 4 фашист офицерын һәм 9 немец солдатын әсирлеккә ала, тик төнлә, авыр яраланып, иптәшләре кулында вафат була.

Җырчы, Татарстанның атказанган артисты **Рәшит Гобәйдуллин** армиягә 1944 елда алына. Аңа Монголиядәге авиация частенда хезмәт итәргә туры килә. *«Сугышка киткәндә, әнием миңа догалар язылган китапчык биреп җибәргән иде, ул, гүя, ниндидер бер серле көчкә ия сыман тоела иде миңа»*, – дип искә алган иде җырчы бер әңгәмәсендә. Р.Гобәйдуллин 1951 елда туган ягына кайта, филармониянең әдәби-музыкаль лекторий солисты булып эшли.

Иҗади эшчәнлеген Татар дәүләт филармониясендә башлап, 34 ел буе сәхнәдән төшмәгән талантлы музыкант, баянчы **Фәйзи Садыйков** та сугышның алгы сызыгында дошман белән йөзгә-йөз очраша. Шул елларны: *«Мин, хәрби училище тәмамлау сәбәпле, авиация частенда хезмәт иттем. Сугыш тынган арада гармунымны уйнап җибәргәч, безнең белән бергә булган хәрбиләрнең күзләрендә яшь бөртекләре күренә иде»*, – дип искә ала иде ул. Ф.Садыйков Япония белән сугышта да катнаша, Казанга 1946 елда гына кайта.

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе булып озак еллар эшләгән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Җәүдәт Айдаров** Бөек Ватан сугышында Ленинград блокадасын өзүдә катнаша. Музыкант буларак аңа, симфоник оркестр составында, 1942 елның 9 августында Д.Шостаковичның атаклы 7 нче симфониясен беренче тапкыр башкарырга туры килә. Сугыштан кайткач, Җ.К.Айдаров музыкант, хормейстер-дирижер, педагог буларак, үзенең эшчәнлеген музыка сәнгатенә багышлый.

Нәфис сүз остасы, сәхнә һәм сугыш ветераны, Татарстанның атказанган артисты **Фәйзи Йосыпов** фронтта сугышчы да, артист та булып көрәшә. Ул Львов пехота училищесында белем ала, сугыш башлангач, Ленинград фронтына эләгә.Училищеда Ф.Йосыпов үзенең иҗатташ дусты, мәшһүр музыкант **Гали Җәмлиханов** белән бергә укый. Г.Җәмлиханов Украина фронтында артиллерист булып хезмәт итә. 1942 елны Ф.Йосыпов 175 нче гвардия минометчылар полкына билгеләнә. Аларның дивизияләренә Ленинград блокадасын өзүдә катнашырга туры килә. Сугыш тынган арада, атаклы урыс артистлары А.Райкин, К.Шульженко, П.Муравскийлар белән очрашып, алар белән бер бригадада сугышчылар өчен концертлар бирә Фәйзи агай.

Сулда – Габдулла Рәхимкулов. 1943 ел

Татар дәүләт филармониясендә озак еллар сәнгать җитәкчесе булып эшләгән **Рәйсә Волкова** фронтта Баренц диңгезе буена урнашкан Роста бистәсендә кызлар взводының командиры булып хезмәт итә. Шулай ук хәрбиләрне ташучы йөк машинасында шофер да була. Сугыштан соң ул үз эшен филармониядә дәвам итә.

Камил Басыйров 1942 елда 17 яшендә үзе теләп сугышка китүчеләр исемлегенә языла, Курск юнәлешендәге фронтның алгы сызыгына җибәрелә. Яраланып госпитальдә ятарга да туры килә. Аңа 1943 елның салкын кышында яңа дәваланып чыккан яшь солдатларны, шул исәптән К.Басыйровны да Волхов фронтына җибәрәләр. Кабат яраланганнан соң, ул туган ягына кайта, филармониянең әдәби-музыкаль лекториендә эшли.

Җырчы, Татарстанның халык артисты **Габдулла Рәхимкулов** 1943 елда армиягә алына, ил чигендә хезмәт итә. 1944 елда ул Молдавиянең Измаил шәһәреннән Батуми шәһәренә күчерелә һәм биредәге Хәрби җыр һәм бию ансамблендә җырлый башлый. Г.Рәхимкулов, армиядә 7 елдан артык хезмәт иткәннән соң, Магнитогорск шәһәренә кайта. Училище тәмамлап, тау токымнарын шартлатучы һөнәрен алып чыга, шахтада эшли. Ләкин аңа җырчы булу теләге тынгы бирми һәм ул татар драма түгәрәгенә языла. 1954 елда Казанга килеп, Татар җыр һәм бию ансамбленә эшкә урнаша.Чын-чынлап халык артисты булып үсә.

Сугыштан соң Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә һәм соңрак эстрада бүлегендә эшләгән җырчы**,** Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Габделхак Шаһиев** армиягә 1943 елны алына. Ерак Көнчыгышта өченче пулемет ротасында хезмәт иткәндә, ул хезмәттәшләре арасында җырчы буларак таныла. Аны солист итеп куялар. Сугыш беткәч, Г.Шаһиев ул Ерак Көнчыгышта оешкан 17 нче армиянең җыр һәм бию ансамбле солисты булып хезмәт итә. Казанга 1951 елда гына кайта.

Музыкант, кечкенә концерт гармуннарында уйнаган талант иясе, ТАССРның атказанган артисты **Фәйзи Биккинин** филармониядә сугыш башланган елны эшли башлый. Илдә сугыш барганда, дошманга каршы нәфрәт белән янган музыкантка иҗаттан берникадәр аерылып торырга туры килә. Ул, үзе теләп, фронтка китүчеләр исемлегенә языла, сапер батальонында хезмәт итә. Ә инде

Фронт бригадасы. Өченче рәттә (уңнан икенче): Җәваһирә Сәлахова, уртада – Ләйлә Латыйпова (трубада уйнаучы). 1941 ел

1944 елда фронт бригадасы оешкач, җырчы Зита (Зәйнәп) Измайлова, Хәдичә Нуриевалар белән бергә, Эстония, Латвия, аннары Литва һәм Польша җирләрендә, Германия шәһәрләрендә совет сугышчыларына концертлар бирә. Җиңү көнен алар Берлинда каршылый.

Татарстан радиосында беренче патриотик җырларны башкарган күренекле җырчы, ТАССРның халык артисты Усман Әлмиев була. Заманында ул үзе бу хакта болай дип искә ала: *«Композитор Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Мансур Мозаффаров җырлар язды. Әлеге җырлар Муса Җәлил, Кави Нәҗми, Салих Баттал, Гамир Насыйри шигырьләренә иҗат ителгән иде. Ул чакта радиодан җырлау турыдан-туры булды. Мине шул җырларны башкарырга махсус чакыралар иде».*

Авыр, дәһшәтле сугыш елларында Татар дәүләт филармониясенең директоры итеп Җыр һәм бию ансамбленең сәнгатъ җитәкчесе **Зөләйха Саттар кызы Әхмәтова** билгеләнә, ул Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, эстрада артистларының репертуарын төзи. Концерт программаларына исә сугышчыларга җан азыгы, рухи ләззәт бирүче, патриотик рухта язылган җырлар, поэзия әсәрләре кертелә.

Филармония әлеге афәтле елларда республика тирәсендәге госпиталь һәм хәрби бүлекләрдә 1700гә якын шефлык концертлары оештыра. Артистлар 17 фронт бригадасы составында сугышның бик күп фронтларында концерт программалары белән чыгыш ясый. Филармония артистлары – җырчылар Зита Измайлова, Җәваһирә Сәлахова, Рәйсә Тимофеева, Разия Тимерханова; музыкантлар Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккинин, Гани Вәлиев; биючеләр Зәйтүнә Ваһапова (Фәткулова), Хәдичә Нуриева, Салих Әхмәров фронтның алгы сызыгында үзләренең концерт номерлары белән Ватанны саклаучыларга күңел күтәренкелеге, көч-дәрт өстиләр. Җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы **Җәваһирә Сәлахова** да халкыбыз дәһшәтле сугыш газаплары, мохтаҗлык кичергән елларда унҗиде яшендә

сәхнәгә аяк баса. Ул, бер төркем сәнгать әһелләре белән, концерт бригадасында сугышчылар алдында чыгыш ясый. Сталинград, Брянск, Курск, Орел фронтлары... Барлыгы – 148 концерт, шуларның 115е алгы сызыкта була.

Җ.Сәлахова шул елларда фронтта чыгыш ясавы турындагы истәлегендә болай дип яза: *«1943 елның апрель ае ахырлары иде бу. Без гастрольләрдән кайтып төшүгә, сез фронтка артистлар бригадасы белән китәсез», – диделәр. Фронтка китәр алдыннан Мәскәүдә безне тыңлаганнан соң, Брянск фронтына, Курски-Орел ягына җибәрделәр. Шулай итеп, без 1 майны фронтта – сугышчылар алдында каршыладык.Ул яклар каен урманнарына бай иде. Урман солдат-сугышчыларның өе булган кебек, урмандагы блиндажлар – безнең өйгә һәм урман – клубка, ә йөк машиналары сәхнәгә әверелде. Сугышчыларның артистларны нинди күтәренке рух белән каршы алуларын сүз белән генә аңлатуы бик кыен. Безнең Татарстаннан килгән һәрбер милләт кешесе өчен аларның иң якын туганнары кебек булдык. Бригадада 10 кеше идек. Безне фронттагылар «үзебезнең артистларыбыз» дип йөртәләр иде. Бригадалар, гадәттә, фронтка 45 көнгә җибәрелә иде, ә без 69 көн – ике срок диярлек булдык. Шул вакыт эчендә 148 концерт биреп, шуның 115е алгы сызыкта булды».*

Разия Тимерханова, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җырчысы, ТАССРның атказанган артисткасы: *«...1941-1942 елларга әйләнеп карыйк. Авыллардан кайткач, безне Калинин фронты ягына җибәрделәр. Ансамбльгә опера һәм балет театры солистлары Асия Измайлова, Андрей Пустоветов, Рус Зур драма театрыннан Евгения Лисецкая кушылды. Зәһәр салкын. Өс киемнәребез дә юка гына. Аякларда резин итекләр. Безне озата килгән Зөләйха апа Әхмәтова: «Мин балаларымны бу салкында мондый аяк киемнәре белән җибәрмим. Алар юлда ук катып үләчәк», – ди артистларны фронтка җибәрү комиссиясе рәисе Б.Л.Военштейнга. Бу кеше бераздан безгә Кукмара итекләре алып килде. Вагонга өс киемнәребезне салмыйча гына кереп яттык. Иртән уянгач, урынымнан тора алмыйм. Аркамны стенага терәп ятканмын да, пальто тән җылысы белән вагон стенасына ябышып каткан икән. Иптәшләр мине тарткалый торгач, пальто шатыр-шотыр куба башлады. Авырырмын дип борчылсам да, берни булмады, яшьлек, күңел күтәренкелеге җиңде. Концертлар уңышлы үтсәләр дә, күңел әрни. Чөнки сугышчылар үлем арасында йөриләр, яуга керәләр. Шуларны күрү авыр иде. Маршрутыбыз Калинин фронты булып, без Калинин, Ярославль, Иваново шәһәрләренә кайткалый идек. 1942 елны Кострома шәһәрендә каршы алдык. Концертлар төрле частьларда – әле танкистлар, әле летчиклар өчен була иде. Февральдә барыбыз да Казанга исән-сау кайтып кердек. Шунда ук Кукмарага барып, 20ләп концерт куйдык. Александр Бендецкий концертларыбызны бик оста алып барды.Тәрбияле, төскә-биткә чибәр, поэзияне яратучы Александр Бендецкий коллективта зур хөрмәт казанган якты шәхес иде. Кукмара госпитальләреннән соң ул бездән аерылды. Шуннан соң аны фронтка концертлар белән җибәрәләр. 1943 елда без аның сугыш кырында һәлак булуын ишеттек».*

Опера һәм балет театрында һәм филармониядә биюче булып эшләгән **Хәдичә Нуриева**: *«1941 елның җәй башы иде. Бөтен сәнгать дөньясы, шул исәптән, Опера һәм балет театры да Мәскәүдә булачак декадага әзерләнде. Кинәт бөтен планнар чәлпәрәмә килде, сугыш башланды. Без, театрдан өч кыз, өч егет, фронтка язылырга военкоматка килдек. Бишебезне алгы сызыкка җибәрделәр, мине, өч айлык шәфкать туташы курсларында өч ай укуым сәбәпле, санитар поездына яралыларны тылга алып кайтырга куйдылар. Яралыларны Казанга ташый идек.*

Юлда бик күп тапкыр бомба һөҗүменә эләктек. Авыр яралыларны ташырга көч тә, сабырлык та кирәк иде. 1942 елда кулым яраланды, бозыла башлагач, миңа операция ясадылар һәм тылга озаттылар. Татар дәүләт филармониясенә кайтып, Усман Әлмиев бригадасында эшләдем. Аннан Рәшит Ваһаповка билгеләделәр. Без районнар буйлап йөрдек. Мин биюче идем. Клублар салкын, ягылмый иде, көнгә икешәр концерт бирәбез, тамагыбыз ач. Тик халык мәхәббәте яшәргә көч бирә иде. 1944 елның декабрендә җырчы Зита Измайлова, вак гармуннарда уйнау остасы Фәйзи Биккинин белән янә фронтка киттек, бу юлы концерт бригадасы белән. Беренче концерт Брест крепостенда булды. Фронт линиясе бик якын, тирәякта снарядлар шартлый иде. Аннан беренче һәм икенче Украина фронтында булдым. Көнгә өч-дүрт тапкыр куела торган концертлар күбрәк землянкаларда булды, чөнки өстә аталар, бомбага тоталар иде.

Хәдичә Нуриева

Польшада азат ителгән территориядә чолганышта калдык. Бер тәүлек буе каршы тордылар. Без Фәйзи агай белән бер җирдәрәк булдык. Фәйзи агай миңа: «Син, Хәдичә, аякларыңны җиргә күм, пулядан саклан», – ди. Мин кулларымны күптән яшердем. Шулай бер тәүлек утырдык. Аннары безгә сугышчылар өстәлде, дошманны тар-мар иттеләр. Алар украин бендеровчылары булып чыкты. Берлинга якынлаштык. Без, артистлар, концертларыбызны дәвам иттек, яралыларны карадык. Шулвакытта: «Җиңү! Ура, Бөек Җиңү!» – дип кычкырган тавышлар ишетелде. Без урамда шатлыктан бер-берсен кочаклап өйләренә кайтучы солдатлар алдында чыгыш ясадык. Шулай итеп, Литва, Көнбатыш Украина, Польша, Көнчыгыш Пруссия җирләрен «биеп үттем» һәм Җиңү көнен Берлинда каршыладым. Без, татар артистлары, алдыбызга куйган бурычыбызга тугры калдык. Ватанның иминлеге өчен көрәшүчеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас! Туплар шартласа да, җырлар тынмады!»

Татар дәүләт филармониясендә биюче булган **Зәйтүнә Ваһапова** да сугыш башлангач, бер төркем артистлар белән Мәскәүдән Мурманск ягына җибәрелә. *«Без төньяк фронтта, алгы сызыкта хәрбиләр өчен концертлар бирдек. Шул вакытларны искә төшереп йөргәндә, күңелдә мондый шигъри юллар туды,* – дип искә алган иде Зәйтүнә ханым бер очрашуда:

Сугышчыга әйткән кайнар рәхмәт
Бик җылытты җанны, уйларны.
Сынатмадык: ядрәләр сипсә дә,
Горур үттек сугыш юлларын...»

Алсу Хәкимова,
Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире. ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Фасилнең моң чишмәсе

Әгъзам Фәйзрахманов

Әгәр исән булса, быел күренекле композиторыбыз Фасил Әхмәтовның 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтәр идек. Юк шул, аяусыз үлем аны арабыздан иртәрәк алып китте. Аңа яшәргә дә яшәргә иде бит әле, югыйсә.

Без Фасил белән тормышта шактый аралашып яшәдек, күрәсең, моңа аның энесе Рафис белән Татарстан телевидениесе студиясендә бергә эшләвебез этәргеч биргәндер. Рафис ул чорда студиянең музыкаль тапшырулар редакциясендә мөхәррир иде. Фасил энесе янына еш килеп йөрде. Алар Рафиснең тапшыру сценарийларын озаклап тикшереп утыралар иде. Музыканы яхшы белсә дә, мөгаен, Рафискә абыйсының ярдәме дә зыян итмәгәндер. Фасил исә телевидение студиясендә үткәрелә торган чараларда да, тапшыруларда да актив катнашты.

Фасил – авыл малае. Оста гармунчы, зирәк хисапчы-бухгалтер Әхмәтгали белән Бибисараның өченче улы булып, 1935 елның алмагачлар чәчәккә төренгән җылы маенда дөньяга килә ул. Элеккеге Тәкәнеш районының кечкенә генә Салтык Ерыклы авылын халык телендә Өшенбашы дип тә йөртәләр. Әтисе аңа өч музыкаль нотадан торган сирәк исемне каян тапкандыр, тик шунысы хак: исеме җисеменә туры килеп тора бит: -фа-си-ля.

Тормышта көтелмәгән хәлләр һәрвакыт туып тора. Унбер айлык чая улы Фасил тәпи йөри башлаганда, авылның иң актив коммунисты, колхозга сөекле шагыйребез Габдулла Тукай исемен бирергә тәкъдим иткән хисапчы Әхмәтгали Хаҗиәхмәтовны, яла ягып, таш капчыкка – зинданга ябып куялар, «Халык дошманы» исеме тагылган тоткынга җидееллык төрмә яный. Әмма Әхмәтгали тик ята торган гади мужик булмый шул, хаклык эзләп, Сталинга кадәр хатлар юллый. Нәтиҗәдә, дүрт айдан акланып, өенә кайтып ава. Ире төрмәдә утырганда, Бибисара көне-төне колхоз эшендә була. Берсеннән-берсе кечерәк балалары өйдә үзләре генә кала. Беркөнне эштән кайтканда Бибисара урам яктан ишекне ача алмыйча егылган, юеш ыштаны ботларына бозланып ябышып каткан улы Фасилне күрә. Шуннан соң ул балалар параличы белән авырый башлый һәм, гомерлек чир алып, инвалид булып кала. Тәпиләре тора-бара зәгыйфьләнеп, нечкәреп бетә, култык таягы аның аерылмас юлдашына әверелә. Әти-әнисе малайларын кайя гына алып барып, нинди генә табибка күрсәтсәләр дә, файда булмый, аяклары көннән-көн кибә. Әле ярый әтисе улына юаныч-шөгыль табып бирә: кулына өр-яңа гармун тоттыра.

Бистәдә өр-яңа клуб сафка баскач, бирегә гастролерлар еш килә башлый. Бибисара аларга аш-су әзерли, мичкә ягып, өйне җылыта. Ә артистлар, ихтирам күрсәтеп, кичләрен Әхмәтгали гаиләсенә беренче рәттән урын бирәләр. Концерт, спектакль башланып китүгә, Фасил, онытылып, музыка, сәнгать дөньясына чума. Казан артистлары бизәнеп-ясангандагы бушлыкны да Фасил белән энесе Рафис тутыра. Сәхнәдән алар башкаруында төрле көйләр агыла. Рәшит Ваһапов, Усман Әлмиев, Фәйзи Биккинин, Мохтар Әхмәдиев, Фәйзулла Туишев, Зифа Басыйрова, Гөлсем

Гөлзада Сафиуллина, Фасил Әхмәтов һәм Риф Гатауллин. Г.Сафиуллина архивыннан

Сөләйманова һәм Оркыя Ибраһимовалар белән яшь Фасил нәкъ шушы бәхетле илленче еллар башында таныша.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Әхмәтгали ага улын Казанга алып килә. Әти кеше гарип улына төпле һөнәр бирү турында хыяллана. Башта аны Хисап-кредит техникумына алып бара, тик, кич кайткач, Фасил әтисеннән музыка училищесын күрсәтүен үтенә. Бу вакытта инде ул гармунда да, баянда да теләсә кайсы көйне уйный белә. Нота серләренә дә төшенеп өлгерә ул. Юкка гына гастролер артистлар белән сәгатьләр буе уйнап-көлеп утырмаган шул.

Шулай да Фасил баян буенча беренче имтиханын ничек тапшыруы турында күз яшьләренә тыгылып сөйли торган иде. Авыр баянын күтәреп, таягына таянып, паркет идәннәре балкып торган бүлмәгә керә ул. Шунда, таягы таеп китеп, йөзе белән идәнгә каплана. Түрдә утырган училище директоры Ильяс Әүхәдиев аңа торырга ярдәм итә. Яшь музыкант, каушавын баса төшкәч, үзе яраткан көйләрне баянда сузарга керешә. Өстәл янында утыручы имтихан алучыларның барысы да аның уйнавыннан канәгать кала.

Нәтиҗәдә, авыл малае Фасил Әхмәтовны училищеның баян классына кабул итәләр. Бу бәхетле мизгел 1952 елның көзендә була. Шуннан башлап Жуковский урамындагы йортта яшәүче бер әби фатирына урнашкан бәхетле егет ноталы китапларын һәм баянын көне-төне диярлек кулыннан төшерми. Әмма озакламый Фасил авыр баянын күтәреп авылдан-авылга гастрольләргә йөри алмаячагына нык төшенә.

Күп тә үтми, сәләтле баянчы училищеның берьюлы ике бүлегендә укый башлый. Теория һәм композиторлык бүлеге аңа торган саен күбрәк ошый төшә. Яшь егетнең аралашу даирәсе дә көннән-көн киңәя бара. Нәкъ шушы чорда Фәтхерахман Әхмәдиев, Ифрат Хисамов, Ләбиб Айтуганов кебек яшь композиторлар аның якын дуслары булып китә. Иҗатына мөкиббән киткән атаклы «Шүрәле» балетының авторы Фәрит Яруллинның энесе – нәкъ үзе кебек үк баянчы һәм булачак композитор Мирсәет аның иң якын дусты-сердәшенә әверелә.

Училищены тәмамлап диплом алгач, Фасил документларын консерваториягә тапшыра. Яшь иҗатчы гомерендә өр-яңа фасыл башланып китә. Чын остаз-педагог, үзе дә сизгер рәссам-иҗатчы Альберт Леман, аңа гына хас сабырлык белән, авыл малаен классик музыка, композиция серләренә төшендерә. Тиздән Ф.Әхмәтовның фортепиано өчен сонатинасы дөньяга килә. Ул Композиторлар берлегенең чираттагы пленумында зур уңыш казана. Тора-бара бу әсәр, Эльза Әхмәтова репертуарына кереп, Мәскәүдә һәм башка күп җирләрдә яңгырады. Мәшһүр музыка белгечләре әлеге әсәрнең аһәңен хәтта «Болеро» авторы, атаклы француз Морис Равельнекенә тиңлиләр.

Анализлый башлагач, шуны тоясың: Фасил Әхмәтовның күпчелек җырлары мәхәббәт турында. Аларның шактый өлеше хатыны – Баулы чибәре, табибә Йолдызга багышлана. *«Тормыш булгач, төрле хәлләр була торгандыр инде, гел болытсыз, ләйсән яңгырсыз гына булмыйдыр ул*, – дип язды энесе Рафис бер мәкаләсендә. *– Фасил абыйның композитор, шагыйрь, җырчы, рәссам дуслары берничә дистәгә тула торгандыр: һәркайсы үз итә, һәркайсы кунак итә. Җитмәсә, нәкъ 1981 елда Казанда дөнья куйган әтиебез кебек, абый да гади кешеләрне – беркатлы авылдаш, әшнә, күрше-күлән мужикларын үз итә иде. «Җиһанов янында бер сәгать утырганчы, Сәйдәш ахирәтләре белән бер сәгать күңел ачам», – ди торган иде ул. Чыннан да, кая гына бармасын, татармы, урысмы, мари яки чуашмы – ул һәркем белән уртак тел табып сөйләшә, ихлас аралаша белә иде».*

Консерваторияне Фасил Әхмәтов, дуслары Ренат Еникиев, Мирсәет Яруллин, Илдус Якупов, Рафаэль Белялов кебек, танылып килгән композитор буларак тәмамлый. Остазлары А.Леман, Н.Җиһанов аны симфоник музыка серләренә төшендерә. Югары уку йортын ул үзенең беренче симфониясен иҗат итеп тәмамлый.

Фәрит Яруллинның якты истәлегенә багышланган симфоник поэма, тәүге тапкыр башкарылганнан соң ук, Татарстан Дәүләт симфоник оркестры репертуарында ныклы урынын алды, хәтта Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә дә тәкъдим ителде. Кызганыч, остазы Нәҗип Җиһанов та, ул чактагы партия өлкә комитеты җитәкчеләре дә үзсүзле, партиясез иҗат әһеленә ярдәм кулы сузарга теләми. Ә Мәскәүнең иҗат әһелләре бу әсәргә ихластан сокланалар. Россия композиторларының Түбән Новгородта үткән күчмә утырышында поэма бик югары бәяләнә. Россия композиторларының Щедрин җитәкчелегендәге идарәсе, Фасил Әхмәтовның үлемсез классик әсәр тудыру бәхетенә ирешүен хуплап, аңа Россиянең Михаил Глинка исемендәге Дәүләт бүләген бирергә карар итә. **Р.Щедрин**: *«Мондый әсәр бөтен дөньяда яңгырарга хаклы, Фасил музыкасы тетрәндерә дә, елата да, сагайта да. Атаклы «Шүрәле» балеты авторының фаҗигасе бүтән кабатланмасын иде!»* – дип белдерә.

Мәскәүдә бөтен илгә танылып кайтканнан соң, соңгарак калып булса да, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты исемнәре бирелә Фасилгә. Ниһаять, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе дә тапшырыла. Әмма шунысы гаҗәп: талантлы композиторга бары Мәскәү зурлаганнан соң гына хөрмәт күрсәтелә.

Бу чорда Фасил Әхмәтов үзенең чын җәүһәр дәрәҗәсендәге тагын бер әсәрен – «Казан симфониясе»н дә төгәлли. Композитор музыка телендә 1552 нче ел фаҗигасен, Явыз Иван явын, татарның тиңдәшсез батырлыгын тасвирлый. «Чабата» көен көйләп, Сабан туе үткәреп, мөнәҗәт көйләп яткан илгә, барабаннар кагып, быргылар кычкыртып, кансыз вәхшиләр ябырыла. Мөнәҗәт көе белән М.Мусоргскийның «Хованщина»сындагы тема үзара көрәшә-бәрелешә. Соңгысы җиңә дә сыман, дошман тантана итә, шулай да, баштагы мөнәҗәт темасы да үлми – борынгы озын көйгә

Сулдан уңга: беренче рәттә – шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин, Миңгол Галиев; икенче рәттә – сулдан өченче – Гөлзада Сафиуллина, дүртенче – Фасил Әхмәтов. Балтач. 1985 ел

әверелеп, «Тәфтиләү», «Әллүки»ләргә охшап, халыкка мәңгелек өмет чаткылары таратырга керешә.

Бу әсәр ул чактагы СССРның Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителә. Әмма премия авторга тапшырылмый. Бирмәүнең сәбәбе дә табыла: документлар Мәскәүгә вакытында барып җитмәгән, имеш.

Балалар дөньясын да үз күрде ул. Улы Азатны үстергән, оныгы Вәгыйзне сөеп калырга өлгергән олы җанлы ата иде Фасил. Икенче оныгы Шамил дөньяга килергә дә бер генә ай калган иде. Җиң сызганып, «Сөембикә» балетына керешергә хыялланып йөрде Ф.Әхмәтов. Әмма планын тормышка ашырырга насыйп булмады шул. Сөекле хатыны – үзе «таң йолдызы» дип йөртә торган Йолдыз белән дачасында ял иткәндә, аның җете зәңгәр күзләре мәңгегә йомыла. Шунысы да серле: нәкъ менә әтисе Әхмәтгалинең туган көне – 8 сентябрь иртәсендә була бу. 1998 елда.

Абыйсының үлемен Рафис бик авыр кичерде. Кайчан гына очрашып, нәрсә генә турында сөйләшергә тотынсак та, ул Фасилне искә төшерми калмады. Күзләре дә яшьләнә иде. Кызганыч, абыйсыныкы кебек үк, Рафис Әхмәтнең дә гомере кыска булды. Зур планнар корып, иҗат итеп йөргәндә, явыз үлем аны да безнең арадан алып китте.

Ирексездән Фасилнең үлемсез җырындагы тетрәндергеч шигъри юллар хәтердә яңара:

Китәсез дә мени,
Китәсез дә мени,
Китәсез дә мени, аккошлар...

Дусты, иҗатташы Равил Фәйзуллинның бу шигыре, нәкъ менә энесе Рафис әйткәнчә, даһи музыка өрфиясенә төренеп, заманабызның иң популяр, матур җырларының берсенә әверелде:

Хушлашырга безгә
Иртәрәк бит әле,
Иртәрәк бит әле, аккошлар!

Ләкин нишлисең бит, хушлашырга да туры килә шул... ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

1970-1988 еллар

■ 1970 нче еллар ахырында филармония үткәргән конкурслар, фестивальләр һәм башка мәдәни чараларның саны арта.

■ 1973-1988 елларда Татар дәүләт филармониясенең директоры Марат Таҗетдинов була. Бу елларда әдәби-музыкаль лекторий бүлегенең эшчәнлеге активлаша, Татарстан симфоник оркестрының эшчәнлеге тотрыклылана, җыр һәм бию ансамбле матди яктан ныгый.

■ 1976 елда филармониянең сәнгать җитәкчесе итеп Илгиз Мәҗитов билгеләнә. Илгиз Габидулла улы республика дәрәҗәсендә узучы зур тамашаларның, чит төбәкләрдә оештырылган татар әдәбияты һәм мәдәнияты декадаларының, авторлык концертлары һәм әдәби-музыкаль кичәләрнең режиссеры буларак та таныла.

■ 1977 елда, Марат Таҗетдинов чакыруы буенча, Казанда Владимир Высоцкий, 1986 елда Булат Окуджава чыгыш ясый. Алла Пугачева, Валерий Леонтьев, Ио-

Уңнан сулга (беренче рәттә): Нәҗия Теркулова, Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева, Айрат Арсланов; (икенче рәттә): Гали Ильясов, Хәнәви Шәйдуллин, Зиннур Нурмөхәммәтов, Рафаэль Ильясов, Гөлшат Зәйнәшева, Гөлзада Сафиуллина, Зилә Сөнгатуллина, Лена Шагыйрьҗан, Рәйсә Билалова; (өченче рәттә): Рафаэль Сәхәбиев, Мирсәет Сөнгатуллин, Эмиль Җәләлетдинов, Миңгол Галиев. 1980 нче еллар

Татарстан сәнгать эшлеклеләре бу фотога Мәскәүнең Казан вокзалында башкаланың Эстрада театрында тантаналы концертта катнашырга килгән көнне – 1980 елның 12 гыйнварында төшкәннәр

сиф Кобзон, Лев Лещенко, Святослав Рихтер, Лолита Торресның Казанга беренче гастрольләре шулай ук ул директор булган елларда оештырыла.

■ 1977 елда, балалар өчен симфоник концертлар булдыру ниятеннән, Татар дәүләт симфоник оркестры «Әкиятләр дөньясында» дип аталган абонемент циклын башлый.

■ 1978 елда Җыр һәм бию ансамбле «Сабантуй» программасын чыгара. Программаның сценарий авторы һәм режиссеры Илгиз Мәҗитов була.

■ 1982 елдан Композиторлар берлеге Татар дәүләт филармониясе белән бергә Идел һәм Урал буе автономияле республикалары композиторларының музыка фестивальләрен үткәрә башлый. Төрле төбәкләрдә узучы бу фестивальләр Россиянең күп композиторлары өчен генә түгел, Татар дәүләт филармониясе иҗат коллективлары өчен дә җитди имтихан була.

■ Композиторлар берлегенең ел саен үтүче концертлары, пленум һәм съездлары филармония ярдәме белән уздырыла. Әлеге иҗади бердәмлек нәтиҗәсендә филармония татар композиторларының академик юнәлештәге музыкасын пропагандалый: Нәҗип Җиһанов, Фасил Әхмәтов, Анатолий Луппов симфонияләре, Рафаэль Билалов һәм Ринат Еникеев концертлары, Мирсәет Яруллин, Бату Мөлеков һәм Борис Трубин ораторияләре, Рөстәм Яхин һәм Резидә Ахиярова романслары Татар дәүләт филармониясенең актив роле нәтиҗәсендә башкарыла.

■ 1985 елда скрипкачыларның VII Бөтенроссия конкурсы үтә. Анда талантлы музыкантлар Рөстәм Абязов, Юлия Виват, Айгөл Рәхимова һәм Лия Ходжаевалар чыгыш ясап, югары профессиональ мөмкинлекләрен күрсәтәләр.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2020

Тукай ул – безнең татар халкының дәүләте

Туфан Миңнуллин

Тукай теле турында сүз чыкканда, минем Тукайның «Китмибез» дигән шигырен искә төшерәсе килә. Мин аны, бераз гына үзгәртеп, болай дим: «Кара йөзләр безне булмас эшкә тәкълиф иттеләр: «Сезгә үз телегез харам, үз телегезне оныт», – диләр. Онытмыйбыз без, беркайчан да үз телебезне онытмаячакбыз. Без әле безнең телгә кабер казучыларның каберләре янында татар телендә сөйләшәчәкбез. Киләсе буын яшьләре шушыны белеп үсәргә тиеш. Безнең телебез – татар теле, ул дөньядагы бер генә халыкның да теленнән ким түгел! Ялганнарга ышана күрмәгез, дөньяда бөек телләр юк! Әгәр дә теге яки бу телдә әти-әни сүзен әйтә аласың икән, әгәр дә ул телдә яратам дип әйтә аласың икән, ул тел бөек! Шуңарга күрә мин Сезгә тәүфыйк телим, бездән дә акыллырак булыгыз, бездән дә вөҗданлырак булыгыз һәм Тукайны бергәләп саклыйк. Тукай ул – һәрвакыт безнең иманыбызны яңартып, юнәлешебезне билгели торган шәхес. Дәүләтләре булмаган илдә дәүләт ролен шәхесләр үти. Менә безнең Тукай ул – безнең татар халкының дәүләте. Без ул дәүләтне сакларга бурычлыбыз. Сезгә киләчәктә дә шушылай җыелып, Тукайның һәрбер туган көнен бәйрәм итеп үткәрергә язсын. Киләчәккә Тукай белән, туган тел белән бергә атлыйк!..

(Туфан Миңнуллинның Тукай-Кырлайда ясаган чыгышы, 27 апрель, 2012 ел)

Тел дәресе

Кайсы сүзне кеше ни өчен уйлап тапкан? Үземә-үзем кызык табып шул хакта уйланып алам мин. Ни өчен, әйтик, безне дөньяга китергән хатын-кызны татар балалары «әни» ди? Әллә соң әни дигән сүз булмаганда бер сабый авызын җәеп «ә-ә-ә» дип елап ятканда, аны тапкан хатын «ни?» дип сорагач,елак бала, «ә»гә «ни» кушып, «әни» дип әйтте микән? Алайса нигә урыс балалары «мама» ди? Гаҗәеп серле нәрсә бу тел дигәнең.

Эше юк эш тапкан, дигәндәй, беркөн бер кызыксыз җыелышта президиум өстәле артында утыручыларга карап тордым да нишләп урыслар түрәләрнең кайсыларына «председатель», кайберләренә «начальник» дигән исем куштылар икән дип уйлап куйдым. «Председатель» дигән сүз ни аңлата? Ул ике сүздән тора бугай? «Пред» һәм «седатель». Татарча итеп әйтсәк, алда утыручы. Димәк, председатель дип аталучы түрә алда утыра, калганннары аның артына урнашкан. Алга, белгәнемчә, дәрәҗәлерәк, куштанраклар утыра ич инде! «Начальник» сүзенең тамырында «начало», ягъни «башлану» дигән сүз ята. Димәк, түрәнең мондые башлап йөри. Калганнар моңа ияреп йөри булып чыга. Урыслар председатель, начальник, директор-фәләннәрне барысын бергә руководитель, ди. Рука+водитель, ягъни кулы белән йөртүче. Кул белән йөртүче нишли? Юл таба алмаганнарга яки кире якка китеп баручыларга, кулын сузып, юл күрсәтә, йә, кулы белән ишарә ясап, туктарга куша. Ишарәне аңламаган томаналарны җитәкләп бара. Җитәкләтергә теләмәгәннәргә кулы белән тамызып та куя. Менә нинди кешеләр икән ул руководительләр. Татар «руководитель» дип аталган түрәләрне җитәкче дип тәрҗемә иткән. Татар үзе бөтен җитәкчеләрне дә түрә дип атый. Бу аның үз сүзе. Түрә дигән сүз түрдә – президиумда утыручыларны аңлата инде.

Җыелыш бетми дә бетми. Тагын ни турында уйлап вакытны уздырырга икән? Әнә, түрдә утыручыларның берсе «приют» дигән сүз әйтте. Кайдан килеп чыкты икән бу сүз? Татарчасы ничек икән? «Приют» – «приютиться»дән алынгандыр, мөгаен. Ягъни кемгә дә булса сыену. «Приют» – ятим, караучысы булмаган ялгызакларның сыену урыны буладыр. Татарда ул сүзнең кыска тәрҗемәсе дә, ул мәгънәне аңлата торган бүтән сүз дә юк. Димәк, татарда «приют»лар булмаган, ятимнәр, ярдәмгә мохтаҗларны бер җиргә җыймаганнар. Аларны туганнары яки бүтәннәр үзләре янына сыендырган. Хәзер инде приют сүзе безгә дә килеп керде. Без дә, димәк, ятимнәрне үз яныбызга сыендырмый башладык, чөнки ятимнәр күбәя, миһербанлы затлар азая. Әй-е-е, диген, кодагый! Түрәләр арта, ятимнәр арта, изге күңелле кешеләр кими. Менә уйлый-уйлый кая килеп чыгылды. Мәгънәсез, файдасыз җыелышта утырсаң, шулай була инде ул.

Шулай дип язып куюым булды – җыелыш та бетте. Алда утыручылар, башлап йөрүчеләр, җитәкчеләр – үз якларына, без, җитәкләнүчеләр, ияреп йөрүчеләр, үз ягыбызга киттек.

*Текстларны **Рөстәм Акъегет** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2020

Көлке куа килә...



Гамил Афзал.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Гамил Афзал
(1921-2003)

Карт ишәк

Гомер буе башын иеп йөрде,
Гомер буе таяк, камчы күрде.
Биргән чакта салам – кибәк алды,
Бирмәгәндә – үрелеп карап калды.
Картайгачтын язды, күзлек киеп:
«Көрәш белән үтте гомер», – диеп.

Фаил Шәфигуллин
(1939-1982)

Казан татары җыры
(«Шәл бәйләдем» көенә)

Шигырь яздым, шигырь яздым,
Шигырь яздым, шигырь яздым,
Шигырем әйбәт түгел лә,
Шигырем әйбәт түгел.
Әннә-гидер, геннә-гидер генәем лә,
Пүчтәк шагыйрь икәнемне беләем.

Сөйләгәннәр сөйләсеннәр,
Сөйләгәннәр сөйләсеннәр,
Дөрес сүз гайбәт түгел лә,
Дөрес сүз гайбәт түгел.
Әннә-гидер, геннә-гидер генәем лә,
Берсеннән дә курыкмаем, җиңгәем.

Тәнкыйтьчеләр ябыккан ла,
Тәнкыйтьчеләр ябыккан ла,
Күзәтәләр ярыктан ла,
Күзәтәләр ярыктан.
Әннә-гидер, геннә-гидер генәем лә,
Мин аларның яннарына киләем.

Тукмарга да уйлары бар,
Тукмарга да уйлары бар,
Оялалар халыктан ла,
Оялалар халыктан.
Әннә-гидер, геннә-гидер генәем лә,
Мин оялмыйм – эчем катып көләем.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән
дивар газетасынан, 1980.)

Зөлфәт
(1947-2007)

Әхәт Гаффарга

Укыдым «Тегермән ташы...»н,
Ә.Гаффарның язмасын –
Мондый ташлар арасына
Кысылырга язмасын!

*(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән
диварм газетасыннан, 1980.)*

**Әхәт Гаффар.
Л.Лерон шаржы**

Ватанны сайлап алмыйлар
(Халык мәзәге)

Корт баласы әти корттан сорый:
– Әти, алмада яшәү рәхәтме?
– Рәхәт, улым, рәхәт.
– Ә бананда?
– Бик рәхәт!
– Ә ананаста?
– У-у, анда бөтенләй җәннәт инде.
– Без нишләп тирестә яшибез соң алайса?
– Ватанны сайлап алмыйлар шул, улым!

Тәлгат Нәҗмиев
(1950-2014)

Табиб сүзе

Бер елны Югары Утар балалар интернат-йортында республика семинары узды. Андый киңәшмәләрнең ахыры булмыйча калмый бит инде. Тост әйтүләр, кысташулар китте. Минем «тормоз»дагы вакыт.

Янымда утырган табиб Әмир Шакиров, карап-карап торды да, түзмәде:

– Курыкма, эч, райком бетте бит инде, – диде.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Апрель башында язучы Локман Закирның «ЖЗЛ» дигән яңа китабы басылып чыкты.

● 16 апрельдә «TRT AVAZ» Төркия дәүләт телевидение каналы татар шагыйре Дәрдемәнд турында «Тамырлар эзендә. Дәрдемәнд» дип исемләнгән документаль тапшыру күрсәтте. Галимнәр Исмәгыйль Түркоглу, Рамилә Йылдырым, Чулпан Четин, Гүлшаһ Йылмаз һәм докторант Ильяс Мифтахов катнашында узган әлеге тапшыруда Дәрдемәнднең тормышы, иҗаты, ул яшәгән чор һәм Рәмиевләр гаиләсенең татар мәгарифенә, иҗтимагый тормышына кертвән хезмәтләре хакында сүз барды.



● 18 апрельдә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, «Кызыл Татарстан» газетасы мөхәррире, «Чаян» журналын оештыручыларның берсе һәм аның беренче мөхәррире, «Кызыл Шәрык яшьләре» журналы редколлегиясе әгъзасы Мәхмүт Кәшфелһади улы Бөдәйлинең тууына 125 ел тулуга багышлап, «Мәхмүт Бөдәйли һәм «Чаян» журналы» дигән виртуаль күргәзмә тәкъдим итте.

● Доктор Альп Әрән Демиркаяның классик язучыбыз Әмирхан Еники тормышы һәм иҗаты турында язган фәнни эше аерым китап булып дөнья күрде.



● 20 апрельдә Чирмешән районының Туймәт авылы халкы быел да, Рамазан ае башланыр алдыннан, барлык саклык чараларын күреп, авыл зиратында чистарту эшләрен башкарды.

● Төркиянең абруйлы журналларыннан берсе булган «Тәмрин»журналы (Истанбул) 2020 елгы дүртенче санын тулаем рәвештә классик язучыбыз Аяз Гыйләҗевкә багышлап чыгарды. Әлеге махсус санның дөнья күрүендә тәрҗемәче һәм язучы Фатиһ Кутлуның өлеше зур булды.

● 21 апрельдә заманында «Идел»журналы һәм «Татар иле» газетасы редакцияләрендә эшләгән журналист Альберт Тәхавиев 68 яшендә вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Дәрвишләр бистәсе зиратында җирләнде.

● Күренекле язучы һәм журналист Фатих Кәриминең тууына 150 ел тулу уңаеннан, аның «Аннан-моннан» дип аталган әсәрләр җыентыгы, төрекчәгә тәрҗемә ителеп (тәрҗемәче – Җиһан Чакмак), Евразия Язучылар берлегенең «Бәнгү» нәшриятында дөнья күрде. 74 битлек китапта Ф.Кәриминең «Шәркый Рус» гәҗитендә «Каләм» кушаматы белән «Аннан-моннан» сәхифәсендә бастырган публицистик язмалары һәм «Бәхетле кыз» хикәясе тәкъдим ителгән.



● 26 апрельдә ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде:

Идрис Газиев (татар композиторлары әсәрләреннән һәм халык җырларыннан төзелгән концерт программалары өчен);

Денис Осокин («Огородные пугала с ноября по март» җыентыгы өчен);

«Сөембикә» операсын сәхнәләштергән коллектив: **Ренат Салаватов, Юрий Александров, Виктор Герасименко, Гульнора Гатина**;

Лирон Хәмидуллин («Дәрдемәнд», «Буранлы төндә», «Зарницы на горизонте» китаплары өчен).

● 27 апрельдә татар мәдәниятен Төркиядә танытуга зур өлеш керткән Төркия дәүләт телерадиокомпаниясенең элекке җитәкчесе Шенол Дәмирөз җитмеш яшендә вафат булды.

2004 елда ул күренекле татар галимнәре Йосыф Акчура, Садри Максуди-Арсал, Зәки Вәлиди-Тоган, мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралы хакында документаль фильмнар төшертте.

Төркиядә татар мәдәниятен танытуга керткән фидакарь хезмәтләре өчен, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев 2005 елда Ш.Дәмирөзне «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләгән иде. ■

МИРАСВОРД

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар шагыйре

Ут ноктасы

Революционер Симон Тер-Петросянның тәхәллүсе

... Сыртланова (очучы, Советлар Союзы Герое)

Һинд үгезе

Гражданнар сугышы чорының күренекле хәрби җитәкчесе

Ул яуда беленә

... Әхмәдиев (татар язучысы, журналист)

Зөянең сул кушылдыгы

... Габдрахманов (Советлар Союзы Герое)

Актриса Юлия ...

Морза

... Әхтәмов (Советлар Союзы Герое)

Максим Горький хикәясе

Бер анадан бер үк вакытта туган балаларның берсе

Шәйхи Маннур романы

Ркаил Зәйдулла поэмасы / ... шүлпасы

Күтәренке күңелле

Очкыч

Солдатларның тимер баш киеме / Дедал улы

Композитор, Татарстан гимнының көй авторы

Бәрмә уен коралы

Бөтендөнья татар ...ы / Аңлатма (иск.)

... Браун

Нәфрәт, ярсу тойгысы

Аксылкызыл

Кайбер илләрдә: парламентның югары палатасы

Шәехзадә ...

Төз атучы

... Гатау (Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйре)

Нигерия каласы

Людвиг ... Бетховен



1821-1829 елларда Греция азатлык сугышында катнашкан хәрби җитәкче

... Мостаев (Татарстанның элеккеге хәрби комиссары)

Төрмә ятагы

Тавык (диал.)

Данлы исем, яхшы ат

... Шәйхразиев (БТКның Милли Шура рәисе)

Раис Габдулла төзеде.

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Вакыт», шама, ат, «Рух», рани, Спас, шыбын, Ләис, мемориал, тан, Роберт, йөгән, хромка, Ахир, Крат, әл, уба, Былтыр, тора, «Гашыйк», «Амур», туй.
Өстән аска: «Ваксынмыйм», Карашәм, галл, Усы, Әхәт, Гай, хат, Бируни, ырам, Рур, Шу, Неарх, фырт, Лорка, Шүрәле, Бор, Тукай, тема, манси, Арктур, Ати, Санта.

«Безнең мирас»

елъязмасы /май

Беренче рәттә (сулдан уңга): Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи; икенче рәттә: Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур. Васильево, 1940 ел

675 ел элек (1345)

Татар дәүләтендә чума авыруы тарала башлый. Бу коточкыч зәхмәт, Кытайда чыгып, анда 12 миллион кешене вафат итеп, Бөек Ефәк юлы аша Идел буйларына да килеп җитә. Ул, Хәзәр (Каспий) диңгезе, Дон (Тын) елгасы вә Кара диңгез ярларында таралып, аннары Италия сәүдәгәрләренең кораблары белән Италиянең үзенә, Грециягә, Сүриягә, Мисырга, Франциягә, Германиягә, Англиягә, берничә елдан исә Скандинавия илләренә дә барып җитә. Шуннан Новгород белән Псков кебек урыс калаларына да тарала.

Алтын Урда дәүләте чума зәхмәтеннән бик зур зыян күрә. Идел буе вә Кырымны кара үлем пәрдәсе каплап ала. Бу эпидемия татар дәүләтенең сәяси-иҗтимагый хәятенә, икътисадына, мәдәни үсешенә бик зур зыян китерә.

155 ел элек (1865)

20 майда журналист, язучы-сатирик Шакир Мөхәммәдев (1865-1923) дөньяга килә.

90 ел элек (1930)

ТАПП (ул вакыттагы Татар язучылары оешмасы) шагыйрь Һади Такташны ике айга Донбасска иҗади командировкага җибәрә.

Мәскәүдә татар телендә «Ударниклар» исемле журнал (җаваплы мөхәррире – Муса Җәлил) нәшер ителә башлый.

80 ел элек (1940)

Себер татарларының халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю вә ачыклау максатыннан, Яңа Себер (Новосибирск) һәм Омск өлкәләренә башкалабыз Казаннан экспедиция оештырыла.Фәнни сәфәрнең җитәкчесе – Хәмит Ярми.

55 ел элек (1965)

«Совет әдәбияты» журналында Шәйхи Маннурның «Муса» романы басыла башлый.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Содержание. Май2020

И останется в мире слово моё…: Ризаэддин Фахруддин.

Татарский мир: «Ильяс хазрат Зиганшин: «Передадим наше наследие будущему поколению!»; «Милосердный сын татарского народа».А.Хабибуллин; «Благородные татарские богачи». Т.Биктимирова.

Историческое наследие: «Вчера, сегодня, завтра». И.Тагиров; «Надгробные камни кладбища Утемиш». Р.Исхакова; «Вопросы относительно судеб татарских женщин на I Всероссийском мусульманском конгрессе». А.Шарафиева; «Газета «Иттифакъ»(«Единство»)»; «Бурхан Шахиди (1894-1989) – знатный общественный деятель Китая, учёный и писатель».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Тоска по родному краю». Х.Миннегулов; «Напев тальяна». С.Шайхи.

В глубинах памяти: «Надгробный камень Марджани». А.Гайнутдинов; «Памятник Великому Мухаммеду». Г.Шамсутдинов; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Слово – украшение языка: «Тукай – это государство нашего татарского народа». Т.Миннуллин.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Булачак прокурор Сәйфихан Нәфиев (рәсемдә уңнан беренче, армиядән кыска ялга кайткан чагы) якын туганнары Фарук һәм Рәшидә белән. 1961 ел

- Татар китабы. **Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов**
- Прокурор. **Фарук Нәфиев**
- Мишәр авылы – Кыр Бикшиге. **Нәкыйп Каштан**
- Карлыгач оясы. **Сәмига Сәүбәнова**
- Фамилияләребез. **Гүзәлия Хаҗиева**

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Кичүчат Сабан туе. 1990 ел

Самдун Фәрхетдинов төшергән фотолар Әлмәт районының Кичүчат авылындагы Ризаэддин Фәхреддин музее (җитәкчесе – Диләрә Гыймранова) фондыннан алынды.

Кичүчат авылының Тау ягы урамыннан күренеш

Авыл аксакаллары Газизҗан һәм Минкәрим бабайлар

Кичүчат авылы механигы Әнвәр Нурми улы Миңнебаев

Кирмәннән Воскресенская урамының күренеше
Абдулла Дубин архивыннан

ИКЕ КАЗАН

Беренче Май мәйданының Кремль урамына тоташкан ягы

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
• редакциядә
• *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә
электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.